PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 АПРЕЛЬ № 4

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ТУАСЫ ҖАННАР ХАКЫНА

авырлыктан чыгу юлы бар

АХИРӘТЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР

уенын-чынын кушып

ТАЛКЫШ КӘЛӘВӘ

Лилия Байкеева сыйлый

Сурия МЕЛИЯ:

«УҢЫШЛАРЫМНЫҢ СЕРЕ – ТОРМЫШНЫ ЯРАТУЫМДА»



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!



Дамир АБДУЛЛИН.
Арча районы.

Арча районының Яңа Кырлай авылында – Сәгъди абзыйның бакча башында күккә ашкан мәгърур бер нарат бар. Гади генә нарат түгел ул – Тукайның кул җылысын саклаучы агач. Сәгъди абзый белән бәләкәй Апуш икесе бергә утырткан булган аны.
Бу хакта заманында Сәгъди абзыйның авылдашлары әйтеп калдырган. Агач янәшәсендәге бәләкәй тактада да: «Чордашлары сөйләгән хатирәләргә караганда, әлеге наратны Сәгъди абзый белән кечкенә Тукай 1893 елның язында утырткаННар», – дип язып куелган.

Габдулла ТУКАЙ

Туган авыл

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Материалны әзерләргә ярдәм иткәннәре өчен Татарстанның Арча районы Яңа Кырлай авылындагы «Габдулла Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексы» директоры Абдуллин Дамир Зиннәтулла улына, «Таттелеком» элемтә компаниясенең матбугат идарәсе җитәкчесе, шагыйрь Зәкуанов Рөстәм Газизҗан улына олы рәхмәтебезне белдерәбез.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Тәхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны	222-09-77
Җитәкче урынбасары	
Рәмзия Кашапова	222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары	
Гөлнур Хәсәншина	222-09-78
Җаваплы сәркатип	
Лариса Маликова	

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Сүрия Мелия
Фото: Наталья Сухарева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 3.04.2017 ел.
Заказ А-830.
Тираж 6242.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

Эльвира ҺАДИЕВА

Ап-ак көннәр

Апрель инде –
Күкрәк тутрып сулый җиле,
Юеш күлмәк чабуларын чишә урам –
Имеш, Кояш кайнарырак...
Ә мин менә
үзәгендә шушы язның басып торам.
Монда – һәр сүз, һәр ым меңәр төскә манма,
Монда – хиснең тәүге һәм соң ихлас мәле.
Кымыз тамчылары кебек ап-акмы көн –
Апрель, димәк!
Син дә... син дә яшә, йәле...





Диля Барышева эше. Владимир Набоков мотивлары буенча. Батик.



Наис ГАМБӘР

* * *

Апрель...
Апрель...
Гөрләп ага сулар,
Эри туңнар... Хәят сәламәт!
Апрель...
Апрель...
Җаным иркен сулар, –
Ярлар тулы сөю-сәгадәт!

Уйлар...
Уйлар...
Тоташ ташкын инде
Тамырларда уйлар агышы;
Дулар...
Дулар...
Җанда язгы сулар,
Ишетәм гөрләвекләр тавышын.

Хәтер...
Хәтер...
Язгы ташу идек,
Аккан сулармы без бүген дә?!
Хәтер әйтер:
«Сөю – тынмас дулкын,
Мәңгелек бер агым күңелдә».
Истә...
Истә...
Төнге яланнарның
Күкрәгенә ятып еларлык!
Эчтә...
Эчтә...
Эчтә сулыгып тибә
Әкияти бер гүзәл чынбарлык!..

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

12
СҮРИЯНЕҢ СЕРЕ: «МЕЛИЯ 999»
Н. Туйгунова





ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8
ТУАСЫ ҖАННАР ХАКЫНА
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





18
ТӨҮЛЕКТӘ – 48 СӘГАТЬ!
Л. Гәрәева



16
АХИРӘТЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР
Л. Әбүдәрова



26
СУРГУТ ТАТАРЛАРЫ
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК



МӘДӘНИ ТОРМЫШ



34

ГАЛӘМ СУЛЫШЫ
А. Юнысова




ЯШӘЕШ

48



ЧАЛЫ КОШЫ
А. Юнысова



ӘДРӘН ДИҢГЕЗ, ЗӘҢГӘР ДИҢГЕЗ...
Й. Шәрапова

52



ШУЛАЙ УК:

26 АК КАЛФАКНЫҢ ТАБЫЛГАН ЧАГЫ
Э. Закирова

40 «ТАШЛАМА МИНЕ»
М. Маликова



ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ

60



МИЛЛИ ҺӘМ ЗАМАНЧА



КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА:

КҮКЛӘРДӘ НИКАХ УКЫЛМАГАЧ... БУЛГАН ХӘЛ.

ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР. РАЛИЯ КӘРИМОВА. ХИКӘЯ.

ҖОМГА НАМАЗЫНА... ИЕРУСАЛИМГА. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ.

СӘЙЛӘНЛЕ ШАРФ. ЗӨЛФИЯ СӘЛИМҖАНОВАДАН МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Әти, әни – иң кадерле, газиз кешеләребез. Күпме генә гомер яшәсәң дә, аларга булган рәхмәтне әйтеп тә, бурычыбызны түләп тә бетереп булмас.

Безнең әти белән әни икесе дә сугыш чоры балалары. Ач, ялангач, ятим үскән буын. Әни – ике яшеннән, әти биш яшеннән әтисез калган. Ике гаиләдә дә бишәр бала үскән. Әниләренең тырышлыгы аркасында берсе дә ачтан үлмәгән. Сугыш авырлыгын да, ятимлек ачысын да, башка кыенлыкларны да алар эш белән баскан. Шулай гомер буе икесе дә эшкә нык, авырлыкларга чыдам, курку, ялкаулыкны белмәс кешеләр булып яшәделәр һәм яшиләр. 80 яшен тутырган әти белән 77 яшьлек әни әле дә үрнәк алырлык. Әле узган ел өйләрне тышлатып, ишек алларына матур таш җәйдереп, бакчалар утыртып яшәп яталар. Җәй җитсә, болыннардан дару үләннәре җыеп киптерәләр. Моның күбесе – дус-ишкә, туганнарга кучтәнәчкә бирергә дип эшләнә. (Рәшит абый гаиләсе – журналның күптәнге укучылары. Кучтәнәчкә китергән хуш исле үлән чәйләрен без дә татып караган бар. – *ред.*) Инде бу яшьтә бераз үзләрен генә кайгыртып яшәсәләр дә булыр иде, кул кушырып кына ята торган кешеләр түгел шул...

Әти кечкенәдән бик шук, кыю, бөтен нәрсә белән кызыксынучан булган. Әтнә районының Бәхтияр авылында, Тукай туган көнне, әмма аннан нәкъ 50 елга соңарып, гаиләдә беренче ир бала булып дөньяга килгән ул. Укырга кергәндә аңа инде 8 яшь ярым булса да, укый да, яза да белми идем, дип сөйләгәне хәтердә. Сугыш чоры бит, кем өйрәтеп утырсын инде? Шулай да ярты ел дигәндә иң алдынгы укучылар рәтенә чыга. 4 нче сыйныфны тәмамлаганда хәтта укытучыларны да уздыра. Берсендә бик кызык хәл була – арифметикадан бирелгән мәсьәләне әти бик тиз генә чишә дә, укытучыга тоттыра. Укытучы аның дәфтәрен алып, каядыр юкка чыга. Бераздан, кереп, әти чишкән мәсьәләне тактага язып куя. Бөтен класс шуннан күчерә. Укытучы исә аны колхоз бухгалтерына күрсәтеп, дөреслеген тикшертеп кергән икән. 7 нче сыйныфны ул инде көн дә алты чакрым йөреп, Олы Мәңгәр авылында укый. Аны тәмамлагач, 8 нче сыйныфка Әтнә урта мәктәбенә китә. Әнисе каршы төшсә дә, әтинең укырга теләге бик зур була. Теләк кенә түгел, әтисенең әманәте дә була бу. Сугышка киткәндә, улының башыннан сыйпап, укырга кушып калдыра ул. Әти урта мәктәпне 1954 елда тәмамлый. Ул чакта урта белемле кешеләр авылда нибары өчәү генә булалар, шуның берсе – безнең әти. Бәхтиярда югары белемне дә беренче булып әти ала.

Билгеле, теләгенә ирешү өчен аңа бик күп тырышырга туры килә. Беренче юлы имтиханнарны яхшы биреп, керүчеләр исемлегенә эләксә дә, торыр урын булмау, акча юклык аркасында, укуын ташлап, эшкә урнаша. Армиядән кайткач, артиллерия училищесына укырга керә. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, аннан да китә. Бары 1960 елда, инде өйләнеп, гаилә коргач кына КХТИга кереп, югары белем алуга ирешә ул. Әти гомере буе дөреслек өчен көрәшүче булды. Балачактан шулай, гаделлек хакына үзеннән олырак яшүсмерләр белән сугышудан да курыкмый. Әле бүген дә «тынгысыз бабай» күп кенә дәүләт чиновникларына тынычлык бирми. Казанның без яшәгән Мирный бистәсендә урамнарны яктырту, тротуарлар түшәтү, уңайлы автобус маршруты ачтыру өчен тырышып йөри. Үткәндәге хатирәләрен барлап, аларны матбугатта бастыра. Шундый бер хатирәсен: әнисенең, исән-имин кайтуын көтеп торсын дип, әтисе сугышка киткәндә тешләтеп калдырган икмәген (йоласы шундый) ачлыкка түзә алмаганда урлап ашавы турындагы язмасын укыганда күзләремә яшь тулган иде. Әти гаярь холыклы булса, әни – аның киресе. Бик тыныч, бөтен нәрсәне тәртип белән, уйлап кына эшли торган кеше. Ул әтиебезнең иң зур бәхете булгандыр. Укырга бик талпынса да, әнигә укырга насыйп булмаган. Ялгызы биш бала үстергән әниләренең бар баласына да югары белем бирерлек мөмкинлеге каян килсен? Нәрсә дисең, сугыш гаепле. Ә бит әнинең нәселендә бар да укымышлы кешеләр булган.

Без, белемгә омтылып яшәгән әти-әнинең ике кызы да, Аллага шөкер, Казан университетының ВМК факультетын кызыл дипломга тәмамладык. «Бишле»гә укырга гына түгел, «бишле»гә яшәргә дә өйрәткән әти-әнигә бик зур рәхмәт.

Гүзәл ИШМӨХӘММӘТОВА.
Казан.

Биектау районының Урта Алат авылында гомер-гомергә су булмаган. *Авыл халкы, чиләк-көянтә асып, чишмәгә суга йөргән. Авыл белән чишмә арасы чакрым тирәсе булыр.*

2007 елда бу авылдан йорт сатып алган идем. Җәй айларында шул авылда торам. Шуңа күрә проблемалары белән дә яхшы таныш. 2010 елда авылдашлар су артыннан йөрүне миңа тапшырдылар. Әйткәнемчә, чишмә ерак, ә казылган коеларны күмеп бетергәннәр. Шул көннән алып, су юллап, кайларда гына булмадым, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем. Иң элек гозеремне Биектау районы Башкарма комитеты җитәкчеләренә җиткердем. Аннары хакимият башлыгына кердем. Эш һич кенә дә кузгалмады. Ләкин минем башлаган эшне ярты юлда калдыра торган гадәтем юк. Татарстан прокуратурасына һәм Тикшерү комитетына гариза язып бирдем. 2011 елның декабрендә Биектау районы Башкарма комитетына «2013 елда авылда су кергән булырга тиеш» дигән күрсәтмә җибәрелде. Әмма ул елны да су кермәде.

Уйладым-уйладым да, бөтен документларны алып, Мәскәүгә киттем. Дәүләт Думасын эзләп таптым. Татарстаннан сайланган үзебезнең депутат Айрат Хәйруллин мине игътибар белән тыңлады. Бу – 2015 елның 17 августы. «XXI гасырда көянтә күтәреп суга йөргән кешене күргәнегез бармы?» – дидем депутатка. «Авыл җирләрен үстерү сәясәте» һәм «Чиста су» программаларын исенә төшердем. Үтемле итеп әйткәнмен, күрәсең. Ноябрь аенда ук авылга су кертер өчен 8 миллион 765 мең сум акча күчерелде. 2016 елның март аеннан су кертә башладылар. Бу максатларга 1 миллион 900 мең сум акча тотылганын беләм. Әлбәттә, бу эшләрне берүзем генә җиңеп чыга алмас идем. Ярдәм итүчеләрем булды. «Сөембикә» журналы безнең проблемалар турында журналга язып чыкты. Татарстанда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская, «Татарстан хатын-кызлары» оешмасы рәисе Зилә Вәлиева, «Роспотребнадзор» җитәкчесе Александра Патяшина, тиешле оешмалар белән элемтәгә кереп, мәсьәләне хәл итәргә булыштылар. Авыл халкы чиксез рәхмәтле аларга! Гомумән, биредә хатын-кызлар башлап йөрде: хатын-кыз журналы, хатын-кыз җитәкчеләр... Дөнья – хатын-кыз җилкәсендә дип, тикмәгә генә әйтмиләр шул.

Җәмбилә АХМЕДОВА.
Казан.



Табигать һәркемгә дә бертөрле сәләт бирми. ***Кемдер җыр-биюне булдыра, кемдер язу-сызу эшенә маһир, кайберәүләр техника белән «җенләнә», кемдер кул эшләре остасы.*** *Әйе, әйе, остасы! Эшне бөтен кеше эшли аны, ә менә остасы бик аз була.*

Сүзем шундый осталарның берсе – Лаеш районы Пәрәү авылында туып-үскән Сәлимҗанова Гөлсинә Габделәхәт кызы турында. Чын мәгънәсендә алтын куллы ул Гөлсинә апа.

Мәктәптә укыганда ук матур итеп рәсемнәр ясый. Төрле конкурсларда катнашып, призлы урыннар яулый. Мәктәпне тәмамлагач, туган авылында калып, 25 ел сыерлар сава. Әнисеннән күреп, Гөлсинә апа тегү эшенә өйрәнә. Алга китеп шуны әйтергә кирәк: Гөлсинә апаның әнисе мәрхүмә Зәйтүнә апа һәм аның апасы Нәсимә теккән күлмәкләрне Пәрәүнең байтак хатын-кызы кия.

Соңрак Гөлсинә апа бәйләү эшенә өйрәнә. Аның хезмәтенә сокланмый мөмкин түгел! Бәйләм башмакның гына да ничә төрлесен уйлап тапкан ул! Ә ул төсләр чагылышы, бизәлеше! Чын рәссам, чын иҗат иясе! Әнә урман аланында агачка бармагын кыстырган Шүрәле, су буенда алтын тараклы Су анасы утыра. Саный китсәң, бик күп алар. Барысы да җептән бәйләнгән аның иҗат җимеше. Ул бәйләгән җылы, матур оекбаш-башмакларны байтак авылдашларыбыз кия.

Гөлсинә апа 1981 елда авылдашыбыз Рәшит абыйга кияүгә чыга. Алар ике бала тәрбияләп үстерәләр, дүрт оныклары бар. Кызы Гөлүсә һәм килене Айгөл дә кул эшенә бик осталар. Кызганычка каршы, Рәшит абый кыска гомерле була.

Гөлсинә апа кавын, карбыз да үстерә. Бакчасындагы чия, слива, виноградтан нәрсәләр генә әзерләми уңган хатын. Аның бакчасында урманнарда гына очрый торган каен җиләгенә кадәр үсә. Яз, җәй куйган хезмәте көзен зур уңышы белән сөендерә. Ул ясаган салатлар, кайнатмалар бөтен авылга җитәрлек. Үзе үстергән нигъмәтләрдән балаларына, дус-туганга өлеш чыгара Гөлсинә апа.

Аның тагы бер мавыгуы турында әйтми китми булмас. Кыш көне Гөлсинә апалар турыннан үтеп киткәндә сине «урман җәнлекләре» озатып кала. Кар бабай белән Кар кызы янына әллә никадәр кар сыннар ясап-бояп куя ул. Ә җәен ул сыннар торган урыннар аллы-гөлле чәчәккә күмелә.

Алтын куллы Гөлсинә апабыз игелекле, мәрхәмәтле, шәфкатьле, олы йөрәкле кеше дә. Ничә ел урын өстендә яткан әнисен кадерләп соңгы юлга озатты.

Озын гомер, ныклы сәламәтлек телибез сиңа, Гөлсинә апа. Алдагы тормышың үзең үстергән чәчәкләрдәй матур булсын.

Роза КӘРИМОВА.
Лаеш районы,
Пәрәү авылы китапханәчесе.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

СОҢГЫ ЧИККӘ ҖИТКӘН ХАТЫН-КЫЗНЫ БАЛА ТӨШЕРТҮ УЕННАН КАЙТАРУ БИК КЫЕН.

Мәдинә АВЗАЛОВА

ТУАСЫ ҖАННАР ХАКЫНА

Гаиләне, әниләрне һәм балаларны яклау үзәге «Умиление»дә эшләүче кызлар үзләре дә бала сыман гына әле. Ләкин: «Штатта без бишәү генә», – дип сөйләгән психолог Аида Фиогбе да, үзәк җитәкчесе Элина Галиуллина да нинди катлаулы, җитди эшкә алынуларын яхшы аңлыйлар. Кеше гомерләре, кеше язмышлары, бер уйласаң, алар кулында бит.

Моннан алты ел элек оешкан әлеге үзәкнең төп максаты – бала төшертергә җыенган, тудыргач та баласыннан баш тарткан әниләрне ялгыш адым ясаудан туктатып калу, кайчан да бер барыбер үкенәчәк уйларыннан кире кайтару.

Менә-менә очарга әзер күбәләктәй, җаны уч төбендә торган сабыйның гомере белән үлчәнә ул игелекләр... Беркайчан да истән чыкмый, гомергә артыңнан эзәрлекләп килә торган зур хата димим, олы фаҗигадер ул балаңнан баш тарту. Тудыргач та нәниен бала табу йортында калдырып кайткан яшь әнинең, газизен эзләп, бер балалар йортыннан икенчесенә чабуы турында елап сөйләвен бер дә онытасым юк. Үкендерә ул шулай, тик инде соң була.

– Баланы табаргамы-төшертергәме дигән сорау туганда, хатын-кыз иң элек гаиләдәге матди хәлне күз алдында тота, – ди үзәк җитәкчесе Элина Галиуллина. – Йә аны ире ташлап киткән, йә табарга

кушмый. Шуны истә тотып, дүрт ел элек гуманитар ярдәм оештырдык. Безнең Киров районында үз складыбыз бар. Мохтаҗларга хатын-кыз һәм балалар киемнәре, караватлар, колясками, бала чүпрәкләре, памперсларга кадәр бирәбез. Һәм, әлбәттә инде, кирәксенгән кешегә азык-төлек таратабыз. Без инде 600 дән артык гаиләгә булыштык. Күбесе боларны җитди ярдәм итеп кабул итә. Дөресен әйткәндә, хатын-кызга күп тә кирәкми. Булмаганда, әйтик, аягына итек (нибарысы!) алып бирсәң дә, бала табарга риза ул. Тик үзенең проблемалары белән ялгыз калдым дип кенә уйламасын. Шунысы куркыта аларны.

Үзәккә мөрәҗәгать итүче хатын-кызларның барысы да диярлек бирегә баласын төшертәм дип килә. Аларны баласын калдырырга үгетләү бик авыр, диләр. Күп вакыт әниләрнең 10-15 проценты гына кире уйлый. Белгечләрнең әйтүенә караганда, йөкле булуын белүгә үк, хатын-кыз белән психологлар эшли башларга тиеш. Югыйсә, әйткәнебезчә, соң була.

Гүзәл затларыбызга беркайчан да җиңел булмаган анысы. Иренең теләгенә каршы килеп, бала тапкан әниләрнең урамда калу очраклары да аз түгел. Алты айлык йөге һәм бер баласы белән кая барырга белми йөргән яшь әнигә, вакытлыча бүлмә алып, киемсалым, азык-төлек белән булышкан, хатынга баласын тапкач та, кирәкле ярдәм күрсәтеп торган үзәк кызлары, 2013 елдан бирле эшләп килгән «Кризис фатирлар» проектын тагын да киңәйтеп, хәзер әнә «Бишек» дип исемләнгән социаль приют ачарга җыеналар. Кирәкле һәм игелекле эш икәнлеге, моңа бөтен җәмәгатьчелек оешмалары кушылырга тиешлеге язмышларда чагыла.

Фатирга түләргә дә җитми

Ул – дүрт бала әнисе. Ире белән аерылган. «Ни өчен?» дигән сорауга җавапны үзе дә белми. «Балаларны яратмады...» – дип кенә куя. Хатын аны алиментка биргән. Тик ала алганы гына юк. Тагын «ни өчен?» дигән сорау. Бәхетсез хатын янә җилкәсен җыера. Күке-ир рәсми рәвештә беркайда эшләми санала. Акча эшли эшләвен, тик балаларына гына түләми.

– Безгә мөрәҗәгать итүче әниләрнең һәр дүртенчесе «алимент түләми» дип, элеккеге иреннән зарланып килә, – дип сүзгә кушыла психолог Аида Фиогбе. – Чыннан да, ул ир беркайда эшләми санала. Шуңа суд приставлары да берни кыла алмый. Ә балаларны ашатырга-эчертергә, киендерергә, мәктәп өчен кирәк-яраклар алып торырга кирәк.

Төпчегенә әле җиде генә ай. Әни кеше, бәби карап, өйдә утыра. Күп балалы гаиләләргә бирелә торган адәм мәсхәрәсе пособиедән тыш, акча керер җире юк. Шуңа алар фатирлары өчен дә түли алмыйлар. «Без акча белән ярдәм итә алмыйбыз, – ди Элина Ренатовна. – Ә менә азык-төлек, кием-салым, әнигә өйдә эшләү шартлары тудыру мәсьәләсендә бик теләп булышабыз. Хәзер ул әкренләп үзе дә акча эшли башлады». Дүрт бала белән тормышны өр-яңадан, чиста биттән башлавы җиңел түгелдер аңа. Әмма чарасыз калсаң, кая барасың? Бала хакына нәрсәгә генә бармый, ниләр генә эшләми әниләр! Шулай ич инде...

15 яшьлек әни

Кризис хезмәте аша мөрәҗәгать итүчеләр арасында балигълык яшенә җитмәгән кыз балалар да шактый.

– Бу шактый четерекле хәл, – дип аңлата психолог. – Беренчедән, ярдәм сораучы әле бала гына. Икенчедән, кыз баланы көчләмәгәннәр микән? Шуны ачыкларга кирәк. Әгәр дә шундый хәл булган икән, без бу хакта хокук органнарына хәбәр итәргә тиеш. Аннары... Бала әти-әнисенә әйтергә курка. Аңларлармы аны, ярдәм итәрләрме аңа? Гадәттә, мондый вазгыятьтә әти-әни баланы ачуланудан, еш кына кул күтәрүдән ары китә алмый. Ә инде йөккә узган икән, мәсьәләне хәл итүнең бердәнбер юлы итеп абортны сайлый. Әле күптән түгел генә 15 яшьлек бер кызыбыз бала тапты, – дип дәвам итә ул. – Әнисе кызының интим тормыш белән яшәвен белмәгән дә. Кызы авырга узгач кына әйткән. Әнисе: «Ишеткәч, шок хәлендә калдым», – диде. Бигрәк яшьләр бит әле. Билгеле инде, әти-әнисе шундук: «Төшертәсең», – дигән. Кыз телефоныбызны эзләп табып, безгә шалтыратты, ярдәм сорады. «Баладан котылырга булышыгыз», – ди.

Психолог башта кызның әнисе, аннары малайның әнисе белән сөйләшә. Шуннан соң гына баланы таптырырга дигән карарга киләләр. Чөнки инде төшертү вакыты күптән узган була. Кыз – гаиләдә бердәнбер бала. Тормышлары җитеш. «Алар безнең матди ярдәмгә мохтаҗ түгел», – ди җитәкче дә.

Өстәлендә бер тамчы да ризык калмаганда, нәниен төрерлек чүпрәк тә таба алмаганда, әниләр шушы үзәккә килеп сыена.

«Уллыкка биргәнче – үтерергә...»

Авырга узып, ике кызы белән Украинадан качып кайткан хатынның әйткән шушы сүзләре үзәктә эшләүче кызларга аяз көнне яшен суккандай яңгырый. «Балагызны табыгыз да, аннары уллыкка бирербез», – ди алар. «Уллыкка биргәнче, аборт ясатам. Аның чит гаиләдә тилмереп яшәвен теләмим», – дип кырт кисә хатын. Тик шулай да соңыннан, уеннан кире кайтып, табасы итә. Малай тугач, әни кеше шатлыгыннан елап җибәрә. Ул бит күптән малай көткән, малай дип хыялланган. Хәзер ул өч баласы белән вакытлыча яшәп тору урынында. Өйдә тик ятмый: тегә, аш-су осталыгына өйрәнә. Тормышта аңа бу һөнәрләр бик тә ярап куяр әле.

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

«Балаң озак яшәмәс»

Еракта калган ул вакытлар хәтеренә төшсә, өч бала анасы Диләрә ханым сискәнеп китә. Аның әти-әнисе Казаннан Фирганә якларына китеп, шунда яшәп кала. Биш балалы гаиләдә үскән кыз, унберенчене тәмамлап, бухгалтерлыкка укый. Кияүгә чыга. Башта бер, аннары икенче балалары туа. Бөтен проблемалар икенче бала туугa башлана.

– Баланың баш сөяге имгәнгән иде, – дип сөйли Диләрә ханым. – Күрәсең, аны алгандамы-салгандамы төшереп җибәргәннәр. Табиблар миңа әйтмәде. Бу хакта еллар узгач кына, Казанга күченеп кайтып, табибларга йөри башлагач кына белдем. Ә андагы невропатолог: «Нәрсәгә бу тиклем чәбәләнәсең. Ул барыбер яшәмәячәк. Синең әле балаларың тагын булыр», – дип елаткан иде мине.

Яңа туган балаңны хастаханәдә бер-ике айга гына да калдырып торырга ярамый. Чөнки ана инстинкты бик тиз сүнә.

Казанга кайткач, алар инвалид балаларын аякка бастыру мәшәкатьләре белән йөри башлыйлар. Гаиләдә – өч бала. Уртанчы уллары – инвалид. Аның башына инде ике мәртәбә Мәскәүдә операция ясаганнар. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы квота белән булышкан. «Бер ел бала тыныч яшәде, өянәге килмәде. Хәзер тагын кабатлана башлады. Кабат операция кирәк. Ә квота хәзергә юк. Ирем операциягә каршы. «Күпме яшәсә, шул кадәрле яшәр. Баланы җәфаламыйк», – ди. Мин каршы. Соңгы көчемә кадәр тырышачакмын. Балага хәзер 11 яшь. Минем аны югалтасым килми». Диләрә ханым көрсенеп куя. Ирен гаепләми, аңлый ул аны. Ипотека буенча бер бүлмәле фатир сатып алганнан соң, аена 21 мең сум акча түли башлагач, ашарларына да калмый. Авыру балага санаторий, бертуктаусыз тернәкләндерү чаралары кирәк. Хатын эшләми, бәләкәчене әле җиде ай гына. Ирнең эшләгәне кредит түләүгә китеп бара. Ә операциягә, хәтта квота булган очракта да, бик күп акча кирәк. «Каян табарга?» – ди Диләрә ханым, янә авыр сулап.

Яшьләргә авыр шул. Тормышны шундый итеп кордылар ки, кредитсыз ни уңга, ни сулга хәзер. Инвалид баласы булган гаиләгә бигрәк тә кыен. Өстәвенә, алар әлегә Россия паспортын да ала алмыйлар. Югыйсә инвалид балага ташламалар ярыйсы гына бит бездә. «Умиление» үзәгендәгеләр белән иптәш кызы таныштырган. Менә инде ел ярым гаилә шуларның ярдәмен күреп яши. Диләрә ханым үзе дә эшсез тормый: үзәктәгеләр булышлыгы белән чигәргә, тегәргә өйрәнә. Теккән-чиккән әйберләрен ярминкәгә чыгарып сата. Аз булса да, барыбер акча бит әле ул.

– Әле ярый ирем әйбәт, – ди ханым.

Анысы шулай. Инвалид бала булган гаиләләрнең төп проблемасы бала түгел, ә эти кеше үзе. Ул көндәлек мәшәкатьләргә түзә алмыйча, өйдән чыгып кача. Биредәге белгечләрнең әйтүенә караганда, Даун синдромы булган балаларның этиләре юк, аларны әниләре генә тәрбияли. Шуңа да биредә «Үзгә бала» проекты эшли башлаган.

«Барыбер табам, дидем»

Янәбызда уйнап йөргән нәни кызчык әле блокнотыма үрелә, әле якшәмбе мәктәбендә укучы балалар калдырган рәсемнәрне бер урыннан икенче урынга күчерә. «Сөйләшми әле, теле әкрен ачыла», – ди әнисе, баласына ягымлы караш ташлап. Ике яшьлек «зур кыз»ның бездә эше дә, гаме дә юк. «Миңа 39 яшь инде», – дисә дә, болай үзе бик яшь күренгән ханымга, «Өчәү минем, менә дүртенчесен алып кайтырга җыенам», – дигәч, соклануымны яшерә алмыйм.

– Курыкмыйсыңмы соң? Дүрт бала белән... ай-һай.

Ул яңгыратып көлеп җибәрә.

– Ничек куркыйм, әнә бит янымда нинди булышчылар, – ди әңгәмәдәшем, өстәл янына тезелешеп утырган үзәк кызларына ишарәләп. – Алар миңа югалырга ирек бирмәс... Ирем дә: «Бәлкем монысын тапмассың», – дип карады. «Үгетләмә, барыбер табам», – дидем.

Ул тиз генә үзенең тарихын сөйләп ала. Зарланмый да, офтанмый да... Гомумән, бу ханым барын да ал төсләрдә күрергә күнеккән, ахрысы. «Бер бүлмәле фатир сатып алдык. Бар акчабыз (һаман бер проблема!) кредитка китеп бара. Менә кызлар ашата, киендерә», – ди ул, инде ишеткән сүзләрне җөмләгә-җөмлә кабатлап. Күп балалы гаилә булганга, аларга йорт салу өчен җир биргәннәр. Хатын шуңа сөенә. Фатир өчен түләгәнгә дә акчаның бер өлешен (1600 сум) кире кайтаралар. Монысына да бик шат ул. «Белмим, кызлар булмаса, кризистан ничек чыккан булыр идек», – дип, рәхмәтен белдерергә дә онытмый.

«Умиление» үзәге җитәкчесе Элина Галиуллина интернет, социаль челтәрдәге элемтәләр аша җыелган акчага өч ел «Кризис» фатирлары тотулары, инде менә йөкле хатыннар өчен «Бишек» дигән приют ачарга җыенулары хакында сөйли. Аның бер бүлмәсе мастер-класслар алып бару өчен булачак икән. Акушер-гинекологлар, психологлар, социаль хезмәткәрләр әниләр белән әңгәмәләр үткәрәчәк. Алар шулай ук «Яшь әниләр клубы» оештырырга, мәктәпләрдә өлкән сыйныф укучылары белән гаилә мөнәсәбәтләренә кагылышлы темага сөйләшүләр алып барырга да ниятлиләр. «Игелек җирдә ятмый» дисәләр дә, үзләрен дөньяга таныту, башкарган эшләре белән масаю өчен эшләми алар бу эшләрне. Бары кулларыннан килгәнчә ярдәм итеп, әниләрне тормышка кайтарырга, үзләрен кеше итеп тояргa гына булышалар. Туасы җаннар хакына барын эшләргә әзер алар.

Белешмә. Ярдәмгә мохтаҗлар өчен телефоныбыз: 89872200360; 216-76-19 (Россия буенча шалтыратулар бушлай – иртәнге 9 дан кичке 10 га кадәр).

ЧҮПЛЕКТӘГЕ... БӘБИЛӘР

Йөзләрчә нәниләрнең олы фаҗигасе, чактан гына өзелми калган гомерләр турында сүзебез.

Ташлап калдырылган, ташландык ише җан өшеткеч сүзләрне шул нарасыйларга карата куллану үзе генә дә зур гөнаһтыр. Кызганыч, әмма күңел тетрәткеч ул мисаллардан беркая да кача алмыйбыз. Дөньяга күзләрен дә ачарга өлгермәгән бичара сабыйларны әле чүплектән, әле урман кырыеннан, әле кар өстеннән табып алалар. Сулышы да беленмәгән, йөрәге дә сизелер-сизелмәс кенә типкән җан иясе полиция хезмәткәрләре, ак халатлы игелек ияләре кулына килеп эләккәч, яңадан тормышка кайта. Нинди зур тырышлык, никадәрле тынгысыз хезмәт бәрабәренә икәнлеген Казанның 18 нче клиник хастаханәсендәге шушындый бәхетсез балалар өчен ачылган бүлекчә хезмәткәрләре генә белә булыр. Ел саен, туган көненнән алып, 4 яшенә кадәр бәләкәчнең «өенә» әверелгән әлеге бүлекчәдә 200 ләп бала булып китә. Бик күп инде бу.

– Язмыш кочагына ташланган, гомере мәче баласыныкыннан да арзан бәяләнгән ул сабыйларның әниләре йә фахишәләр, йә наркоманнар, йә аракыдан башы чыкмаган айнымаслар, – ди хастаханәнең балалар стационары бүлеге мөдире Татьяна Мороз. – Газизен чүплеккә ыргытып калдырган имансызлардан ни көтәсең? Аларга бала кирәкми. Полиция, ашыгыч ярдәм хезмәткәрләре алып килгән баланың туган көнен дә (якынча, әлбәттә), исем-фамилиясен дә үзебез куябыз.

Бирегә яңа туган балаларны гына түгел, караучысыз калган 4 яшькәчә балаларны да алып киләләр. «Әле генә ике баланы алып килделәр, – ди бүлек мөдире. – Берсенә 1 яшь, икенчесенә 4 яшь. Әниләре ташлап чыгып киткән. Ә балалар фатирда ялгыз». Бәбиләүгә үк баласы турында оныткан әниләрнең бала пособиесенә яшәүләрен, эше судка барып җиткән очракта да судка йөрмәүләрен, инвалид балаларга пособиенең 15 мең тирәсе түләнүен сөйләп ала.

Бүлекчәгә килеп эләккән сабыйларның барысы да озак һәм җитди дәвалануга мохтаҗ. Юыну дигәннең нәрсә икәнен белмәгән ул сабыйларның кайсы бетләп беткән була, кайсы авызына ризык каба алмый тилмерә. Ашый башласа, косып җибәрә. Чөнки аны юньләп ашатучы булмаган. Шундый хәлдә килеп эләгә алар табиблар кулына. Аннары ярдәмгә психологлар, неврологлар кушыла.

Узган елның август айларында булган вакыйганы гына искә төшерик. Ул чагында бөтен республика халкы гөж килде. Хатын баласын таба да, кая куярга, кайда ташлап калдырырга белми йөри торгач, урамда ашыгыч ярдәм машинасын күреп ала. Янына килә. Кеше күрмәгәндә генә, бәләкәй төргәкне машина астына ташлый. Ничек аны күреп алалар, ничек машина таптап китми. Гомере булгандыр инде баланың. Сабыйны үзе ише бәхетсезләрне кочагына алырга әзер торган әлеге хастаханәгә алып киләләр. Ә хатынны тоталар, ул кылган җинаяте өчен хөкем каршына баса.

Гомумән, моның ише – күке әниләр дип әйтмим, җинаятьчеләр өчен законнар кырыс булырга тиеш, минемчә. Җинаятьчеләр дим, чөнки алар инде чүплеккә ташлап киткәндә үк бала язмышын хәл иткән була. Баланың исән калуын теләми алар. Исән калуын теләсәләр, һичьюгы хастаханә ишек төбенә, бәбибоксларга ташлап китәрләр иде.

Хатын-кызның төрлесе бар: яшәргә урыннары булмаучылар, әти-әнисе табарга рөхсәт итмәгән яшь әниләр... Алар нәниләрен вакытлыча шушы бүлекчәдә калдыра. Андыйларга табиблар, хезмәткәрләр булдыра алганча ярдәм итә. «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы белән берлектә оештырылган «Син ялгыз түгел» программасы да бүген уңышлы эшли. Ярдәм сорап мөрәҗәгать итүченең берсе дә игътибарсыз калмый. Авырлыкка юлыккан хатын-кызлар чыннан да ялгыз түгел.

Тагын яз җитә. Бүгенге көндә биредә әниләре ваз кичкән нәниләр – 31 тирәсе. Ләкин май айларында андыйларның саны кискен артачак дип көтелә. Чөнки бүлек мөдиренең әйтүенә караганда, шикле юлда йөрүче, тәртипсез яшәү рәвеше алып баручы хатын-кызлар үзләрен март мәчеләреннән ким тотмый. «Тудырган да ташлаган» ише хәлләрне күрәсе, ишетәсе бар икән әле алайса...

Мәдинә АВЗАЛОВА

АВЫР ХӘЛДӘ КАЛУЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРГА:.....

- «Надежда» социаль-хокукый һәм психологик ярдәм үзәге. Телефоны: 8(499) 492-46-89, 492-26-81, 492-06-48.
- «Добро даром» хәйрия фонды. Телефоны: 8903-344-01-99.
- Казанның 18 нче шәһәр клиник хастаханәсендәге әниләре баш тарткан балалар бүлекчәсе. Телефоны: 8 (843) 275-98-28. Адресы: Казан, Рихард Зорге урамы, 2 нче «А» йорты.
- «Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге. Телефоны: 8 (843) 246-44—01.
- Казанның 1 нче бала табу йортында, 1 нче, 3 нче һәм 5 нче хатын-кызлар консультациясендә «Бала тормышын коткар» Бөтенроссия программасы буенча махсус кабинетлар эшли.
- Татарстанда җәбер-золым күргән хатын-кызлар һәм балалар өчен «кайнар линия» ачылды.

PRESSA.RU



Фото: Наталья Сухарева

СҮРИЯНЕҢ СЕРЕ: «МЕЛИЯ 999»

Натали
ТУЙГУНОВА

НЫК ИХТЫЯРЛЫ ҺӘМ ТӘВӘККӘЛ, ҮЗ ДИГӘНЕНӘ ИРЕШМИ КАЛМЫЙ, ДИП ӘЙТЕРГӘ ЯРАТАБЫЗ КӨЧЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР ТУРЫНДА.

Шулай анысы... Ләкин эчтән еш кына күңелләре тиз уалучан бик нәфис зат алар. Тормыштагы иң авыр көнне ничек кичерергә дә, ничек барысына да кул селтәмәскә, табигатьтән илһам алып, тәүлекләр буе ничек эшләргә, үз принципларыңа ничек тугры калырга? Көчле ихтыярлы хатын-кызларның берсе белән шулар хакында сөйләшәбез.

Сүрия Мелия – татар хатын-кызлары ассоциациясе әгъзасы, уникаль «Мелия 999» кулинар цехы хуҗабикәсе, Әстерхан «фанаткасы».

Бүген татар мәдәниятен үстерүгә Россиядә генә түгел, ерак чит илләрдә дә зур игътибар бирелә. Сүрия, ә Сезнең туган шәһәрегез Әстерханда татарларның милли традицияләре сакланамы?

– Әлбәттә. «Дуслык» җирле милли оешмасы бик күп кызыклы чаралар үткәрә. Башка эшмәкәрләр кебек, мин дә фестивальләрдә, бәйгеләрдә актив катнашам. Татар ашлары рецептларын сакларга, әстерханлыларны үзенчәлекле милли ризыклар белән таныштырырга тырышам. Безнең цехтан кала, шәһәребездә әле беркемнең дә мондый эшкә алынганы юк. Татар авылларында яшәүче әбиләрдән сорасаң гына инде! (*Көлә.*) Күп татарлар Әстерханнан күчеп китә шул бүген. Казанга китүчеләр дә бар. Татарстанның башкаласы – искиткеч шәһәр! Анда мин беренче тапкыр 1969 елда булган идем. Ул чакта ук инде ул мине таң калдырган иде! Казанга татар хатын-кызларының Бөтендөнья конгрессында катнашырга килгәч, аңа кабат гашыйк булдым.

Ә үзегездә Казанга күчеп китү уе тумадымы?

– Юк, мин Әстерханымны бик яратам! Мөгаен, шәһәребезнең фанаткасыдыр мин. Берара Тайландка яки Италиягә – океанга якын җирләргә – күчеп китеп, шунда бунгало төзеп, ыгы-зыгыданерактарак яшәү турында да хыялланып алдым. Әмма аннан аңладым – далаларыбыздан башка яши аламмы соң?! Шәһәребез иң рәхәт, иң уңайлы җир кебек тоела миңа – искитмәле кешеләр яши монда! Шуңа күрә мин үзебезнең өлкәдә – елга ярында йорт сатып алдым. Анда нинди рәхәт мизгелләр кичерүемне сүзләр белән генә әйтеп аңлата да алмыйм! Гаҗәеп табигать, эссе көннәрдән ышыклый торган җиләслек, кайтавазлар яңгырарлык тынлык... Мин әле сәяхәт итәргә, дөнья белән танышып йөрергә дә яратам. Шәһәрләр, аларның тарихы, кешеләре, милли ашлары – барысы да кызык. Ләкин минем өем – Әстерхан. Ул – минем мәхәббәтем.

Гаилә – ишле, мин иң өлкәне булгач, хыялны арткарак күчерергә туры килде.

Сез тумышыгыз белән Әстерхан кызы булып чыгасыз, димәк?

– Әни ягыннан бабам – төп Әстерхан кешесе, ә әбием –Казан татары, чыгышы белән Такталы авылыннан. Сугыш вакытында ул Әстерханга килеп эләгеп, озак елларга абыйсын югалта. 1969 елда гына хатлар аша бер-берсе белән табышалар. Менә шул вакытта мин беренче тапкыр Татарстанга барып чыктым – туганнарыбыз белән күрешергә дип бардык. Милли ашларыбызга мәхәббәтне дә миңа нәкъ шул әбием сеңдерде бит. Ул шәп пылаучы иде! Туйлар өчен әзерләргә дип, махсус чакырып алалар иде үзен! Күз алдына китерегез: телеңне йотарлык пылау пешерер өчен ул берничә сәгать буе казан янында басып тора. Өйдә дә әллә нинди тәм-томнар белән сыйлый безне – гап-гади мичтә авызда эреп китәрлек пәхләвә әзерли иде әби. Шаккатарсың! Аның шәкәр-чурекләре, бәлешләре тагын... Тәмнәре хәзергәчә авызда. Аш-су әзерләүгә хирыслык миңа, мөгаен, әбиемнән күчкәндер.

Сүрия, сезнең «Мелия 999» кулинария цехы кулдан эшләү, сирәк рецептлар, төрле тәмнәрнең бер-берсен тулыландыруы белән дан тота. Әзерләгән ризыкларыгыз арасында, татар ашы булудан бигрәк, ул бары Әстерхан татарларыныкы гына дип әйтерлекләре бармы?

– О, монысы аның үзе бер тарих! Сирәк рецептлар җыю белән без күптән шөгыльләнәбез. Ә шулай бервакыт, цехны камилләштерү, ассортиментны киңәйтү

PRESSA.RU

турында уйланганда, башыма бер фикер килде бит. Әстерханда – балыклы якта – балык пилмәне булмасын инде! Рецептураны, технологиясен эзләргә керештек. Гомер буе биредә яшәүчеләрдән сораштык, хәтта башка төбәкләргә дә мөрәҗәгать иттек. Эзләгәнебезне таптык бит тәки! Хәзер инде безнең тапалган судак, сазан фаршы, толстолобиктан әзерләгән пилмәннәребез бар. Соңгы арада судактан өчпочмаклар ясый башладык әле менә. Итле, бәрәңгеле, суганлы татар өчпочмакларын гел пешерә идек инде анысы. Бер танышым балачак ризыгы булган балык өчпочмаклары турында сөйләде дә, без дә пешереп карарга булдык – искиткеч тәмле килеп чыкты! Кухняда мин экспериментлар еш ясыйм, аннары рецептураны эшемдәгеләргә бирәм.

Үземдә эшләүчеләргә: «Начар уйларны бусага артында калдырыгыз, камыр бөтенесен сизә, үзенә сеңдерә», – дим.



Судактан өчпочмак
(Әстерхан кучтәнәче)
Камыр: 250 мл сөткә: 250 г маргарин, 2 йомырка, 10 г тоз, 15 г шикәр комы, 750 г он. Камыр йомшак булырга тиеш.
Эчлек өчен: 1 кг судак филесы, 500 г кыздырылган суган, 300 г ваклап туралган бәрәңге, 80 г укроп, 20 г тоз, 5 г төелгән кара борыч. Судакны 1 см итеп шакмаклап турыйбыз. Кыздырылган суганны, туралган бәрәңгене, яшел укропны, тоз һәм борычны бергә кушып болгатабыз. Камырдан 75 әр граммлы түгәрәкләр әвәләп җәябез һәм һәркайсына 50 шәр грамм эчлек, 5 әр грамм ак май салып чыгабыз. Өчпочмак формасына кертеп, чит-читләрен бөрәбез. Өчпочмак өстен йомырка сытып тугланган, сыр кушылган май белән майлыйбыз һәм 30-40 минутка мичкә тыгабыз.

Өйдә ризык әзерләү – бер нәрсә, ә аңардан бизнес ясау – бөтенләй башка. Ничек килдегез моңа, һәм, иң мөһиме, унбиш еллап инде көндәшләрсез эшләрлек үз кәсебегезне ничек булдырдыгыз?

– Барысына да ирем «гаепле». Ул гаҗәеп кеше иде. Милләте белән грузин. Искиткеч тәмле пешерә иде. Безнең өйдә һәрвакыт грузин аш-суы, рус, татар ризыклары әзерләнде. Килгән кунаклар еш кына: «Нишләп, тәвәккәлләп, үз рестораныгызны ачмыйсыз инде?» – дип сорый башлады. 2001 елда бу эш катлаулы иде әле, шуңа, зурдан купмыйча, без башта кулинария цехы ачып карарга булдык. Мин кулдан пилмәннәр бөгәм, ирем хачапури өчен сыр ясый. Фирмабызның озын гомерле булу сере бик гади – бөтен ризыкны башта ук, үзебезгә пешергән кебек, җаныбызны биреп әзерләдек. Хәзер дә нәкъ шулай эшлибез. Инде даими сатып алучыларыбыз, зур цехыбыз, ашчыларыбыз бар. Теге заманнарда әле заказчылар табу да җиңел түгел иде, шуңа күрә туңдырылган продукциябезне машинага төяп, тиешле урыннарга илтеп бирә идек. Кибет хуҗалары белән килешүләрне үзебез төзибез. Хәтерлим, кереп, сорап, ялынып йөрүләрдән шулкадәр ояла идем. Әмма ирем мине гел әйдәкләп тора. Беренче елны без бар эшне дә икәү генә башкардык, әкренләп барысы да җайга салынды, беренче хезмәткәрләребезне эшкә алдык. Ә үз предприятиебезне ачуның икенче елында инде ирем бу дөньядан китеп барды. Берүзем калдым...

2016 елда предприятиебез оешуга 15 ел тулды. Шул арада үзем дә үстем, ныгыдым, әлбәттә. Көчле иренә аркаланып яшәүче 22 яшьлек тәҗрибәсез кыздан мөстәкыйль ханымга әверелдем. Ирем бар яктан да таяныч иде: дустым да, әти урынына калган кешем дә, бизнес буенча партнерым да булды ул. Мине күп нәрсәгә өйрәтте: эшне алып барырга, курыкмаска, тәвәккәл булырга. Аны югалтуның авырлыгын үзем генә беләм.

Сөйләгез әле, нинди иде ул?

– Ирем кызыклы кеше иде. 80 нче елларда студентлар кичәсендә таныштык аның белән. Шундук үзенә каратты. Яшенә караганда өлкәнрәк күренә, эрудицияле, юморга бай – чып-чын грузин инде. Ул да мине ошаткан. Бик озак артымнан йөрде, мине генә түгел, бөтен гаиләбезне кайгыртуны үз өстенә алды. Әти ташлап киткәч, кечкенә туганнарыма аякка басарга булышты, ә безгаиләдә ун бала! Рәхмәт аңа, барыбыз да укып чыктык.

Беренче очрашкан көннәрдә ул: «Минем өем – Грузия!» – дип кабатлый иде. Өйләнешеп, бергә тора башлагач, ватанына еш кайтып йөрде, кире әйләнеп кайтканда: «Сине сагындым, минем өем биредә икән», – дип әйтә башлады. Аның белән бик бәхетле идем.

Сүрия, көчле хатыннарның да кулыннан эше төшәме?





– Әлбәттә. Без бит хатын-кызлар. Әйе, көчлеләр, ләкин хатын-кызлар. Безгә башны куеп еларлык көчле җилкә булу кирәк. Ял базасында атналар буе яшәп, шуннан гына эшкә йөргән чакларым булды. Анда мин күбрәк верандада – чыбылдык эчендә йокладым, табигатьтән энергия алдым. Мин бик аралашучан, дусларым да күп, ләкин үз-үземә бикләнеп, ялгыз гына каласы килгән чаклар да булды. Мондый очракларда иң яхшы табиб – табигать...

Тормышыгызда иң бәхетле көнегезне атагыз әле?

– Андый көннәрем байтак минем. Мәсәлән, узган ел парапланда очып карадым. Нибары бер сәгать! Әмма әйтеп бетергесез бәхет кичердем! Хәтта ул видеоны Фейсбукка куярга да кыймадым – куанычтан, сокланудан кычкырып елавымны бөтен кеше аңламас дип курыктым. Дусларым күп, туганнарым исән-сау – бу бәхет түгелмени?! Кайчак акча юклыктан, кемдер кәефне кырудан зарланган булабыз. Болар барысы да вак-төяк. Без исән-сау, менә шул инде ул бәхет. Ә иң бәхетсезе... Иң якын кешемне – иремне югалткан көн...

Сезне нәрсә куркыта?

– Бүген мине бернәрсә дә куркытмый. Якыннарыңны югалту гына бик авыр. Яшәү белән үлем һәрчак янәшә йөри, һәм без моның белән ризалашырга, аны шулай кабул итәргә тиеш.

Бүгенге эшегез булмаса, кем булырга теләр идегез?

– Ирем авырый башлагач, гел курку халәтендә яшәдем. Сулыш алуыннан ук хәлен аңларга, уколлар ясарга өйрәндем. Мин, мөгаен, табиб булып, кешеләрне дәвалый алыр идем дип уйлыйм.

Сез кешеләрдә беркайчан да нәрсәне гафу итә алмас идегез?

– Катлаулы сорау... Хыянәтнедер, мөгаен. Ләкин еллар узу белән, моңа да башкача карый башладым. Тормышымда төрле хәлләр булды, әмма мин аларны үткәреп җибәрергә, кичерергә өйрәндем. Дөрес, хыянәтне белү, аңлау һәм алга таба бара алу бер дә җиңел түгел. Ләкин тормыш биргән иң кыйммәтле сабакларның берсе бу.

Бер әби шалтыратып: «Кызым, рәхмәт сиңа!» – дисә, шуннан да зуррак мактау юктыр.

Балачагыгызның иң якты хатирәсе?

– Яшелчә бакчасы бар иде. Без, бала-чага, арыш ипиенә сарымсак сылап, тоз сибеп, урамга чыгабыз. Бакчада редиска, кыяр үсә, чарлакта капчыгы белән кипкән балык утыра. Дөньяда иң тәмле ризык шулар булгандыр. Без, ашарга да кайтып тормыйча, көннәр буе уенда әвәрә килә идек. Хәзер урамда бала-чага күрмәссең, хәтта авылныкылар да интернетта утыра.

Тормышта бернәрсә дә очраклы булмый, диләр. Сез моңа ышанасызмы?

– Ничек кенә ышанам әле! Безнең предприятие исемендә тикмәгә генә «9» саннары тезелеп тормый. Цехны «Мелия 999» дип атаганда ук «тугыз»лының минеке икәнен аңладым. Юктан гына түгел бу! Әйе, тормышта бернәрсә дә очраклы гына килеп чыкмый дип, мин гел әйтәм: шуңа күрә юлында очраган әнә шундый билгеләрне күрә, тыңлый белергә кирәк. Кешенең үзеннән, аның холкыннан да күп нәрсә тора әле. Позитив булсаң, тормышны яратсаң – барысы да әйбәт килеп чыгачак!

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

АХИРӘТЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР

(уены-чыны бергә)



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

ДУС КЫЗЫГЫЗ КИЯҮГӘ ЧЫККАНЧЫ, СЕЗ ТИГЕЗ ИДЕГЕЗ: ИКЕГЕЗ ДӘ УКЫЙСЫЗ (ЭШЛИСЕЗ), БЕРГӘЛӘШЕП ЯЛ ИТӘСЕЗ, КҮҢЕЛ АЧАСЫЗ, ШАТЛЫКЛАРНЫ БЕРГӘ УРТАКЛАШАСЫЗ, ХӘСРӘТЛӘРНЕ БЕРГӘ, ПРОБЛЕМАЛАРНЫ ИҢГӘ-ИҢ КУЕП ХӘЛ ИТӘСЕЗ.

Матурлык салонына барсагыз, берегез – массаж, икенчегез маникюр ясата; кибеттә дә бер-берегез өчен – стилист. Маҗараларны бергә табасыз – борылып карасаң, сагынып сөйләрлек хатирәләр шактый. Егетләр мәсьәләсендә фикерләр бераз үзгә булса да, социаль хәлегез уртак: икегез дә менә дигән булачак кәләшләр... иде.

Һәм көннәрдән бер көнне ахирәтегезнең күкләрдә укылган никах сәгате сукты да, ул ир хатынына әйләнде. Аннан, тугыз ай узуга, әни булып куйды. Әйтерсең лә, тормыш эстафетасындагы таякны ул алданрак эләктерде...

Юллар әкренләп аерыла кебек – һәркайсыгыз үз дөньясында яши хәзер. Әмма дуслыктан алай гына баш тартып буламыни? Һәм көннәрдән бер көнне сез ахирәтегезгә шалтыратып, кунакка килергә җыенуыгыз турында хәбәр итәсез. Бу җөмләдә «кунакка» сүзен кызыл белән язасым килә, чөнки ахирәтегез бәби тапканчы аларга кунакка килеп йөргән булсагыз, монысы ул барулардан бөтенләй аерылачак.

Иң яхшысы: бәбигә нинди бүләк алып килергә икәнен алдан белешегез. Әлбәттә, сез, үзегезчә, матур да, кыйммәтле дә бүләк алырга мөмкин. Ләкин бәби тугач, аны туганнары, якын кешеләре киләсе ике-өч елга җитәрлек кием-салым, уенчык белән тәэмин итеп куя: сезнеке меӊ дә беренче күлмәк булуы ихтимал. Бу – беренчедән. Икенчедән, әни кеше балага әйбер алганда, һәрнәрсәнең составын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыга, зыянлы булырдай әйберләрне матур, дип тормый, бракка чыгара. Хәтта ки дус кызыгызның моңа кадәр андый гадәте булмаса да, ул сез күрмәгән арада кинәт кенә параноикка әйләнгән. Ә менә кабы белән подгузник алсагыз – оттырмассыз. Дус кызыгыз моның өчен сезгә әле бик озак рәхмәт укыр. Бигрәк тә эшкуар яки күп акчалар алып эшли торган түрәгә кияүгә чыкмаган булса, ихтимал, ул әле коляска, карават һәм бала өчен кирәкле булган бихисап әйберләрне сатып алганнан соң, экономияли дә башлагандыр. Ни дисәң дә, өч кешелек гаиләдә бер эти кешенең генә эшләве сиздерә ул.

Үзенә бүләккә исә яраткан авторының яңа китабын алып килергә була. Моның белән сез дус кызыгызның бу дөнья кешесе икәнен исенә төшерерсез. Югыйсә соңгы ике-өч айда ул үзе турында бөтенләй онытты, кибеткә чыкканда (кибеткә чыгу – дөнья тирәли сәяхәткә тиң!) балалар әйберләре сатыла торган бүлектән узганы юк. Ә инде кайчандыр интеллектуалка булуын социаль челтәрләрдә бик күптәннән яңартылмаган сәхифәләре генә искә төшереп тора. Аның каруы, ул хәзер педиатрия буенча үзе дә күпмедер дәрәҗәдә лекцияләр укый ала. Теләсә кемгә, хәтта сезгә дә. Шуңа да тамак кырып, бу турыда вакыты җиткәч сорашырмын әле, дип бүлдерергә дә мөмкин.

Ишек ачылуга дус кызыгыз урынына аңа охшаган кешене күрсәгез, аптырап калмагыз. Бу – ул, ләкин бизәнмәгән, бары түгәрәкләнгән генә. Кайчандыр үзенә генә күңелсез булмасын өчен сезне дә мәҗбүри диетада тоткан кеше шушы инде, шушы. Бәлки болай күбрәк тә килешәдер әле үзенә. Гәрчә бала тапканнан соң, котылгысыз рәвештә үзенә сөйрәп ала торган депрессия галәмәте дә булырга мөмкин аның бу кыяфәте. Әгәр шулай икән, сез – аның өчен коткаручы. Бүген генә булса да.

Кайчандыр юылмаган савыт тормасын, дип, яңа пешкән ашны да түгеп, кәстрүлен юып куя торган дустыгызның раковинасына күз салыгыз. Тау кадәр өелгәнме? Чәй кайнаган арада аны юа торсагыз да була.

Сүз уңаеннан, килешли аның яраткан ризыгын алсагыз да була. Баласына аллергия бирерлек булмаса, әлбәттә. Яисә, килгәч, үзегез пешерегез. Шулай ук кер үтүкләргә, дустыгызны ваннага юынырга кертеп җибәреп, бала карап торырга да мөмкин. Баланы киендереп бирүен сорап, урамга алып чыгып китәргә дә була. Иркенләп юынсын – соңгы ике-өч айда ул, бәлки, өстенә су гына коеп чыгадыр.

Әни кеше душка керүе турында «барабан кагып» хәбәр итә. Аның бу сүзе өйдәгеләргә сугыш игълан итү кебегрәк ишетелә.

Дус кызыгызның сезнең белән сөйләшеп утырырга да вакыты кала икән, иманым камил, ул сезгә бала тудыру йортында күргәннәрен сөйләячәк. Әзер булыгыз, сабырлыгыгызны туплагыз. Әлбәттә, сезнең өчен кызык тема түгел, чөнки сез әле анда булмадыгыз, сезнең өчен бикле дөнья ул. Дус кызыгызга исә анда күргәннәре турында кат-кат сөйләргә – эчен бушатырга кирәк.

Нишләп бу мәшәкатьләрне ире дә азрак үз өстенә алмый икән, дигән вәсвәсәле уй үтмәдеме башыгыздан? Дөрсен әйтәм, дус кызыгыз да бу хакта иренә үпкә белдереп караган инде. «Миңа булышмыйсың, без сине күрмибез, иртән китәсең, кич кайтасың», янәсе. Ире дәшмәде. Ләкин аның мәшәкатьләре дә бихисап булып чыкты: гаилә хакына эшли, аптекадан – дарулар, кибетләрдән бөтен кирәк-яракны алып кайта... Кайда ватылган, кайда кителгән – төзәтә. Квитанцияләр, кредитлар вакытында түләнеп бара, өйдә телефон, интернет ише коммуникацияләр төгәл эшләве – аның өстендә. Ял көннәрендә бала белән саф һавада йөри.

Йә ничек? Кунак булу ошыймы сезгә? Тизрәк кияүгә чыгып, бәби алып кайтасы килү теләге сүрелмәдеме әле? Арыдыгызмы? Ахирәтегез хакына түзәсез инде: ул көн дә башкара бит бу эшләрне. Аның һәр минуты исәптә, эш режимыннан бераз тайпылдымы, бөтен көненең асты-өскә килә. Шуңа да кунакка килгәч, сезгә тиешле игътибар күрсәтә алмаса, үпкәләмәгез. Ярдәм итегез, югыйсә нинди ахирәт инде сез? Ул моны гомерендә дә онытмаячак. Һәм үз чиратында сезгә дә шундый ук игелекләр кылачак. Әгәр оныта икән – бигайбә. Игелек эшлә дә суга сал, диләрме әле?

P. S. Һәм сез шалтыратканда, телефонын алмаса, зинһар, үпкәләмәгез. Юк, ул эреләнмәгән. Борынын да күтәрмәгән. Ул элеккечә сезне сагына, хөрмәт итә, дуслыкның кадерен белә. Телефон алмавының сәбәбе исә бик гади – вакыты юк. Вакыты булгач, үзе шалтыратыр. Бүген булмаса, берәр айдан.

PRESSA.RU

ТӘҮЛЕКТӘ – 48 СӘГАТЬ!



...Менә шулдыр инде рух көче
Нәсел җебе аша бирелгән,
Гыйлемлелек, күңел сафлыгы,
Чын ярату туган иленә...
Гүзәлия ЗАКИРОВА

Лилия ГӘРӘЕВА

«И АПАЕМ, БЕР ҮЗЕГЕЗ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ ӘЛЕ. ӘЙТЕП КЕНӘ АҢЛАТЫП БУЛМЫЙ, КИЛЕП КҮРЕРГӘ КИРӘК АНЫ!» АЗНАКАЙДАН БЕР ШАЛТЫРАТТЫЛАР, ИКЕ... АХЫР КИЛЕП, КЫЗЫКСЫНУ ҖИҢДЕ.

Азнакай район советының оештыру бүлеге җитәкчесе Эльвира Галиеваның гына түгел, Азнакай хатын-кызларының да тормышын үзгәрткән җәй иде бу – 2014 елның җәе. Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумыннан бик илһамланып кайтты ул. Юл буе күңелендә бер уй бөтерелде: «Башкалар булдырганны алар эшли алмыймы? Андый кызлар әллә бездә юкмы? Безнең үзебезгә дә «Ак калфак» оешмасына керергә кирәк». Азнакайның көнчыгышына да, көнбатышына да телефоннар зең-зең хәбәр итте: «Кызлар, җыелышыйк әле!» Берсе дә, юк, димәде, нигә кирәк, дип шик белдермәде. Бертавыштан күтәреп алдылар: «Үзең җитәкләсәң, без хәзер үк синең арттан тезелеп басабыз». Бу ышаныч – еллар буе гадел хезмәт, ихлас тырышлык белән яуланган ышаныч. Әнә шул көннән, Азнакайның район советы аппараты җитәкчесе Айдар Хәлиуллин әйтмешли, моңарчы рәсемнәрдән генә белгән «Ак калфак»ның үзен дә күрде алар, көчен дә тойды.

Эльвира Галиева – Азнакай кызы. Монда аның үзен генә түгел, әти-әнисен – Сәйлүн абый белән Нәгыймә апаны да яхшы беләләр. Акыллы, хөрмәткә лаек гаилә. Эльвира – әти кызы иде. Хокук өлкәсенә кереп китүе дә әтисе сүзен тыңлап. Юрист булам дип хыялланмаган иде югыйсә. Әтисе ялгышмаган, кызының җанына, рухына нәрсәнең якын булуын дөрес абайлаган.

Үз өендә бәхет тапканда гына кеше чын-чынлап бәхетле була. Әлеге билгеләмә асылында нинди генә мизгелләрдә дә көчле иңен куярдай ирең булу, мәхәббәт җимешләрең – балаларыңның шат авазларын ишетү торадыр. Роберт Альберт улы белән яшьлекләренең гүзәл мизгелендә кавыша алар. Гаиләнең беренче куанычы булып кызлары Луиза дөньяга килә. 2002 елда уллары Артур туа. Шул ук елны кулына Казан дәүләт университетының хокук белгече дипломын ала (монысы да икенче тапкыр), фатирлы булалар.

Бәхетле, бик бәхетле Эльвира. Бәхет канатларында очып кына йөри. Алган белеме буенча, суд системасында эшлисе килә иде – анысы да чынга ашты. Суд ишеген ачып кереп, берәр эш булмасмы, дигән көннәр әле кичә генә булган кебек. Кеше урынына дип кенә алганнар иде, бер елдан – канцелярия мөдире, аннары судья ярдәмчесе булды, инде тагын бер елдан суд администраторы итеп куйдылар. Тырыш, эшчән кешеләр күп ул. Эшне бик оста итеп оештыручылар да бар. Тик шулай да кешеләрне үзенә ышандыра белүчеләр күбрәк уңышка ирешә, ахрысы. Эльвира Сәйлүн кызында тырышлык та, оештыра белү дә, ышандыру көче дә бар.

Район советының оештыру бүлегенә җитәкче итеп эшкә чакырганда, аның нәкъ менә шушы сыйфатларын күргәннәрдер. Булдыра аласына башкалар ышанса да, үзенең генә мондый зур эшкә алынырга егәре җитмәс күк иде. Алай да район башлыгы Шәйдуллин Марсель Зөфәр улы уйларга вакыт биргән иде аңа. «Син аны булдырасың», – дигән сүзләре дә ышаныч өстәгәндер... Әйе, эше четерекле, районда нинди киңәшмә яки чара буласын, кайсысына кемнәрне чакырасын – барысын да башында тотасы. Боларга өстәп, мәдәни, социаль чаралар... «Азнакайның патриоты ул. Без аны культмассовый сектор дип йөртәбез. Райондагы мәдәни чаралар да, спорт ярышлары да аның тәкъдиме белән уза. Әле болар гына түгел – җиң сызганып, районның иҗтимагый эшләрен дә тартып бара ул. Азнакайның «Ак калфак» оешмасын җитәкли. Хәзер бездә бернәрсә дә «Ак калфак»ларсыз узмый», – ди район Башкарма комитеты җитәкчесе Айдар Шәмсетдинов аның турында.

...Ак калфак. Бу ике сүздә ниндидер затлылыкмы, сер диимме, кодрәтме – ниндидер мәгърур көч бар. Дөньяны матурлык яшәтә, диләр, дөньяны хатын-кыз яшәтә. «Алай итәсе иде, болай үзгәртәсе иде», – дип, гел чеметкәләп тормаса, тормыш үз көенә мыштым гына барыр иде шунда. «Бәгырьне корыттылар инде», – диләр алар турында. Үпкәләп, каты итеп әйтелгән сүзләр түгел бу. Яратып, аларның тынгысызлыгына күрә әйтелгән сүзләр. Тормышның кайсы гына өлкәсен алма, бар җирдә дә алар – «Ак калфак»лар.

Азнакайлар аны идеяләр генераторы дип атый.

Җиләк бәйрәмнәре

Болын тулы кып-кызыл җиләк. Яше-карты ярышаярыша җиләк җыя. 200 чиләк, 300 чиләк... Ятимнәр, картлар, гариппләр – берсе дә өлешсез калмас. Кичен җиләк бәлешләре пешереп, ишегалды белән ишегалды, урам белән урам берләшеп, күңел ачарлар.

Җиләк өмәсе уздырырга дигән тәкъдим дә «Ак калфак» кызларыннан чыкты бит. Район башлыгы Марсель Зөфәр улы да хуплады аларның бу тәкъдимен. 2011 елда районны җитәкләргә алынганнан бирле, азнакайлылар яңа җитәкчеләренең кешелеклелеген тоеп яши. Лаеклы ялга чыкканда һәрбер райондашын үзе барып котлаган район җитәкчесе тагын бүтән бар микән?!

Яратты бит халык Җиләк өмәсен. Хәзер инде әнә бөтен район белән чыгалар. «Без дә чыгабыз», – дип, оешмалар үзләре үк теләк белдереп тора. Ә бит эш җиләктә генә түгел. Күмәклек, янында ярдәмгә мохтаҗлар барын күрү, аларны сөендерүдән тәм табу – «Ак калфак»ларга аның менә шунысы кадерле. Җиләк чоры тәмамлангач, бергәләп мунча миллеге бәйләргә чыгарлар, аңа дару үләннәре җыючылар кушылыр. Урман нигъмәтләренең берсе дә әрәм булмас. Ятимнәр һәм картлар йортларына бүләк иткәннән артып калганнарын шәһәр мунчасына илтерләр, алары белән өлкәннәр көнендә әби-бабайлар кинәнер.

Бишек җырлары

Йокла балам, йом күзең,
Йом-йом күзең, йолдызым...

Кичә генә әнкәсе куенында тирбәлгән нарасыйлар, тәрбияче апаларының иркәләп кенә җырлаганына изрәп, йокыга куера. Без белмәгән илаһи бер көч бар-

PRESSA.RU



■ Җиләк өмәсе көнне Азнакайда болын сыеннан авыз итмәгән кеше калмый. Үзе йөри алмаганнарга өй саен өләшеп чыгалар.



■ Иң газиз, иң ышанычлы кешеләрем – гаиләм.

дыр кебек ул җырларда: «...изге теләк теләрмен, бәхетле бул диярмен...» Сүзләрнең һәркайсы – бер формула. Яхшы сүз, изге теләк – бәхет формуласы. Яхшы теләк белән йокыга киткән, «үс-үс» итеп уянган бала кечкенәдән бәхет тәмен тоеп үсә.

Аның бит монысы да шул «Ак калфак»лар керткән яңалык. Бүген Азнакайның алтынчы балалар бакчасындагы сабыйлар: «Әйдәгез, яттык һәм күзләрне йомдык!» дигән фәрман белән түгел, «әллүки-бәллүки» дигән йомшак-моңлы көй белән йокыга китә. Балаларны бишек җыры белән йоклаткан бакчаны күрергә дип, кайлардан гына килмиләр хәзер. Бишек җырларын хәтта китап итеп тә чыгарган азнакайлылар.

«Ак калфак»ның кыйбласы – милли традицияләрне онытмау, гаиләләрнең таркалуына юл куймау.

Кемгәдер, бәлки, болар вак нәрсә булып тоелыр. Әмма шушылай бөртекләп барламасаң, халыкка күрсәтеп бирмәсәң, алар онытылачак. Онытылып баручы мирасыбыз болай да аз түгел. «Ак калфак»лар әнә шул мирасны барлап, аңа заманча сулыш өреп, яшьләрне кызыктырырлык итеп кабат яңартырга тырыша. Ел да үтә торган «Чатыртау җыены» да, «Сөмбелә», «Нардуган»нары да, «Орчык бәйрәме» белән «Карга ботка»сы да шуның өчен бит – иртәгә оныкларыбызга кызыктырып сөйләрлек сүзебез булсын, менә болары – безнеке, дип күрсәтерлек мирасыбыз калсын өчен.

«Пар канатлар» клубы

Клуб турында сөйләргә керешкәнче Эльвира Сәйлүн кызы үзе белән булган бер хәл турында искә төшерде. Кичләтеп кенә аларның ишегән бер әби шакый. Адресын да каяндыр белгән бит! «Кызым, миңа бер бабай табарга булышыгыз әле. Мин аңа иртән коймаклар пешереп, чәй эчертер идем. Ялгызы тилмергән берәр бабай юк микән?»

Шушы очрак димчеләр клубына старт биргән башлангыч була да инде. «Авыл саен «Ак калфак»лы кызларыбыз бар. Ул авылларда ничә егетнең өйләнмичә йөрүен дә, ничә кызның кияүгә чыкмаганын да беләбез. Кавыштырыйк без боларны», – дип, утырышларының берсендә уртага салып сөйләшәләр дә, димчеләрсез булмый дигән фикергә киләләр. Беренче эш итеп авылларда яшәүче ялгыз кешеләр барлана, аннары анкеталар төзелә, кемнең кемгә тиң булыры ачыклана. Аннары инде якын-тирә авылларда яшәүчеләрне чакырып, кичәләр уздыралар. Бик җанлы, кызык уза икән ул кичәләр. Бер очраштырдык та, калганын үзләре карасын инде, димиләр. Бер-берсен ошатып калучылар булса, аларның икесенә берәр концертка яки кафега чакыру бирәләр. Максатлары – районда ялгызлар санын киметү генә түгел, яшьләрне кавыштырып, балалар санын да арттыру. Уңышлары да бар. Мәсәлән, узган ел бу клуб Азнакайда биш парны кавыштырган. «Без моны – җиңү, дибез. Кешеләр үзләренең парларын тапса, ялгыз картаймый, картлыгын картлар йортында үткәрми, дигән сүз бит ул», – ди Эльвира ханым, һәр кушылган пар өчен ихлас шатланып.

Һәр эшнең үзенең бирелеп эшли торган кешесе кирәк. Азнакайда гаиләгә зур игътибар бирүләрен күреп кайттык. Аерылышырга дип гариза тотып килгән яшьләр белән хәтта район башлыгы үзе сөйләшә монда. Һәм, беләсезме, файдасы тия шуның – ун парның алтысы, гаиләне җимерү ниятеннән ваз кичеп, култыклашып кайтып китә. «Пар канатлар» клубының җитәкчесе, ничә еллар ЗАГС мөдире булып эшләгән «Ак калфак»лы Лена Мохтәрова тагын бер кызыклы мәгълүмат ирештерде, бәлки, башка районнарга да аларның эш тәҗрибәсе ярап куяр: алар яшьләрнең



■ 2015 ел, 10 декабрь. Азнакайның «Ак калфак» оешмасы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Рәхмәт хатына лаек булды.

гаиләне таркатырга дигән гаризасын кабул иткәнче, башта ике якның да әти-әниләре белән сөйләшә. Хәер, «Ак калфак»ларның максаты – гаиләне корганда ук нык нигезле итеп коруга ирешү. Өйләнешергә гариза биргән яшьләргә тормышның төрле өлкәләренә караган дәресләр уздырулары да шул нигезне ныгыту өчен. Гаилә бюджетын да колачлый ул дәресләр, психологияне дә, балалар тәрбиясе шәригать хөкемен дә...

Армиягә хатлар

Түгәрәк өстәлгә тезелешеп утырып, «Ак калфаклар» хат сырлый. Күптин-күп сәламнәр – Азнакайның армиядәге егетләренә. Яңа ел алдыннан, Илаһтан гаҗәеп бер могҗиза көткәндә барып ирешәчәк ул хатларда исән-имин хезмәт итеп кайт, дигән изге теләк тә, син безнең горурлыгыбыз, дигән мактау сүзләре дә бар.

Кечкенә генә бер гамәл инде. Ә шул егетләр армиядән кайтып: «Эльвира апа, рәхмәт Сезгә. Хатыгызны алгач, бик күңелле булды», – дип рәхмәт әйтергә кергәч, җанга шулкадәр рәхәт. Димәк, алар дөрес юлда, гамәлләре бушка кылынмаган.

Кемгә генә булмасын – олы яшьтәме, яшь кешеме – һәркайсына җылы сүзен әйтеп, күңеленә юл таба белүче, эш, тормыш, гаилә мәшәкатьләрен хәл итү юлларын төгәл билгели алучы, киңәшләре белән ярдәмгә ашыгып торучы көчле рухлы кеше Эльвира ханым. Азнакай хатын-кызлары аны үзләренең киңәшчесе, ярдәмчесе итеп күрә. Һич онытасы юк: бер көнне бүлмәсенә хәсрәте йөзенә чыккан ханым килеп керде. Уллары армиягә киткәч, ире белән аерылышкан булганнар. Әтисе, күрәсең, улына әнисен гаепле итеп язгандыр – ана белән бала арасында элемтә өзелгән. Хат язудан да туктаган егет, әнисе шалтыратканда телефонын да алмый. Эльвира шул частька үзе шалтырата, егет белән иплəп кенә сөйләшә – ана белән бала күңеленә күпер сала.

Югалган авыллар

Басу уртасында – яшел утрау,
Учма-учма каен, наратлар.
Яшел сагыш булып сибелгәннәр
Авылларсыз калган зиратлар.

Бу юлларның авторы шагыйрь Илдус Гыйләҗев үзе дә Азнакай төбәгеннән. Кешелекнең ялгышымы, язмышымы – Җир йөзеннән нигез урыннары гына түгел, гасырлар буе каен, наратлары шаулаган зиратлары белән юкка чыккан авыллар бар.

Истәлеккә сыңар ташы да калмаган мондый авыллар турында Татарстанда беренчеләрдән булып Азнакайның «Ак калфак» кызлары сүз кузгата. Шушы район җирлегендә генә дә 69 авыл җир йөзеннән мәңгегә юкка чыккан. Аларны ачыклау, тарихларын барлау кайчандыр шушында яшәүчеләр белән очрашып сөйләшүдән, архив белешмәләреннән башлана. Азнакайның югалган авыллары турында истәлекләрне барлап, китап итеп тә бастырып чыгарганнар. Димәк, алар китап битендә генә булса да яшәешләрен дәвам итә, хәтердән җуелмый.

Йомшак кебек кенә күренсә дә, Эльвира ханым – эшен җиренә җиткерүче таләпчән җитәкче.

Азнакай районының Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Гыйләҗев белән Ташлы Ярга – татар халкына танылган артистлар Нәҗибә Ихсанова белән Әзһәр Шакировларны биреп, бүген Җир йөзеннән юк булган авыл урынына юнәләбез. Кайчандыр монда тормыш кайнаганын күккә ашкан мәгърур стелла гына сөйли. Без килгәндә басу җиле аңа шыпырт кына нидер пышылдый иде. Мөгаен, кайчандыр бу җирдә яшәгән кешеләр турында сөйләве булгандыр.

...Азнакай–Казан арасы якын түгел. Кардан ачыла башлаган басуларга карап, «Ак калфак»лы кызларны уйлап кайтам. Кыш көне бу басулар нинди калын кар катламы астында иде. Кояш көн дә җылыта торгач, ул карлар да бер көн эри, кар астында яткан кара җир ачыла. «Ак калфак» кызларын да шул кояш белән чагыштырам. Алар да бит, еллар катламын эретеп, халкыбызның никадәр җәүһәрен көн күзенә чыгара алган.

«Ак калфак»ның игелекле гамәлләре турында язар сүзләр күп. Әмма... аларның милли кием модасына яңа сулыш өреп, калфактан һәм милли чигешле матур күлмәкләрдән йөрүләрен дә, «Ак калфак» оешмасының һәр әгъзасына район башлыгының шәхсән үз кулы белән ак калфак бүләк итүен дә, авыр тормышлы гаиләләрне шефлыкка алуларын да җиткерә алмадым әле мин. «Ак калфак»лар үҗәтлеге белән булдырылган «Гаилә» һәйкәле дә, борынгы һөнәрләребезгә өйрәтүче мастер-класслар да караламада гына калды...

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

КАЛЫР ТИК АТЫҢ...



Гүзәлия ХАҖИЕВА, филология фәннәре кандидаты

ИСЕМНӘР ЯСАЛЫШЫНДА ИҖЕК ЯКИ АВАЗЛАРНЫ КУШУ, ТИТУЛ СҮЗЛӘР ЯКИ САННАР НИГЕЗЕНДӘ АББРЕВИАЦИЯ ЮЛЫ БЕЛӘН ЯСАЛГАН ИСЕМНӘРНЕ ТЫЮ ТУРЫНДАГЫ КАНУН ПРОЕКТЫ ТАТАР ҖӘМГАТЬЧЕЛЕГЕНДӘ ЗУР РЕЗОНАНС УЯТТЫ.

Әлеге закон проекты тормышка ашкан очракта милли исемиятебездә хәзер популяр булган кайбер исемнәр тыелырга мөмкин дигән фикер дә күпләрне борчый.

Әлеге канун проекты турында фикер төрлелеге күзәтелә: бер яктан, дәүләтебездә исем сайлауны җайга салырга тырышу бар; икенче яктан, бу яңа канун ата-ана, бала хокукларына каршы килә дигән фикерләр ишетелә. Дәүләтнең әлеге адымын ата-аналарның исем сайлауда чиксез иҗадилыгын контрольгә алырга, мәгънәсез исем бирүне бераз чикләргә омтылу дип аңларга кирәк.

Мәсьәлә, чыннан да, бар һәм борчылырлык. ЗАГС идарәсе хезмәткәрләрен дә ата-аналарның мәгънәсез, кайбер очракларда башка сыя алмаслык исемнәр кушу белән мавыгуы шөбһәгә сала икән.

Татарлар гомер-гомергә балага исем бирүгә җитди якын килеп, исемнең мәгънәсенә нык игътибар иткәннәр.

Укымышлылыгы белән аерылып торган, гарәп-фарсы, рус-европа телләрен дә белгән халкыбыз исемнәрнең мәгънәсенә битараф булмаган. Исем сайлауга, исем бирү йола-гадәтләренә һәрвакыт җитди караган. Халык арасында матур, мәгънәле исемнәрне популярлаштыру максаты белән, XIX гасыр ахырында муллалар «Исме Аллаһы Тәгалә әл-Хәсәни» [1848], «Авраде Фәтхия» [1865] кебек сүзлекләр бастырып чыгарганнар. Бу китапларда ислам дине кагыйдәләре һәм кануннары нигезендә исем кушарга һәм сайларга кирәклеге ассызыкланган.

XX гасыр башында дини учреждениеләрнең совет хөкүмәтеннән, диннең мәктәптән аерылуы, глобализация шаукымы татар тормышын да читләтеп үтми, һәм болар исем кушуга, исем сайлауга йогынты ясый. 1917 елгы инкыйлабтан соңгы антропонимия үсешен «антропонимик шаукым чоры» дип атап йөртәләр. Әлеге чор – аббревиатур, билгеле бер шәхескә багышланган исемнәрнең күп санда керүе белән билгеләнә. XX гасырның 20-30 нчы елларында татар исемнәре генә түгел, исем кушу йолалары да үзгәрә. «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 22 июнь санында эшче татар гаиләсендә туган бер кызга иптәш Троцкийга багышлап, Троцкина дип исем кушу бәйрәме үткәрелү турында хәбәр ителә. Этнографлар билгеләвенчә, XX гасырның 30 нчы елларыннан башлап, балага исем кушу яңача башкарыла башлый, әлеге йоланы «октябриналар» дип атыйлар, һәм алар митинг, җыелыш, котлау рәвешендә, еш кына доклад формасында үткәрелә. 1930 елда «Азат хатын» журналында ата-аналарга киңәш рубрикасында түбәндәге исемнәр тәкъдим ителә: Рафил, Марат, Фред, Ирек, Азат, Дамир, Вил, Рево, Ренад, Корыч, Эдвард, Альфред, Алмас, Илдус, Арыслан, Ким, Марс, Баян, Карл, Марсель, Марлен, Тимер, Радик, Батыр, Ук, Лерон, Илгиз, Роберт, Сталь, Денам, Ялкын, Зирәк; Роза, Клара, Флера, Гүзәл, Йолдыз, Рева, Рема, Гөлкәй, Кояш, Алсу, Ләлә, Ландыш, Марта, Бүләк, Луиза, Аида, Лера, Ариа, Майа, Иркә. Киңәш ителгән исемнәр арасында кыскартылма исемнәр дә бар: Дамир – «Да здравствует мир»; Вил – «Владимир Ильич Ленин»; Рев – «революция сүзеннән кыскартылган исем»; Ренат – «революция, наука и труд»; Ким – «коммунистический интернационал молодежи»; Марлен – «Маркс Ленин»; Рева – «революция сүзенең кыскартылма варианты»; Рема – «революция и Маркс сүзләренең кыскартылмасы»; Радик – «радий сүзенең кыскартылмасы» һәм башкалар.

Әлбәттә, антропонимик шаукымга бирелеп, тиз арада чорга хас исемнәр уйлап табарга тырышуны халкыбызның укымышлылыгына, зыялылыгына бәйләп тә аңлатырга мөмкин. Уку-язуга һәвәс, театр, музыка, кино сәнгатенә гашыйк халкыбыз чорга хас сәяси-иҗтимагый, мәдәни дулкын ташкынына тиз бирелеп китә. Шуңа күрә татарларда тиз арада яңа исемнәр барлыкка килә. Әлеге исемнәрнең күпчелеге XXI гасырда исем-символларга әверелеп, реаль тормыштан ераклашканнар, бүгенге көндә аңыбызның үткәндәге элементлары булып саклаLналар һәм... әле дә куелалар.

Үлемгә дучардыр тумыш һәр инсан.
Ләкин атың калыр, чын кеше булсаң...

Йосыф Баласагуни «Котадгу белиг»

XX йөзнең 20 нче елларыннан башлап, Ренат, Дамир, Эльмира кебек исемнәрнең күпләп кулланыла башлавы күзәтелә. Әлеге исемнәр шул чордан бирле татарлар арасында яратып кушыла торган исемнәргә әвереләләр. Кайбер исемнәрнең, шул ук Ренат исеменең, мәсәлән, латин телендәге renasor сүзенә бәйле булып, «яңадан туган» дигән мәгънәне аңлатуы билгеле. Казан шәһәре буенча үткәрелгән статистикага караганда, бу исем 20–30 нчы елларда активлашкан, ә 1990–1999 елларда исә иң күп кулланылыш алган, популярлашкан. Дамир исеме дә, мәсәлән, XX гасыр башында «да здравствует мир»ның кыскартылган варианты буларак килеп керә. Чынлыкта, аның мәгънәсен галимнәр тимер сүзе белән бәйләнелешле итеп карыйлар, шул рәвешле, Дамир исеменең семантикасын киңәйтәләр. Шуңа күрә тамырын-нигезен ныклап тикшерми торып, аббревиатур исемнәрнең кулланылышын чикләп куюның дөрес гамәл булмавы да ихтимал.

XX гасырның 90 нчы елларын алсак, бу чорда, милли күтәрелеш белән бәйле рәвештә, ата-аналар тарафыннан балага кемгә дә булса багышлап исем кушу тенденциясе күзәтелә. Мәсәлән, соңгы вакытта татарлар Минтимер исемен беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев исеменә нисбәтле кушалар. Әлеге шаукым 90 нчы елларда активлашып киткән иде. Халык арасында Илһам, Хәйдәр, Разил, хәтта татарга күпмедер дәрәҗәдә ят булган Роберт исемнәре татар халкының күренекле җырчылары Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичевка, атаклы шагыйрьләр Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллинга һәм башкалардан күреп кушыла. Халкыбыз күренекле затларына хөрмәтен әнә шулай чагылдыра.

PRESSA.RU

Татар антропонимик системасында Әмир, Әмирхан, Сәет, Солтан, Рәис, Мөдәррис кебек исемнәр дә татарлар тарафыннан яратып кушыла. Титуляр терминнар нигезендә ясалган мондый исемнәр татар антропонимик системасы үсешенең бөтен чорларында да кулланылып, хәзерге чорда ата-аналар арасында популярлыгын югалтмаган исемнәр булып саналалар. Татар антропонимик системасында сословие титулларыннан ясалган исемнәр иң борынгы катламга карыйлар. Әлеге титул компонентлары күп кенә төрки телләрдә дә билгеле.

Исем кушу, исем сайлауны җайга салу элек-электән дәүләтнең күз уңында булган.

Соңрак чорларда титул компоненты кергән исемнәрнең семантикасы турыдан-туры титулга бәйле каралмый башлый, ә теләк исем булып яңгыраш ала. Ир-егетләргә титул, чин компонентлы исем бирү – ул бала тормышта үз урынын тапсын иде, билгеле бер иҗтимагый биеклеккә менсен иде, матди ирек казансын иде дигән ата-ана теләкләренә нигезләнә. Шулай итеп, татар исем системабызда Солтанбай, Солтангали, Солтангази, Ханзафар, Ханморат, Ханзаман, Мирзагали, Мирзавәли, Мирзанур, Морзабәк, Морзабулат, Морзагаян, Шәехбулат, Шәехтимер, Шәехгали, Әмирхан, Әмирҗан, Әмиргали, Мирсафа, Мирвәли, Мирхатип, Сәетхан, Сәетгали, Сәетрәхим, Шаһбаз, Шаһгәрәй, Шаһнур, Тархан, Тарханбәк, Тархангол кебек исемнәр традицион нигездә титулга бәйләнешсез, теләк исемнәр рәтендә каралалар. Дини титуляр исемнәр дә татарлар арасында бик популяр була: Ахун, Ахунбай, Ахунҗан, Ишанбай, Ишангали, Ишангәрәй, Мулланур, Муллахан, Муллаәхмәт, Хаҗиәхмәт, Хаҗигали, Хаҗинур, Шәрифгали, Шәрифулла, Шәрифзадә һәм башкалар. Әлеге титуллар татар гаиләләрендә нәсел җебен бәйләү вазыйфасын да үти. Гаиләдә бер үк титулны гаилә әгъзаларының исемнәрендә куллану гадәти күренеш була. Мәсәлән, татар шәҗәрәләрендә бер үк детерминантларның берничә буынны бәйләп торуы билгеләнә. Мисалга, Карабәк шәҗәрәсендә исемнәрдә кулланылган бәк, морза компонентлары нәсел буыннарын тоташтырып тора торган компонент ролен үтиләр.

Димәк, татар исемиятендәге һәрбер исем – ул тарих, чор тарихы, гаилә тарихы, кеше тарихы. Исемнәр турындагы закон проектының тормышка ашуы милли республикаларның антропонимик системаларын исәпкә алып каралырга тиеш. Милли үзенчәлекләребездән ерак, мәгънәсез исемнәр бирү теләген чикләүдә дәүләтнең катнашуы, һичшиксез, кирәкле эш дип каралырга хаклы. Монда саксыз эш итүнең файдага караганда, зыяны күбрәк булырга мөмкин. Әлеге проектны тормышка ашыру бу өлкәдә эшләүчеләр белән берлектә башкарылса, галимнәр фикеренә колак салынса иде.





ХАТЫН-КЫЗ — ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР САГЫНДА

Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында «Нәүрүз» заманча татар милли сәнгате күргәзмәсе ачылу кысаларында «Сөембикә» журналы «Милли-мәдәни традицияләрне саклауда хатын-кызның роле» дигән темага «Түгәрәк өстәл» оештырды.

«Түгәрәк өстәл» янындагы сөйләшүне «Сөембикә» журналы җитәкчесенең урынбасары Рәмзия Кашапова алып барды. Сөйләшүдә катнашучылар арасында Төркия Республикасы Генераль консулы хатыны Анна Дилмач, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры Гөлзадә Руденко, Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы директоры Раушания Сәүбәнова, балалар киемнәрен җитештерүче Гөлнара Җиһаншина, Татарстан халыклары ассамблеясенең Алабуга муниципаль районындагы вәкиллеге директоры Зөләйха Эмирбекова, Казан федераль университетының Алабуга институтындагы татар филологиясе кафедрасы доценты Фәридә Габидуллиналар бар иде. Халык традицияләрен саклауда хатын-кызның роле турында шулай ук Алабуга районында яшәүче төрле диаспора вәкилләре дә сөйләде.

Заман хатын-кызы нинди булырга тиеш? Балаларны ничек итеп үз халкыңа, аның гореф-гадәтләренә мәхәббәтле итеп тәрбияләргә? Милләтне саклап калу өчен ниләр эшләргә?

«Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар, үз тормышларыннан мисаллар китереп, әнә шул сорауларга җавап бирделәр. Фикерләр уртак булды: туган телне саклау мәсьәләсе һәр халык өчен ул традицияләрне, милли үзенчәлекләрне саклап калу дигән сүз.

Иң яхшы милли сыйларны тәкъдим итеп, аш-су әзерләү традицияләре белән дә таныштырдылар.

Әлеге гамьле сөйләшүдән соң, кунаклар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының Күргәзмәләр залына, «Нәүрүз бизәкләре» күргәзмәсенең тантаналы ачылышына килделәр.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Республика җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов Дубайда VII Еллык инвестицион форум ачылышында катнашып, Дубай әмире, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Премьер-министры Мөхәммәд ибн Рашид Әл Мәктүм белән очрашты, Гарәп инвесторларын Татарстан Республикасы белән хезмәттәшлеккә чакырды.

■ Татарстан башлыгы Рөстәм Миңнехановка мәскәүлеләр үзенчәлекле Коръән бүләк иткән. Изге китап 2004 елны Ватикан типографиясендә, Иоһанн Павел II Атакай рөхсәте белән бастырылган, һәм ул бүгенге көндә Болгарда саклanучы дөньядагы бердәнбер зур басма Коръәннең күчермәсе.

■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов быелгы Сабан туен бәйрәм итү көне турындагы карарга кул куйды. Карар нигезендә, авылларда һәм район үзәкләрендә Сабан туе бәйрәмен 1 һәм 2 июль көннәрендә билгеләп үтү күздә тотыла. Чаллыда бәйрәм тантаналары – 8 июльдә, ә Казанда 15 июльдә үткәреләчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ Казанда туган тел һәм әдәбият укытучыларының «Туган тел» Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе – Татарстанның Арча районы Утар Аты мәктәбендә 21 елдан артык татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирүче Зөһрә Касыймованы тәбрикләделәр.



МӘДӘНИЯТ

■ Г. Камал театры матбугат чараларына «Дәрсе гыйбрәттер театр...» дип аталган өр-яңа проект тәкъдим итте. Һәрбер спектакльне нибары 20 тамашачы гына карый ала. Тамашалар, гадәти спектакль кебек, сәхнәдә түгел, ә театрның моңарчы тамашачы аяк басмаган почмакларында уйнала. Идея авторлары – Фәрит Бикчәнтәев һәм Нияз Игъламов, текст авторы – Рүзәл Мөхәммәтшин, режиссеры – Илгиз Зәйниев.

■ ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан оештырылган «Тантана-2017» театр премиясенең быелгы лауреатлары билгеле булды. Жюри җиңүчеләрне 12 номинациядә билгеләде. Әлмәт ТДДТ артисткасы Наилә Нәҗипова Я. Пулиновичның «Син кайда идең» спектаклендәге Эльза Александровна образы өчен – «Иң яхшы хатын-кыз роле», Г. Камал исемендәге ТДАТ артисты Рамил Вәҗиев «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә җиңү яулады.

■ Татарстан китапханәләре үз укучыларын бердәм укучы билетына күчерә. Билет шәхси штрих-кодлы пластик карта рәвешендә ясалган. Бүгенге көндә Татарстанда 1400 тирәсе китапханә 23 меңнән артык укучыга бердәм билет буенча хезмәт күрсәтә.

■ Татарстан Республикасы Рәссамнар берлегенең 80 еллыгына багышлап, Мәскәүдә «Татарстан – безнең күңел түрендә» күргәзмәсе узды. Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәмендә төзелгән экспозициядә иллеләп рәссамның эшләре күрсәтелде. Барлык авторлар да – Татарстан Рәссамнар берлеге оешмасы әгъзалары.

СПОРТ

■ Казанда гимнастика буенча балаларның III Olympico Baby Cup-2017 фестивале булып узды. Анда Россиядән, якын һәм ерак чит илләрдән меңнән артык яшь спортчы катнашты.

■ Башкалабызның Гимнастика үзәгендә нәфис гимнастика буенча Бөтенроссия «Триумф» ярышы узды. Россиянең 38 шәһәреннән спортчылар катнашкан бу чарада Казанның балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе вәкилләре дә чыгыш ясады.

■ Казанның Су спорты төрләре сараенда «Спортта чикләр юк» дип аталган социаль-белем бирү проекты тормышка ашырыла башлады. Балалар арасында ватанпәрвәрлек, туган җир белән горурлану, сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү һәм авыр тормыш шартларында калган балаларга ярдәм итүне максат итеп куйган әлеге чара Дәүләт Думасы депутаты, Россиянең атказанган тренеры Ольга Павлова җитәкчелегендә уза.

МӘГАРИФ

■ Түбән Камада – КНИТУның «Нефтехимия инжиниринг» үзәгендә балалар өчен «Кванториум» технопаркы эшли башлады. Монда балаларны наноквант, робоквант, нейроквант кебек яңа техник юнәлешләр белән таныштырачаклар.

■ Татарстанда узган «Кеше тәрбияләү» конкурсы кысаларында иң яхшы класс җитәкчеләрен һәм педагог-оештыручыларын атадылар. Түбән Каманың 27 нче мәктәбе укытучысы Светлана Гурьянова «Иң яхшы класс җитәкчесе» исеменә лаек булды, ә Чаллының 35 нче мәктәбеннән Наталья Тутова «Иң яхшы педагог-оештыручы» дип танылды.

PRESSA.RU



АК КАЛФАКНЫҢ ТАБЫЛГАН ЧАГЫ...



Эльмира ЗАКИРОВА

«ЗӨЛФИРӘ КАЕННАРЫ», «ЗӨЛФИРӘ БАЛАЛАРЫ» ДИГӘН ГЫЙБАРӘЛӘР АВЫЛНЫҢ БРЕНДЫНА ӘЙЛӘНГӘН, ДИЛӘР.

Йөзек кашына куярлык...

Һәр татар хатын-кызының калфагы булырга тиештер инде ул. Соңгы вакытта калфактан йөрү үзенә күрә бер күркәм гадәткә дә әйләнеп бара. «Ел хатын-кызы» бәйгесенә әнә Балтачлар кулдан ясалган уймак кебек нәфис калфаклар алып килгәннәр. Матурлар! Затлылар! Чәй тәлинкәсеннән дә кечерәк шул сувенир калфакларны кунакларга тараттылар. Ак көмеш җепләр белән каймаланган фирүзә төсендәге нәни калфакны кулыма алгач, аһ иттем! Нәкъ фирүзә күлмәгем төсендә! Залда «Зөлфирә калфаклары» дигән шыбырдау узды. Кем ул Зөлфирә? Җитмәсә, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлар оешмасы рәисе Кадрия Идрисова: «Ясле-бакчаларда кулдан төшми торган «Гөлбакча» китабының авторын син белмәскә инде?!» – дип, кем икәнен шундук искә төшертте! Бөтен татар дөньясы хатын-кызларына таныш Зөлфирә Камалова лабаса! Аспирантурада укыган, балалар бакчалары өчен 20 ләп методик кулланмалар авторы, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты, фәнни тикшерү җитәкесе...

Гасырлар аша җемелдәп, йолдызың янсын икән,
Йөзек кашына куярлык эшләрең калсын икән...

Зөлфирә Фәсхетдин кызы белән таныштыруны хатын-кызлар бәйгесендә әнә шулай шигъри юллар белән башлап җибәрделәр. Узган ел татар хатын-кызлары форумында мәгариф һәм тәрбия өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен Балтач районы «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Зөлфирә Камаловага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырганнар иде. Үзе белән якыннан таныш булмасам да, бу тынгысыз ханымның матур эшләре турында гел ишетеп, һәркайсыннан хәбәрдар булып тордык. «Бәби туе», «Бишек туе», «Исем кушу», «Ак калфакның энҗеләрен бөртекләп җыяр чаклар», «Шәҗәрә – безнең тамырлар», «Гаилә – бәхет таҗы» кебек бәйрәмнәр... Күбесе республика күләмендә уздырылган чаралар бит. Районда «Сүнмәс дәрт» ветераннар клубы оештыруын да, «Буйдаклар» клубындагы эшчәнлеген дә, ул үткәргән хәйрия чараларын да иркенләп аерым сөйләрлек.

Ә менә Зөлфирә ханым тормышында үзенә бер урын алып торган Карадуган чоры, «Ак каен» балалар бакчасы турында инде легендалар йөри. Зөлфирә апаларының «Карадуганым» шигыренә көй язып, яшьләр гимн итеп җырлый дип тә сөйлиләр. Барып күрәсе иде. Калфактан башланган сөйләшү юлга чакырды. Фотохәбәрчебез Ксения Богданова белән Балтачка кузгалдык.

Бер көрәшер өчен килдек без...

Мин инде Зөлфирә турында әз-мәз беләм кебек. Укыганнар, ишеткәннәр буенча хыялымда бик кызык образ туа. Хәзер менә, әкият сөйләгәндәй, читтән торып Ксенияне таныштырып барам.

– Арчаның Түбән Пошалымында гаиләдә бер кыз туа. Әти-әнисенең дүртенче кызы икән инде ул. Бик зәгыйфь, хәлсез була ул. Бу бала тернәкләнеп китә алмас, дип, әнисе хафага төшә. Зәңгәрләнеп беткән сабыйны күреп, туганнары Заһретдин Сабира әбиләренә баланы мичкә тыгарга киңәш итә. Төреп, катыргы тартмага салып, ипи көрәге белән җылы мич түренә урнаштыралар. Бәләкәй төенчекне мичтән алганда сабыйның инде йөзе кызарган, сулыш алулары ук башкача була. Яши бу, дип җиңел сулап куялар...

Карадуганнар, Зөлфирә апа каеннары, дип йөртә икән аларны.

– Әллә безнең героинямы? – дип кызыксына Ксения. – Сөйлә, сөйлә...

– Ут борчасы кебек җитез, шаян булып үсә ул. Тырышып укый, пионер, комсомол вожагы була. Көчле оештыру сәләтен белгәнгә, мәктәпнең өлкән пионер вожатые итеп куялар. Читтән торып педагогика институтын тәмамлый...

– Һәм көннәрдән бер көнне без барасы авылга эшкә җибәрәләр! – дип йомгак ясамакчы була юлдашым.

– Әйе... Ләкин ничек һәм ни өчен килгәнен белмисең әле. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытканда тормышка чыга. Тәвәккәлләп, Балтач СМУында эшләүчеләрнең балалары өчен ясле-бакча оештырып җибәрә башта. Яңалыклар кертеп, канатланып эшләп йөргәндә, Карадуган мебель фабрикасы директоры махсус эзләп килә аны. Фабрикада эшләүче бер хатын, карарга кеше булмагач, ике баласын да бикләп калдырып эшкә китә; плитә өстендәге кайнар су балалар өстенә төшеп, сабыйлар пешеп үлә. Бик борчылган директор тиз арада ясле-бакча төзү артыннан йөри башлый, булдыра алырдай мөдир эзли. Зөлфирәнең сәләтен әллә каян күреп ала ул! Бу 1979 ел була. Ә тәрбияче булу Зөлфирәләр нәселендә буыннан-буынга тапшырыла торган һөнәр икән. Бертуган апасы Фатыйма да балалар бакчасында мөдир булып эшли. Заманында әниләре Шәрифелҗамал Түбән Мәтәскә



PRESSA.RU

авылында «Сабира» балалар бакчасында мөдир була. Шәрифелҗамалның дәү әнисе Маһикамал исә революциягә кадәр үк инде Мөндеш авылында бер байда балалар карый. Менә шундый язмыш. Бүген инде Карадуган бакчасында Зөлфирәнең кызы Зөһрә – Бәдретдинова Зөһрә Фәрит кызы – мөдир! Мөдир вазыйфасын башкаручы династиянең бишенче буын дәвамчысы!

Телебезнең, җырларыбызның аһәңен сеңдереп, әдәп-әхлак кагыйдәләрен өйрәтеп, алар киләчәгебезне тәрбиялиләр...

Бишекләрдә – илнең киләчәге

«Ак каен» исеменең дә тарихы бар. Зөлфирә үзе уйлап тапкан. Мебель фабрикасында каен агачын күп кулланалар анысы. Аннары ак каен Зөлфирә Фәсхетдин кызының өч буыннан килгән гаилә символы да ди бит әле. Үз авылларында бабасы елга буенда каеннар үстергән, әтисе каен полосасы белән авылдашларын сөендергән... Зөлфирә дә хезмәттәшләре белән бергә ясле-бакча тирәсенә күп итеп яраткан агачларын утырткан.

...Карадуган безне тау башында утырган балалар бакчасы, зифа каеннары белән ерактан ук балкып каршы алды. Кул сузымында гына Арбаш, әнә генә Таузар, Түбән Шубан, Югары Шубаннар... Бал кәрәзе кебек сап-сары өйләре, зәңгәр, яшел, кызыл түбәләре белән Карадуган үзе дә таудан матур бер уенчык кебек күренә иде. Патша заманында ук Себер трактында утырган бу авылның этап төрмәсе, почта станциясе, трактиры булган, ул гөрләп торган. Бүген дә шулай. Анда – атаклы мәктәп, музейлар. Һәм, әлбәттә, анда данлыклы «Ак каен».

Алар безне әниле-кызлы каршы алырга чыктылар: 33 ел биредә эшләгән Зөлфирә ханым һәм чит телләр факультетын тәмамлап, әнисе эшен дәвам итәргә кайткан кызы Зөһрә. Кайчандыр әнисе Балтачтан көн саен йөреп эшләгән, хәзер инде кызы Балтач белән Карадуганны бер итеп йөри. Хәер, апасы Энҗенең дә эше җаваплы – Балтач муниципаль район башлыгының ярдәмчесе ул.

Без, әйтерсең, затлы, аллы-гөлле чәчәкле шарык дөньясына килеп эләктек! Бизәкле келәмнәр, диварларына кадәр чәчәкләргә күмелгән зәвыклы бүлмәләр, ап-ак япмалар белән тышланган диван, чигүле сөлгеләр, ал пәрдәләр, бик күп гөлләр, әллә нинди рәхәт бер халәткә күчерде. Барысы да калфаклар, бердәй ак якалы фирүзә күлмәкләр кигән тәрбиячеләрне исемләп таныштыралар. Илсөяр белән Резеда – «Бөтерчекләр»нең апалары икән. «Шаяннар» инде Раушания, Зилә апаларына гына карап тора. «Тиктормаслар» өчен Наҗия, Эльмира апаларыннан да якыны юк. Тагын әле «Логопед» төркеме бар. Анда йөрүчеләрнең дә үз Әкълимә, Гөлнур апалары. Дилә апалары исә балаларны русча сөйләшергә өйрәтә. «Ак каен»ның калган хезмәткәрләре дә бакчаның нурлы йөзен балкытып йөриләр. 2015 елда, билингваль балалар бакчасы буларак, Гранприга лаек булганнар. Илһамия апалары музыка тәрбиясе бирә. Күңелне җәлеп иткән калфаклар, тәрбиячеләрнең затлы күлмәкләре Әнисә апаларының кул җимеше икән. Эшмәкәрләр ярдәме белән булдырылган релаксация бүлмәсендә талгын музыка яңгырый, паннода йолдызлар балкый, Чижевсий лампасы яна. Ял иттерә торган рәхәт бер халәт!

«Безнең Карадуган балалар бакчасы милли тәрбия бирү буенча эш алып бара. Миллилекне саклап калу өчен шундый тәртип керттек: һәр бала үзенең түбәтәе, калфагы белән килә бирегә. Тәрбиячеләргә махсус күлмәк һәм калфаклар тектердек...» Мөдирнең шул сүзләрен кайта-кайта искә төшерәм. Милләт зыялылыры менә кайда үсә икән!

Кызыл келәм түшәлгән баскычлар аска алып төшеп китә. Ике катлы дигән бакчабыз өч катлы икән ләбаса!





Сиртмәле бишекне тибрәтеп, бишек җырлары көйлиләр.
Йокла, улым,
йом күзең,
Йом-йом күзең,
йолдызым...

Зөлфирә ханым көлә-көлә серен аңлата, «Бакчада эшләүчеләр, әти-әниләр, мәктәп укучылары бергәләшеп казып, өмәләр ясап, мәйданыбызны зурайттык шулай», – ди. Ә анда... бер як дивары көзгедән генә торган музыкаль бүлмәдә кызлар-малайлар җырларга, биергә өйрәнә. «Бөтерчекләр» төркемендәге нәниләр бишек җырлары тыңлап йокыга китә шулай.

Бишек дигәннән, «Ак каен»да кечкенә музей да бар әле. Бишекләрнең нинди генә юк! Хәтта республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтовны тибрәтеп үстергән бишек тә биредә эленеп тора. «Готыф абыйның оныклары да безнең бакчага йөрде бит, – дип аңлата Зөлфирә Фәсхи кызы. – Күп иде инде алар. Бакый абый Зыятдиновныкылар да, башкаларныкы да...»

«Ак каен»га бүген 85 бала йөри. Ясле-бакчаның үз шәҗәрәсен дә төзеп куйганнар. Кемнәр эшләгән биредә – барысы да тарихка кереп калган.

Светофор куелган, машиналар тезелгән бүлмәдә юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтәләр, «Тылсымлы ком» тугәрәгендә пыяладагы ал, шәмәхә комнар өстендә нәни генә куллар халкыбызның милли бизәкләрен, кояш, чәчәкләрне сырлый, татар халык әкиятләренә анимацион этюдлар ясыйлар, үзләре мультфильмнар төшереп карыйлар... Хәйран калып танышып йөрибез. Бакча яшендәге кызы булган Ксения – соклануның аръягында.

Әйтерләр, татар кызы ул, дип...

Сүз башым бит калфак иде. Менә хикмәт! «Ак каен»да безне тагын бер сюрприз көтә булып чыкты! Зөлфирә ханым кадерләп, саклык белән генә өстәлгә бер калфакны алып салды. «Бу бик борынгы, 1860 елгы калфак инде. Безнең нәселнең бик кадерле ядкаре. Гүзәллек сөюче Маһикамал әбиебез үз куллары белән чиккән аны. 1889 елда туган кызы Хәсбикамал үсеп җиткәч, мәдрәсәдә укыганда матур булып йөрсен дип, аңа бүләк иткән. Хәсбикамал әбием исә калфакны минем әнигә – Шәрифелҗамалга кидерә. Аны бик тә гыйлемле мөгаллимә итеп күрәсе килә әбиемнең. Әнием сандыгыннан миңа күчте калфак. Мин, үз чиратымда, аны Зөһрәгә тапшырдым», – дип сөйләп, кызына тоттыра кадерле мирасны. Янибызда бөтерелеп торган кечкенә Эвелина – Зөһрәнең кызы икән. Зөлфирә, оныгының аркасыннан сөеп торган арада, әнисе аңа борынгы калфакны кидереп карый. Менә кем, кадерләп саклап, киләчәк буыннарга тапшырыр аны! Менә кемгә әйтерләр «Ул татар кызы!» дип... Бер калфак тарихы үзе бер шәҗәрәне хәтерләтә. Нәселдән-нәселгә миллилекне саклап килүче калфак – ерак әбиләрдән тапшырылган кадерле хәзинә.

Карадуганныкылар гына түгел, Таузар, Арбаш, Апаз, Кенә, Шубан, хәтта Балтачның үзеннән дә килә икән нәниләр.

...Без кайтыр юлга җыенабыз. Тиктормас, шаян Илүзә, Фирүзә, Кәримә, Әмир, Идрисләр кул болгап калалар. Монда рәхәт: нәкъ өйдәгечә! Бишек җырлары яңгырый, әкиятләр сөйлиләр, йомшак итеп, яратып эндәшәләр... Зөлфирә апалары шулай күрергә теләде, шулай хыялланды. «Бу уңышларга бөтенебезнең дә – гаиләмнең, хезмәттәшләремнең, үзем белән эшләгән җитәкчеләремнең дә өлеше кергән», – ди ул. Инде менә йокысыз төннәрнең, тырышлыкның, тәвәккәллекнең, кешеләр яратуының нәтиҗәсе – күз алдында. Милли мәгарифне үстерүдәге хезмәтләре өчен коллектив Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты булды! Чын татар кызлары, татар уллары үсеп килә. Әнә, ак каеннары да шаһит шуларга.


«Ак каен» балалар бакчасы тормышыннан фоторепортажны сайтыбызда карый аласыз.



Кем кызлары, кияүләре дигәндә, «Зөлфирә белән Фәритнекеләр!» дип, аерым бер соклану белән әйтәләр алар турында. Оныклар Фәнзил, Эльвина, Эвелиналар да шул «Зөлфирә-Фәритнекеләр» булып йөри. Гасырларны кичкән нәсел калфагы бүген мөдир кызы Зөһрәгә күчте.



PRESSA.RU



СУРГУТ ТАТАРЛАРЫ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Обь елгасы аша салынган Югра күпере – Россиядәге иң матур күперләрнең берсе. Кызгылт-сары әфлисун төсенә буялган, асылмалы мондый күпер башка юк! Аның ачылганына ун гына ел әле. Ә аңарчы... Язларын, мул сулы Обь бозлардан арынганчы, Сургут берара зур дөньядан аерылып тора торган булган. «Азык-төлек җитәрлек булсын дип, күпләп алдан алып куя идек», – дип искә төшерәләр. Җәйге яллар җитә башласа, самолетка билет алу өчен аэропорт кассасына чиратка басып, төн кунулар гадәти күренеш булган. Сургутның сазлыклардан гына торган чакларын хәтерләүчеләр байтак әле монда! Шәһәр бит илленче еллар уртасында, бу төбәктә нефть һәм газ табылгач кына төзелә башлый. «Без килгәндә Сургутта ике генә оешма исеме ишетелә иде – «Татнефть» һәм «Башнефть», – дип әйтүчеләр булды. Милләттәшләребезнең монда күп булуы шуңа күрә шаккаттырмый. Авыр эшкә кайда да безнекеләр тотына инде... Бүген калада 40-45 мең татар яши диделәр. Тамыр җибәреп дисәм... Тормыш мәшәкатьләре артыннан чапканда да, балалар үстергәндә дә, эш урыннарында шактый зур уңышка ирешкәндә дә... күзләре гел күпер ягында аларның. Туган якларга юл – шул якта! Кайтырга кузгалсаң, иң элек шушы күперне үтәргә кирәк.

«Киттеләр...»

Себер җирендә иң беренче мәчет моннан ике дистә ел элек Сургутта салынган. Бу якларның иң матур, иң затлы иман йорты, диләр аны... Килүебез бәйрәмгә туры килде әле: Таһир хәзрәт Саматов һәм аның җәмәгате Рәйсә абыстай мәчеткә йөрүче апаларны җыеп, чәй табыны янына хатын-кызлар көне белән котлауны күптән инде гадәткә кертkән икән. Дөресрәге, Коръән укып, әле кайчан гына алар белән бергә дин гыйлеме алган, намаз укыган, инде менә ахирәткә күчкән Гөлмисрур, Моксинә, Мария, Нәҗибямал апаларны искә алу, рухларына дога кылу көне бу.

Табын артына җыелган апаларның һәркайсының үз язмышы. Әмма барысын да бер нәрсә берләштерә – һәркайсы Себер җиренә «вакытлыча» дип килгән булган.

– Мин Чирмешән районы Лашман авылыннан. Акча эшлибез дә, кайтып өй салабыз дип килгән идек, – дип сөйли Фәния апа Шакирова. – Эшнең хурлыгы юк, дип гомер иттек. Иремне иртә югалттым. Үзем генә булсам да, тәвәккәлләп, Түбән Камага күченгән идем. Тора алмадым... Инде балалар: «Әни, кузгалып та маташма, барыбер кире кайтасың», – диләр.

– 47 ел элек килгән идек, – ди Фәмзүлә апа Гыйльметдиянова. – Өйләнештек тә, акча эшлибез, дип чыгып киттек. 22 яшь иде миңа ул чакта... «Беренче поезд керү белән кайтып китәбез», – дидек. Гел сузылды... Кызык яшәдек үзе, татарлар үзара аралаштык: бер атнада – беребезгә, икенче атнада – икенчебезгә кунакка йөрешә идек. 16 ел элек ирем үлде, яңарак кына олы кызымны җирләдем...

– Килгәнгә өч дистә ел булды, – ди Әлфия апа. – Монда болай озак яшәрбез, димәгән идек. Хәзер инде белмим... Безнең балалар бирелдә төпләнде – оныкларны үстерергә булышырга кирәк. Яшьтәшләрнең күбесе китте китүен. Әмма кайберләре кире дә кайта. Күңелсез хәбәрләр дә еш ишетелә: олыгайган саен, күчену авыррак шул. Бигрәк тә ир-атларның йөрәге чыдамый...



■ Риф Садыйков һәм Рафаил Ульбеков Татарстан Президенты янәшәсендә. Казан.

Кемдер «ике елга гына» дип килгән булган, кемдер – «өч елга»... Берәүләрне – комсомол путевкасы, икенчеләрне – югары уку йортын тәмамлаганнан соң юллама белән җибәргәннәр. «Яшерен-батырын түгел, без монда һәркайсыбыз акча эшләргә дип килдек», – диләр. Озын салкын кырыс кышлар (быел суыклар янә рекорд куйган әле: минус 60 ны да узган!), кыска җәйләр, авыр эш... Боларга туган яклардан ераклыкны, сагынуларны да кушсаң... Юк, акча берничек тә җиңел килмәгән аларга. Ярый әле, үзләре әйткәнчә, өметләрен аклаганнар: хезмәт хакы да түләгәннәр, бараклардан акрынлап фатирларга да күчергәннәр. Сургут халкы гел ике нәрсәне көтеп яши дигән гыйбарә телләрендә еш яңгырый: җәйне һәм җәйге ялларны. Шаярталар! Чынлыкта, «көтеп үткән гомер» дию аларга бик туры килә.

Сүз уңаеннан. Сургут татарлары белән аралашырга туры килгәндә, кемдер хакында «китте» дип әйтсәләр, мәрхүм танышларын искә алалар икән дип ялгышмагыз. Туган якларына күченеп кайтып китүчене, гадәттә, «китте» дип сөйли алар.

Сезне монда көтәләр!

Җәмигъ мәчете һәм татар милли-мәдәни мохтарияте. Сургут татарлары ишекләрен һәрвакыт ачып керә ала торган ике урын бу шәһәрдә. Чакырусыз, үзләре кайчан тели – шунда! Сургут каласында гына түгел, өлкәдә яшәүче барлык татарларны берләштерүне, туплауны заманында якташыбыз, Чистай егете Фәнис Гатауллин башлый.

> *Мохтарияттә төп эшне хатын-кызлар алып бара. Гаиләдәге кебек. Без, ир-атлар, аларга таяныч кына.*

Кызганыч, гомере генә кыска була аның... (Инде Фәниснең улы Рамил үсеп җитеп, Татар үзәгенә йөри башлаган.) Бүген Сургут – өлкәдә яшәүче һәммә милләттәшләребез өчен рухи үзәккә әйләнгән дисәк тә, ялгыш булмас. Лангепас, Түбән Варта, Лянтор, Федоровка, Урай, Нефтеюганск... Сургут Казанга карап торган кебек, Себернең татарлар күпләп яши торган бу шәһәрләре аларга карап тора. Бер ягыннан икенче ягына кадәр ике мең (!) чакрым булган өлкәне бер йодрык итеп берләштерүдә Ханты-Манси автоном округы татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Таһир хәзрәт Саматовның өлеше шактый. Абруйлы, дәрәҗәле, хөрмәтле кеше ул. «Газпром», «Лукойл», «Сургутнефтегаз» кебек оешмаларның җитәкчеләре дә аның белән кул биреп күрешә, сүзенә колак сала, үтенечен кире какмый. (Хәзрәт һәм аның матур гаиләсе турындагы язманы алдагы саннарыбызның берсендә укырсыз.)

– Безнең фикерне монда ишетәләр, – Сургут татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рафаил Али улы Ульбеков та шулай ди. Хәзрәт кебек ул да шәһәрнең координация советы әгъзасы. – Сургут – күп милләтле

PRESSA.RU





шәһәр. 29 милли оешма арасында безнеке иң көчлесе санала. Өч айга бер тапкыр «Татарлар» дигән газетабыз чыгып килә. (Редакторы – Рәфис Шәймәрдан, профессор, күп китаплар авторы. – *Г. С.*) Татар үзәгендә, кечкенә генә булса да, китапханә ачтык. Ә Сабантуй быел бездә утызынчы тапкыр узачак. Узган ел мәйданга 30 мең кеше җыелды, диделәр. Аны бездә шәһәр бәйрәмнәре исемлегенә керттеләр. Татарстан Сабантуйда катнашу өчен аерым җырчылар гына түгел, зур көчле коллективлар җибәрсен иде. Башкортстан андый мөмкинлекне таба... Татарларның рухын күтәрү өчен кирәк ул. Әле менә яңа ачылган «Нефтяник» сәнгать сараена Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамблен китертәсебез килә. Россиядәге иң зур сәхнәдә татарча, инглизчә, итальянча җырласыннар – күрсеннәр бөтенесе татарның нинди халык икәнен!

Кемнедер монда романтика тартып китергән.

Рафаил Али улының тамырлары Ульян өлкәсенең Зур Черекле авылына барып тоташа. Әтисе белән гаеткә барулары, әнисенең «Азат хатын» журналын алдыруларын сөйли ул. Куйбышев төзүче-инженерлар институтын тәмамлагач, Сургутка килә. «Чөнки монда гаиләлеләргә бүлмә бирәләр иде», – ди. Тиздән кайтып китәбез, дип, өч ел чемодан өстендә утыралар. Аннан тагын өч ел, тагын өч ел... Рафаил Ульбеков бүген Сургутта билгеле шәхес – идарәче компаниянең директоры. Җаваплы вазыйфа! Ә милли хәрәкәт эшендә катнашуы – күңел кушуы.

– Яшьләргә гел әйтәм – тамырларга тартылу барыбер булачак, дим. Татарча көйләрне мин кырыкка җитәрәк тыңлый башладым. Эзләп алып! Тагын бер генә мисал. Әнинең сеңлесе руска кияүгә чыккан безнең. «Энем, мине татар зиратына күмәрсең», – ди. Ире: «Ә мине кая?» – дип аптырый. Анда да янәшә буласылары килә. Зират дигәннән, мөселманнар өчен аерым зиратыбыз бар хәзер...

Якшәмбе мәктәбе

– Дүрт яшел яфрак... Бер кызыл, бер сары, бер ак тюльпан...

Альбертның авызы ерыла, Гүзәл апасы: «Булдырдың!» – ди бит. Калганнар әле тырышып-тырышып лалә чәчәкләре буйый: Денис, Эмилия, Амали, София... Кайсыдыр карандашын югалткан: «Где у меня яшел?» Тизрәк буярга да, такта янына чыгып, кулындагы рәсемең турында сөйләргә кирәк: «Өч яшел яфрак, бер сары тюльпан...»

Татар үзәге каршында эшләүче «якшәмбе мәктәбе»ндә ачык дәрес бара. Иң кечкенәләренә дүртәр яшь кенә булган бу сабыйларның татарча сүз байлыгын санарга бармаклар да җитә әле: саннар, төсләр, җиләк-җимеш исемнәре... Әмма «тамчыдан күл җыела», ди халкыбыз!

– Якшәмбе татар мәктәбе бездә 1993 елдан бирле эшли. Быелгы уку елында беренче тапкыр шундый бәләкәчләр килде менә. Берәүне дә кире бору гадәтебез юк: «Алабыз!» – дидек. Үзебез исә башта аптырап калдык, укый-яза белмәгән, хәреф танымаган сабыйлар белән нишләрбез?! Катнаш гаиләдә үсүчеләр бар. «Әти», «әни» сүзенең нәрсә аңлатканын белмәүчеләр... Без бар нәрсәне дә уен, җыр аша өйрәнәбез. Һәр дәрес ахырында әниләре алар өчен чәй әзерли. «Балалар ял көнен көтеп ала. Үзләрен татар дип санауларын, телне дә, динне дә белүләрен телибез», – ди әниләре.

Гүзәл Шәрәфетдинова – Нурлат кызы. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач, язмышы шушында алып килгән. Татар теле укытучысы булырга җыенса да, гомере буе мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыта ул. «Якшәмбе мәктәбе»ндә татар теле дәресләре алып бару – анысы күңеле кушканга.

– Ә зурлар төркеме... Анда егет-кызлар да, 70 яшьлек апа-абыйлар да бар. Кемдер хәтта башка шәһәрдән килә!

Бер кызык яңалык. БДИ вакытында: «Безнең балалар башкалардан өстенрәк булсын», – дип... татар үзәгендә рус теле курслары оештырганнар. Булдай! Чит-ят халык арасында уңышка ирешү өчен, белемең белән алардан бер башка югарырак торырга кирәк, дию, яшьләргә шулай сеңдерелә.

«Сандугач»

Сургут татарлары бай: аларның хәтта җыр һәм бию ансамбльләре бар! 1984 елда оешкан ул. Бу якларга татар артистларының әле юл салмаган, халыкның җыр-моңнарыбызга сусаган вакыты... Казанда режиссерлыкка укып, Сургутка



Җиңел укыла, гыйбрәтле язмышларга бай, дип, китапларны ошаталар. Китап ахырында күрсәтелгән адрес буенча язучы белән элемтәгә дә керәләр... «Саба таңнары» газетасының элеккеге журналисты Гөлсинә ханымның китапларын миңа бөтен Сургут укый кебек тоелды. Аның бирегә инде икенче сәфәре. Бу юлы миңа юлдаш итеп безне дә чакырды. Шулай булгач, «Сөембикә»не Сургутка аның китаплары һәм Дания китерде дисәм дә дөрес булыр.

юллама белән эшкә килгән Пермь кызы Гөлфирә Рангулова: «Җырларга теләгән татар-башкорт яшьләрен чакырам», – дип, газетага белдерү бирә. Нуриянең дә күзенә чалына ул белдерү. Шатлыгының чиге булмый! «Сургут» универмагына барып, татарча сөйләшүчеләрне ишетсә: «Сез кайсы яктан?» – дип якташларын эзләп йөргән чагы бит...

Ике елдан, үзе башка эшкә күчкәч: «Инде син дә җитәкли аласың», – дип, Гөлфирә ханым ансамбльне Нурия Җиһаншина кулына тапшыра. Балык эшкәртү комбинатында эшләүче икътисадчы кызның язмышы бөтенләй башка сукмакка борыла да куя шулай, «өч елга гына килдек» дию дә онытыла... «Элегрәк, әле Казан, Уфа артистлары килмәгән заманда, айга дүртәр концерт куя идек, – Нурия ханымның күзләрендә очкын кабына. – Барыбыз да үзешчәннәр бит. Күрше шәһәрләргә барып концерт куябыз да, төнлә юлда кайтып, иртүк эшкә йөгерәбез».

«Сандугач»ның туган көненә ел саен яңа программа тәкъдим итәләр. Һәрберсе халкыбызның йолаларына, гореф-гадәтләренә нигезләнгән: «Кичке уен», «Аулагөй», «Нәүрүз», «Сабантуй»... Ансамбль бик күп фестивальләрнең лауреаты. Костюмнарны Казаннан тектереп кайтаралар – анысы милли-мәдәни мохтарият тырышлыгы.

Безне китап очраштырды!

Татар үзәге эшендә гаиләләре белән катнашучылар байтак биредә. Рушания һәм Риф Садыйковлар (Риф Рәүф улы Садыйков – «Стройкурс» компаниясе директоры. Бер үк вакытта Югра татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе урынбасары да. Казан белән дә, Ханты-Манси автоном округына кергән шәһәрләрдәге барлык татар оешмалары белән элемтәдә ул. Бу төбәктәге татар тормышы белән танышырга теләсәң, аңа мөрәҗәгать итәргә яки ул эшләгән «Татарлар – Сургут» (www.surguttat.ru) сайты белән танышырга кирәк), Гүзәл һәм Ринат Шәрәфетдиновлар, Дания һәм Харис Әфләтуновлар...

Дания Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Ахман авылы кызы. Ләкин минем аңа гел «якташым» дип дәшәсем килде. Бабалары бездән – Кайбыч районы Мөрәле авылыннан бит! Өстәвенә, Апас районы Багыш авылы килене ул.

Шулай, күкләрдә никах укылган булса, җирдә барысы да көйләнә. Даниянең Төмәндә танышып, бик якын кешесенә әйләнгән дус кызы Татарстаннан булып чыга. Фәния аны берсендә үзләренә, Багышка кунакка алып кайта. Күрше егете Харисның да ялга кайткан чагы була. Яшьләр, әлбәттә, танышалар. Шул бер кич барысын да хәл итә...


Әфләтуновлар ике кыз – Гүзәл белән Гөлназны үстерәләр. 11 нче сыйныф укучысы Гөлназга милли-мәдәни мохтарият советы әгъзасы, Актаныш кызы Гөлчәчәк Фатхулова: «Уң кулым!» – дип кенә дәшә. Гөлназ Казанга, Татар яшьләре форумына да барып кайткан.

Казан дигәннән... Ике ел элек җәйге ял вакытында Гөлсинә Галимуллинаның берничә китабын сатып ала Дания. Юл буе поездда шул китапларны укып кайталар.

> *Югра белән Татарстан арасында туристлар алмашу буенча килешүләр төзелә.*

...Гыйнвар ахырында Казаннан Сургутка туры рейс ачылды: ике сәгать ярым дигәндә, Сургут халыкара аэропортына барып төшәсең. Аралар якыная... Һәр төбәкнең үз матурлыгы: Сургутны барып күрергә теләүчеләр, һичшиксез, булачак, әлбәттә. Нарат яки мүк җиләге, эрбет чикләвеге, муксун балыгыннан авыз итәргә. Сайма паркын, Себер «Биг-Бен»ын, музейларны күрергә, мәчеткә сокланырга... Обь ярына кадәр барып җиткән кеше Югра күперен күрми китми инде. Күпер төбендә үк – «Күпер» музее. «Бер генә объект турында сөйләүче бердәнбер музей ул Россиядә», – диделәр. Мөгаен, анда сез дә керерсез. Себер өчен әһәмияте гаҗәеп зур булган бу күпернең һәм шушы юлның иминлеген кайгыртучы «Северавтодор» оешмасын татар егете – Рамил Мусин җитәкләвен ишетеп, һичшиксез горурланырсыз. Бу хакта сезгә шушы музейның директоры – татар кызы Әлфия Шаһиева сөйләр. Ә күпергә карап, аз гына уйланып басып торырга җай булса, монда гомер иткән милләттәшләребез җанындагы җирсүне, сагынуларны сез үзегез тоярсыз...

Казан–Сургут–Казан.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

PRESSA.RU

Астрофизик галимнәр Галәмне тыңлый беләләр. Өзлексез «җырлап» торган Җиһан аларны сокландыра да, бөек ачышларга да рухландыра. Галәм хорында үзгә бер нотаны сизеп алганда бөтен дөньяның бар галимнәре бииһая бер дулкынлану кичерә. Ник теге яки бу җисем нотаны боза, ник теге яки бу пульсар сулышын тизләтә? Аннары килеп, бу Галәми хорның дирижеры кем? Булырга тиеш бит инде ул?! Чөнки җитәкче дирижер таягыннан башка музыка хасил була алмый! Ноталар йолдызлы бизәк хасил итсен өчен бөек Хаким, ягъни дирижер кирәк. Кешелек дөньясы Йолдызлы күк дигән илаһи хордан күзен ала алмыйча, Бөек Серне аңлый алмыйча миллион еллар йөди.



ГАЛӘМ СУЛЫШЫ



Асия ЮНЫСОВА







Океан-дәрья да шул авазлар системасына буйсына булыр. Йөз меңләгән балыклары, җәнлекләре, акыл иясе дельфиннары авазлар алмашып, ничектер, аңлашып, ниндидер уртак гармонияне табып, үзара сөйләшеп-җырлашып яшиләр. Ә аларның дирижеры кем? Юк, дирижерсыз гына булмас ул, булмас...

Югары сәнгать яралган антик дөньяның тамашаларын күз алдына китерегез. Эсхил, Эврипид, Софокл трагедияләре уйналган Колизей амфитеатрларын. Алгы планда фаҗига рольләргә бүлеп уйнала, ә арткы планда Хор шул заманда булып узган вакыйгалар хакында җырлап тора. Димәк, Хор һәммәсен дә белә, һәммәсеннән дә хәбәрдар! Ә менә аның дирижеры инде кеше, таяклы музыкант булырга тиеш.

Әллә үзебез хорда җырламадыкмы? Һәр мәктәп концертында тәүге чыгыш хорныкы була торган иде. Һәр оешманың, һәр вузның үз хоры булу хәтта мәҗбүри иде бугай. Ә ул хорда дәрәҗәле җырчы – солист бар. Гомуми авазлар ташкыныннан аерылып, күккә үрләгән тургай кебек ул солист.

Фуга...

Миләүшә Әмир кызы Таминдарова Казан дәүләт консерваториясенең хор бүлеген, аннары шунда ук ассисентураны тәмамлаган, хор дирижерлары кафедрасында хәзергәчә укытып йөри торган дирижер. Әмма аның бу регалияләрен Татарстан камера хоры җитәкчесе дигәне күмеп киткән. Хәер, хорның исемен дә еш кына кыскартып әйтәләр: Таминдарова хоры! Нәкъ шулай – өндәү билгесе белән.

Аңа кадәрме? Аңа кадәр Миләүшә Таминдарова профессор Семен Казачков җитәкләгән студентлар хорының хормейстеры. Шул ук вакытта Казан музыка училищесында хор дирижерлары бүлеген җитәкли. Үзенең шушы хорын әле 1997 елда ук танытырга өлгерә. Россия милли операсы оркестры белән дә, Оборона министрлыгының симфоник оркестры белән дә катлаулы музыкаль әсәрләр башкарып, үзләренә халыкара фестивальләрдә катнашу хокукы яулый камера хоры. Чехиядәге фестивальдә Таминдарованы дирижер буларак зур уңыш көтеп торган икән. «Дирижерлык өлкәсендә соклангыч казанышларга ирешкән өчен» медале аңа гына бирелә.

Ләкин Миләүшә – Тургай, ягъни солист бит әле. Опера һәм балет театрының, башка музыкаль коллективларның АКШка, Германиягә, Швециягә, Чехиягә гастрольләрендә башлап җырлаучы сыйфатында катнашып, Таминдарова Моцарт, Гайдн, Софья Гобәйдуллина әсәрләрен җырлый. Шул сәфәрдән кайткач бирелә инде аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән дәрәҗәле исем. 2007 елдан башлап Миләүшә Әмир кызы Татарстан дәүләт камера хорын җитәкли.

Без аның белән Зур концерт залы бинасындагы кабинетында сөйләшеп утырабыз.

Кечкенә икән кабинетыгыз.

– Миңа җитә. Минем хорымның Европаның иң затлы залында – Сәйдәшев исемендәге Зур Концерт залында репетицияләр ясау мөмкинлеге бар!

Сез – солист буларак танылган җырчы – хор сәнгатенә кереп киткәнсез. Аның да ир-атларга гына буйсына торганына. Хатын-кыз дирижерлар бармак белән генә санарлык бит ул. Сез дә, тагын менә Анна Гөлишәмбарова бар.

– Казан данлы дирижерлары белән мактана ала. Натан Рахлин, Фуат Мансуров, Семен Казачков, Владислав Лукьянов, Александр Сладковский... Болары телгә килгән исемнәр генә әле.

Ә мин Сезнең янга хор дигән хикмәт хакында сөйләшергә дип килдем.

– О-о, хор чыннан да хикмәт ул! Балагыз булса, хорга бирегез. Мәшәкатьле үсмер булса, бигрәк тә! Музыка изге нәрсә бит ул. Аның тирәсендә нәҗес тормый. Музыка ул кешелекнең рун язуы! Анда бар да бар. Шекспир ни дигән әле, «ноталар безне коткарачак!» – дигәнме?

Әллә тагын... Мин Бетховенның: «Музыка кешеләр йөрәгендә очкын кабызырга тиеш!» дигәнен генә ишеткәнем бар.

– Сезнең ишеткәнегез бар, ә минем ул очкынның кабынганын күргәнем бар, күргәнем!

Әле мин Сезнең күзләрдәге очкынны гына күрәм. Каян килә бу тиклем энергетика?

Бу хакта соңыннан. Әле хор хикмәте турында сөйләшик. Әйтик, бала төрле конкурсларга йөри, ди. Конкурслар балачак дигән матур фасылны харап итә торган нәрсә. Вундеркиндларны конкурслар түгел, акылы булган әниләр тәрбияли. Акыллы әни баласын хорга бирә, кеше арасына китерә. Сабыйларны иртә картаюдан хорда җырлау гына коткарачак.

Ничек итеп?

– Бала хорда, беренчедән, дуслыкка; икенчедән, җаваплылыкка өйрәнә. Өченчедән, тавыш аппаратын, резонаторларын эшләтеп, сәламәтлеген ныгыта. «Чылбырлы сулыш алу» дигән нәрсә бар. Ул болай. Хорда җырлаучылар бөтенесе берьюлы авазны өзеп, сулыш алырга тиеш түгел. Чираттан кирәк. Шуңа күрә хорда җырлаучы күршесен тыңлый. Күршесе сулыш алу өчен бүленгәндә авазны ул дәвам итәргә тиеш. Димәк, аның колагы күршесен тыңлау дулкынына көйләнгән. Күршесе аның авазын тыңлый. Алар шул рәвешле бер-берсен ишетәләр. Бөек әйбер ул – «чылбырлы сулыш алу»!

Хәзерге дөньяда бик кирәкле сыйфат ул – бер-береңне ишетә, тыңлый белү! Сез әле тагын бик кызык кына итеп «быть в фуге» дип тә әйтеп куйдыгыз. Монысын да шул бер-береңә карата сабыр булуның, музыкадагы гына түгел,

PRESSA.RU

дөньядагы авазлар полифониясен ишетә белүнең бер төре дип атыйкмы?

– Шулайрак. Ә менә мин үзем дирижер буларак, хорның бөек миссиясен кешеләргә ачылырга ярдәм итүдә дә күрәм. Хорыма йөргән 32 кешенең һәркайсының йөрәге ничек типкәнне ишетеп торам мин. Күзләрен күрәм. Алар монда килгәч, ачылалар... Мин, хордагы егетнең күзенә карап: «улым», дип эндәшкәндә, ул «улымның» күңеле җылына.

Сезнең камера хорында 32 генә җырчымыни? Ә бит сәхнәне иңләп, затлы киемнәрдән чыгып баскач, күп күренәсез.

– Хор дип аталу өчен коллективта 50 җырчы булу шарт. Күбәербез әле.

Хор булса да, дирижер сүзе чыккач, күз алдына оркестр килә. Феллини фильмындагыча, сезнең хористларны да берәр музыка уен коралына тәңгәл итеп карыйсы килә. Һичьюгы Сезнең үзегезне

– Мин – виолончель!

Виолончель – ялгызлык һәм моңсулык символы. Ә Сезне репетиция вакытында күзәтеп утырганда минем күңелгә бер генә чагыштыру килде: перпитум мобиле! (мәңгелек двигатель). Сезнең буй-сын кылган хәрәкәтләргә акробатлар көнләшерлек. Ә мимика соң, мимика! Бу «сөйли белә торган» йөзне сәхнә тоткан мәшһүр мимнар әҗәткә сорап торырлык. Кулыгызда дирижер таягы да юк. Керфек угы белән генә авазларны «кабызып» җибәрәсез. Аңлыйлар тагын үзегезне.

– Аңлашмагач та хор була димени ул! Күмәк җырлау, оркестр – ул тулы бер фәлсәфә. Мин үземне виолончель дисәм дә, иң яраткан музыкаль уен коралым – кеше тавышы! Анда музыка уен коралларындагы аһәңнәрнең барысы да чагыла.

...Һәм дога

– Мин хорда беренче тавышта җырламас идем. Мин уртада булырга, икенче тавышта җырларга яратам. Ә болай өч тавышка җырлый алам. Әйтик менә Софья Гобәйдуллинаның «Мәхәббәткә аллилуйя»сын җырлап күрсәтимме? Бу композиторның язганнарын аңлар, яратыр өчен вакытлар узуы кирәк. Музыкаль әсәрне бер тыңлауда гына яратам димә, ике тыңла, өч тыңла – шуннан соң гына ярату килә. Бездә аңланмаган композиторлар тагын да бар. Мәсәлән, Шамил Шәрифуллин. Мин матур музыка тыңлаганда тетрәнеп калам. Матур музыка ул күлмәк кебек – аны киеп куясың.

Хорда җырлаганда сез шулай җыйнаулашып күлмәк киясезме? Ә миңа җыйнаулашып хыяллanasыз, хәтта аяк табаныннан да музыкаль авазлар суырасыз кебек тоелган иде. Адәм баласы булдыра алмастай таләпләр куясыз кебек. Менә ничек итеп авазлар, аңкаудан старт алып, бөтен гәүдә буйлап җырлап үтеп, табаннан чыгып китә ала ул?

– Музыкант кеше чыдам булырга, гәүдәсен идарә итә белергә тиеш. Ә музыка тетрәндерергә тиеш. Әйтик, «Җиңү көне» җырын яки Гамзатов сүзләренә «Торналар»ны йөрәк итен талкытмыйча гына җырлап буламы соң? Тетрәнмичә! Мин тетрәнәм, мин шундый инде. Мин дөньяны үзгәртә торган музыканы, дөньяны үзгәртә торган кешеләрне яратам. Аида Гарифуллина белән Владимир Васильевның безнекеләр булуына горурланам.

Ә бит Сездә биюче азарты да сизелеп тора. «Амболлю, амболлю» дип сөрән салып, мамбаны йә самбаны биеп китәрсез кебек. Гәүдә җиңел булгач, рәхәттер ул?

– Рәхәт! 37 килоны ташладым. Эшкә җәяү йөрим. Дөрес туклану, дөрес яшәү, дөрес ниятләр... Әйе, безнең өчен ниятләр мөһим: «Йөгерә алсаң, йөгер; атлый алсаң, атла; атлый алмасаң, шуыш», диелгән хәдис бар.

Бая Сез «Аллилуйя»ны җырлап күрсәткәндә, иртән тавышны уяту өчен әйбәт күнегү бу дип уйлап куйган идем. Шушы сихри авазлар белән тамакны «чайкап» алганнан соң, тавыш үзеннән-үзе белькантога (матур җырлауга) көйләнеп куядыр кебек.

– Мин көнемне намаз белән башлыйм. Намаз минем яшәешемне тәртипкә салды. Иртәнге намазга торасы булгач, иртә ятам...

Хорында чиркәү музыкасына байтак урын биргән Таминдарованың бу гамәле бераз сәеррәк тоела.

– Моның нәрсәсе сәер? Бах, Гайдн, Вивальди музыкасы миңа иманга килергә комачауламады. Күземне ачкан өчен мин Мәмсә авылында яшәүче Гөлсем апага, Сикертәндә гомер итүче Наилә апа белән Җәүдәт абыйга рәхмәтле.

Ә музыка дөньясына алып килгән өчен кемгә рәхмәт укыйбыз?

– Әнием Таһирә белән әтием Әмир Таминдаровларга. Алар миңа гына – өченче төпчек кызларына гына кысан фатирга пианино алып куйдылар. Икесе дә фронтовиклар иде. Безнең өйгә композитор Исмай Шәмсетдинов, җырчы Сөләйман Йосыпов килеп йөрделәр. Әтинең кыз туганы Рәшидә апам Таминдарова Опера һәм балет театрында җырлады. Ә ул Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов кебек бөекләр белән таныштырды.

Сезгә бәхетле язмыш насыйп булган, күрәсең.

– Мин искитмәле бәхетле кеше!

МИЛЛИ АШЛАРНЫҢ КАДЕРЕН ҮЗ ИЛЕҢДӘ ЯШӘГӘНДӘ ГЕНӘ БЕЛМИСЕҢ УЛ. ДӨНЬЯГА ЧЫГЫП КАРАСАҢ... ТАТАРСТАННЫҢ ҺӘМ РОССИЯНЕҢ АТКАЗАНГАН АШ-СУ ОСТАСЫ БУЛГАН БЕР ХАНЫМ БЕЛӘН ДӘ ШУЛ ХАКТА СӨЙЛӘШКӘН ИДЕК.

Асия
СӘГЫЙТОВА

ТОКМАЧЛЫ АШ

Бу ханым оныгы белән Германия клиникаларының берсенә балага иң дөрес диагнозны куйдырырга дип барып кайткан иде. Шунда күргән-кичергәннәрен минем белән дә уртаклашты: «Беләсеңме, Алман илендәге муллык белән шаккаттырып булмый безне хәзер. Үзебездә дә ризык муллыгы. Акчаң гына булсын. Алай да кибетләренә кердем. Ассортимент бездәгедән йөз тапкырга мулрак дип таптым. Ярый, хуш. Малай белән клиникага урнаштык. Төн кундык. Иртәнге аш килде. Тәлинкә төбендә бер чеметем яшелчә, бер-ике телем колбаса. Аш алдыннан кабып куярга ярый. Тик... дуңгыз ите бит. Бар белгән немецчамны җигеп белештем моны. «Швайнмы?» дип соравыма хәдимә туташ, «йа-йа», дип баш какты. Әйе, дигәне инде бу. Этеп куйдым тәлинкәмне. Ботка көтәм. Ләкин ботка килмәде. Ярый әле малайга дип йогырт куйганнар иде. Бала да ач калды. Колбасаны балага бирәсе калган дип үкендем инде соңыннан... Авыр хәлгә калганда рөхсәт ителә ул хәрам ризык.

Көндезге аш вакытында да, кичке ашта да табын әллә ни мул булмады. Икенче көнне дә кайнар ризык күренмәде. Хуҗа Насретдин ишәге кебек ач торырга өйрәндек. Хуҗа Насретдинны гына түгел, Торна белән Төлке турындагы әкиятне дә искә төшердем. Хәтерлисең булыр, Торна Төлкегә ашны озын муенлы чүлмәккә



салып биргән, ә Төлке Торнага дигән сыен сай тәлинкәгә җәеп салган – шулай кунак итешкәннәр.

Ярый, димен, танышларыма чыккач, сыйланырбыз әле. Казан кызы алман егетенә кияүгә чыккан иде. Шуларда берничә көн торып, шәһәр карап, музейларда йөреп алырбыз дигән ният бар. Ни кызганыч, Казан кызы үз илендә кунакны ничек сыйлауларын оныткан булып чыкты. Иртәнге ашка монда да юка телемле сыр, ветчина ише алман сыйлары килде. Безнеңчә әйткәндә, коры-сары. «Безнең ашказанында гөмбә чире бар, шуңа күрә ашауны шундый тәртиптә тотабыз», – дип акланды якташым. «Болай ашап торсагыз, ашказаныгызда имән дә үсәр әле», – дим.

Ә карын чын ризык тансыклады, үзебезнең бәрәңгене, шулпаны... Сабырым төкәнде. Хуҗа хатынга 500 евро чыгарып бирдем дә, базарга барып авыл тавыгы ал, йомырка, он алып кайт, дидем. Алып кайтты. Кичкә болар эштән кайтуга менә дигән тавык ашы пешереп куйдым. Камыр җәеп, җемелдәтеп токмач кистем. Өйдәге хуш ис урамнарга чыкты. Алман кияү ишектән керә-керешкә һаваны йотлыгып сулый. Бу нинди тәмле исләр янәмәсе!

Бер тәлинкә ашады бу токмачлы ашны, тагын берне өстәтеп алды. Алман хатынына әйләнгән Казан кызы да иреннән калышмый. Аштан тәмам канәгать калган бюргер берзаман миңа бик кызыктыргыч тәкъдим ясады. Ул үзе шулай дип уйлый инде: «Фрау, калыгыз сез монда. Виза ягын җайлармын. Ашарга пешереп торыгыз безгә. Мин Сезгә аена 1000 (мең!) евро түләрмен», – ди. Мин дә сер бирмим: «Герр, бу тәкъдим бик ымсындыргыч, әлбәттә. Тик мине Казандагы рестораннарым көтә бит, – дигән булдым».

Казанга кунакка чакырдым әле үзләрен. Чын татарча итеп, табынга мул ризыклар тезеп сыйларга исәбем. Безнең халык шәп итеп ашарга да, шәп итеп эшләргә дә ярата. «Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен!» дигән мәкаль дә бездә генә ул.

Мин бу мәкаль янына үзем алган сабакны да өстәп куям: «Табының ярлы булгач, кибетләрең мул булудан ни файда?»

PRESSA.RU

Балык Бистәсендә яшәп иҗат итүче Рәсимәбез бар безнең. Рәсимә Гарифуллина. «Сөембикә» укучыларын һәрчак әле шигырьләре, әле күләмле чәчмә әсәрләре белән сөендереп тора. Бүген дә бер шәлкем шигырьләр юллаган редакциягә.

Рәсимә
ГАРИФУЛЛИНА

ЙӨРӘКТӘ – ЯЗ ЧӘЧӘКТӘ...

Мәхәббәткә рәхмәт!

Син янымда булган
Ал таңнарым өчен,
Иртәләрем өчен
Мең рәхмәт!
Өстәп сөю көчен,
Миңа канат куйган,
Чын бәхетле иткән
Мәхәббәт!

Син янымда чакта
Алсу була таңнар,
Җанда була җаннар –
Бик рәхәт.
Миңа саклап килгән
Саф хисләрең өчен,
Терәк булган өчен
Мең рәхмәт!

Җаның-тәнең белән
Чын сөюең өчен,
Рәхмәт сиңа, иркәм,
Мең рәхмәт!
Безне кавыштырган
Алсу таңнар өчен
Мәхәббәткә миннән
Мең рәхмәт!

Күктә – йолдыз...

Күктә – кояш, урамда – кыш,
Йөрәктә – яз чәчәктә.
Кышкы көндә чәчәк аткан
Мизгелләр бу йөрәктә.

Күктә – болыт, урамда – көз,
Җанда – сихри мизгелләр.
Кышка, көзгә исе китми,
Сөю көтә күңелләр.

Күктә – йолдыз, урамда – төн,
Ә йөрәктә – яктылык.
Чөнки сөю дәшеп тора,
Бәхет чәчеп, яктырып.

Сөю – бәхет

Кичке авыл урамыннан
Икәү килә елмаеп.
Ике гашыйк – ике шатлык
Йөрсенмени моңаеп?

Күктә ай елмаеп тора,
Йолдызлар яктыралар.
Кулга-кул тотынып килә
Айлы юл буйлап алар.

Бертуктаусыз көлешәләр,
Бәхеттән хисләр ташкан.
Йөрәктә сөю ташкыны,
Күңелләр күккә ашкан.

Кичке авыл урамында,
Асылмалы басмада
Егет куенына керә
Бер оялчан кыз бала.

Ике йөрәк бергә тибә –
Иркәли күңел күген.
Боз өстендә ике шәүлә –
Ай үзе шаһит бүген.

Бер-берсенә сарылалар –
Иреннәр кушылалар.
Нәкъ бер үк җырны җырлаган
Сандугач кебек алар.

Күк түбәсе

Каурый болытларны җир өстенә
Юрган итеп япкан шикелле,
Зәңгәр күктә ак болытлар йөзә,
Акка төреп керсез күңелне.

Таң атканда күкләр алсу була,
Кояш нурларында коена.
Эңгер-меңгер – кояш китеп бара,
Кичке шәфәкъ керә куенга.

Ә төннәрен күктә йолдыз туе,
Мәңге гашыйк ай да яктырак.
Зөһрә кызга хәерле төн теләп,
Сөю җыры көйләп яткыра.

Якты ай да, йолдызлар да бердәм –
Бар җиһанга ак юл күрсәтә.
Айлы төннән якты көнгә күчү –
Ак өметләр безне яшәтә.

Күк түбәсе үзе төренгән күк
Юрган кебек җылы толыпка.
Рәхмәт әйтеп җирдән кулым изим
Ак каурыйлы серле болытка.

«Люциянең шигырьләре үзе кебек – якты, нурлы, көләч!.. Аның иҗаты яз кебек: күңелләргә ургылып килеп керә...»
Люция Әблиева иҗаты турында Галимҗан Гыйльманов шулай яза, аның шигъриятен ихласлыкка тиңли.
Юридик факультет тәмамлап, дәүләт хезмәтендә эшләү, каләм тибрәтеп, җырлар, шигырьләр, хикәяләр яза башлау... Әхлакый сафлык, тормыш фәлсәфәсе, яшәү мәгънәсе – барысы да сыйган аның шигырьләренә.



Люция
ӘБЛИЕВА

Язгы мизгелләр

Язның моңсу мизгелләре –
Ташулар ташып тора.
Елгада боз кузгалгандай,
Күңелне ашыктыра.

Язның моңсу мизгелләре –
Әле җир ачылмаган.
Сыерчыкка дигән оя
Агачка асылмаган.

Язның моңсу мизгелләре...
Кышны җибәрә алмый.
Кояш нурлары булып ул
Каралган карны ялмый.

Таратыр әле моңнарын –
Сыерчыкка кушылыр.
Җыр көйләп агар елгалар –
Яз шатлыгы шушыдыр.

Сыерчык бураннарына
«Хуш», – дип әйтеп калабыз.
Болыт астыннан караган
Кояшка елмаябыз.

Елмаер яз чын кинәнеп,
Яшел үлән үрләгәч.
Умырзая баш калкытыр
Күгәрченнәр гөрләгәч.

Әмма бүген бик ямансу –
Март кына календарьда.
Тик шулай да яшәү рәхәт
Күңелдә өмет барда.

Җырым кала

Якты дөнья буйлап барам –
Җир өстендә эзем кала.
Моң уяна йөрәгемдә,
Күңел кылым зеңләп ала.
Якты дөнья буйлап барам,
Җырым белән җирне бизәп.
Үземнән соң җырым кала,
Яшьлек кала, кулын изәп.
Якты дөнья буйлап барам –
Тормыш матур, яшәү рәхәт.
Матурлыкка күзем ачкан
Туган җирем, мең-мең рәхмәт!

Яз утырды кереп җаныма

Яз утырды кереп җаныма,
Тойгыларны чиртеп уятты.
Тормышымда яңа әйләнеш
Башланганын күңел аңлатты.

Йокламаган соры кышларда,
Черем генә иткән хисләрем.
Тансыкланып көтеп торганнар
Язның төсен, тәмен, исләрен.

Мөлдерәмә тулы йөрәк тә
Ташып китәр кебек җыр булып.
Язга әсирлеккә төшәргә
Җаным әзер... оча талпынып.

Бала чакта кигән күлмәкләр

Бала чакта кигән күлмәкләрне
Әнкәй саклый әле бүген дә.
Күз нурларын түгеп, ул аларны
Теккән кышның озын төнендә.

Безнең киеп йөргән күлмәкләргә
Карадылар бар да кызыгып.
Анасына күрә баласы дип,
Әнкәй текте тагын тырышып.

Биш баланы, табу гына түгел,
Бастырырга кирәк аякка.
Үзенең дә киясе килгәндер
Яңа күлмәк, куеп ак яка.

Исемдә юк, тегеп кигәндерме,
Вакыт тапкандырмы үзенә.
Яңа күлмәк бик килешер иде
Юкса аның нурлы йөзенә.

Барлыйм килеп шушы күлмәкләрне,
Арынам да тормыш йөгеннән.
Бала чагым карап тора төсле
Әнкәемнең сандык төбеннән.

* * *

Елама, төн,
Яшьле күзләреңне
Таң йолдызы күрсә, үпкәләр.
Үпкәләтсәң аны,
Кем таң саен
Якты нуры белән иркәләр?
Елама, төн,
Сагыну-сагышларым
Мине вакытлыча биләгән.
Мәңгелеккә түгел
Аерылышу –
Җиз иләктән хисләр иләнгән.
Хәтерләтә, дисең,
Минем халәт,
Аяз көндә суккан яшенне.
Таң йолдызын,
Зинһар, аптыратма,
Тыел, төнем, түкмә яшеңне.
Елама, төн...

* * *

Кыш әле китеп бетмәгән,
Карлар тора яугалап.
Шытып чыккан кай арада
Сары башлы тузганак.
Кояш белән шаяра ул,
Белеп кенә кадерен.
Тузганакның туе кайчан, –
Белмисеңме, кадерлем?

Сөюемнең тәңресе

«Яратам... сагындым... көтәм!»
Өч бөртек сүз хатыңда.
Өч көнлек тә аерылуга
Түзәлмавың хакында.
Өч кенә бөртек энҗе сүз
Язгансың чигеп-тезеп.
И сөюемнең тәңресе,
Мин дә нәкъ синең кебек.

PRESSA.RU

Аның әсәрләрен һәрчак көтеп алалар. Бигрәк тә хатын-кызлар. Геройлары – көчле, талантлы, иҗатта һәм хезмәттә максатка ирешкән ханымнар. Сүз, әлбәттә, күренекле язучы Мәдинә Маликова иҗаты турында. Укучылары аны «Азат хатын» журналисты чагыннан ук беләләр, яратып укыйлар. Бер тынга укыла торган «Шәфкать», «Басып сайрар талы бар», «Фидая», «Кызыл гөл», «Юкә чәчәк аткан чак иде» романнары күңелгә килә. Һәм, әлбәттә, соңгы романы «Арыш тәме»! Бу әсәре өчен Мәдинә Маликова быел республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Язучы бу мәртәбәле исемгә чыннан да лаек!

Бүген игътибарыгызга «2012 ел китабы» конкурсында I урынны алган, 2014 елда кабат нәшер ителгән «Арыш тәме» романыннан өзек тәкъдим итәбез. Романның төп герое – Айзирәк. Ул сөйгән егете Васил белән бәхетле гаилә корырга әзерләнә, киләчәктә яраткан эшендә уңышларга ирешү турында хыяллана. Фаҗигаләр, кавышулар… Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган бүлектә Айзирәк, юл һәлакәтендә вафат булган апасының яшь баласын карап, аңлашылмас ситуациядә кала. Егете белән аралары бозыла… Әнә шулай ымсындырып алып кереп китә дә, бер тынга укыла «Арыш тәме».


Мәдинә МАЛИКОВА

«ТАШЛАМА МИНЕ»

(«Арыш тәме» романыннан өзек)

Ишектән керүгә, беренче күзгә бәрелгәне – Касыймның күз карашы булды. Ул эшеннән кайтып кергәндә, өйдә бала ялгызы иде. Мөгаен, иңрәп елап яткандыр. Бала күтәреп торган җизнәсенең рәнҗүле, хәтта ачулы сүзләр әйтәсен көтеп, Айзирәк гаепле кешедәй кызарынды. Җизнә исә аны күрүгә җиңеләеп киткәндәй сөенеп елмайды:

– Кайтмассың дип курыккан идек…

– Нишләп инде? Ун минутка гына чыгып тордым…

– Синсез дә калсак, эш харап безнең. Шулай бит, улым?

– Алай ук дияргә… Мин монда бит әле…

– Ташлый күрмә берүк…

Айзирәк, аның чиксез соклану да, ялвару да чагылган карашын күтәрә алмыйча, башын иде, аннан котылу чарасын эзләп, ванна бүлмәсенә борылды.

– Хәзер коендырып алам…

Кранны ачып, озынча зәңгәр ләгәнгә шабырдатып су агызырга керешә. Тик качып котылу мөмкин түгел, сабыйны күтәреп, тар җиргә Касыйм кереп басты.

Айзирәк Солтанны сак кына аның кулыннан алды да:

– Кухня өстәлендә череда төнәтмәсе тора, ярты литрлы банка белән, – диде. – Алып кер әле.

Череданы, ягъни эт тигәнәген Гөлүсә бер букча әзерләп куйган иде. Төнәтмәсе бала тәнендәге тимгелләргә, тапларга – менә дигән дәва.

Иңнәр иңгә, куллар кулга орынып киткәләде – чөнки сабыйны бергә коендырдылар, бергә киендерделәр. Касыйм үзен шундый кечелекле тота, шулкадәр ярарга тырыша, һәр ымы, хәрәкәте, кыюсыз гына күз сирпеп алуы белән рәхмәтен шундый итеп сиздереп тора иде ки, күңелен китерлек сүз әйтү, йөзеңне бозып карау да мөмкин түгел иде.

Юындыргач, сабый тынычланып китте, тәненең кычытуы кимеде булса кирәк. Шешәдән ризыкны да әйбәт кенә имде. Караватына яткыргач, изрәп йоклап китте.

Аннары Айзирәк бәрәңге пешереп изде, колбаса кыздырды. Кара-каршы утырып ашаганда аны-моны сөйләшмәделәр, икесе дә, кыенсынып калгандай, карашларын өстәлдән аермадылар.

Аннары Касыйм олы бүлмәгә чыгып, диванга утырды да, колакчыннар киеп, радио тыңларга кереште, Айзирәк бала әйберләрен юып элеп куйды.

Соңыннан бүлмәгә кереп, Касыймга:

– Төнлә еласа, менә бу шешәдәге сөтне җылытып эчерерсең, – диде.

– Ярый, рәхмәт.

Касыйм әле аның тел төбен аңламый, Айзирәкнең төнге йокысын бүләсе килми, дип кенә уйлый иде. Балдызы чыгу ягына борылгач, аптырап калды:

– Кая киттең?

– Нәзилә апа янына. Аларда йоклыйм.

– Нишләп алай?..

Балдызының ни дияргә белмирәк торганын күреп:

– Әйе шул. Бер төн булса да тыныч йокларсың, арыгансыңдыр, – дип, үз соравына үзе җавап бирде Касыйм.

...Нәзилә карчыкның ишек кыңгыравы иртәнге сәгать биштә зыңгылдады.

– Таң тишегеннән кем йөри икән?

Әбекәй ыңгырашып урыныннан кузгалмакчы иде, ян диваннан Айзирәк сикереп торды.

– Хәзер үзем ачам.

Ишек артында Касыймның тавышы ишетелде:

– Айзирәк, чык әле...

Кызның йөрәге жу итте: бала чирләп киткәнме әллә? Ул халат җиңенә кулын тыга алмый азапланды. Баксаң, сәбәп бик гади икән. Ул ишекне ачкач, Касыйм гаепле кеше кебек ялварып аңа текәлде:

– Эшкә киткәнче бер сәгать кенә булса да черем итеп булмасмы, дигән идем... Төн буе тынгы бирмәде...

Аңа ничек каршы әйтәсең? Айзирәк Василгә антын бозмады, җизнәсе белән икәүдән-икәү генә бикле ишек артында төн уздырмады бит. Хәзер яктырган, көн туган иде инде.

Айзирәк чыгып, сабыйны кулына алды да, кече бүлмәгә кереп китте. Касыйм, спорт костюмын кигән килеш, диванга ауды да оеды. Бала борсалана, ыңгыраша, сызлана иде. Айзирәк өчен вакыт бик әкрен үткән кебек тоелды. Будильник кыңгыравы аны каты сискәндерде. Баксаң, Касыймның торыр вакыты җиткән икән.

Ул ваннага кереп киткән генә иде, ишекне дөбердәттеләр. Бу, мөгаен, Нәзилә карчык иде. Чөнки баскычтан менгән кеше тышкы ишек яңагындагы кыңгырауга баса. Фатирның үз ишеген фәкать уртак коридордагы кеше генә шакый ала. Ни булган әбекәйгә? Шулхәтле каты дөмбәсли, карт кулы ничек чыдый диярсең. Ут капканмы әллә? Айзирәк кулындагы баланы яткызырга өлгермәде, трусиктан гына калган яланаяк Касыйм, юыну бүлмәсеннән чыгып, ишекне киң итеп ачып җибәрде. Бусага артында Васил басып тора иде...

Каршысында чәче тузгыган, ярым ялангач Касыймны, аның артында, халат киеп, бала кочаклап басып торган Айзирәкне күргәч, эчендә нинди давыл купканын үзе генә белгәндер егет. Ул, нишләгәнен аңышмыйча, хуҗаның иңбашына учын куеп, читкә этәрергә теләде, тегесе кузгалмагач, җилкәсе аша үрелеп:

– Син нишләп монда? – диде. Тавышында үпкә, рәнҗеш, ачу, ярсу чагылды. Касыйм, борылып, тәмам коелып төшкән балдызына күз салып алды да кара төк белән капланган күкрәген калкан итеп Васил каршысына куйды.

– Нәрсә ырлыйсың! Кайда булырга тиеш әле ул, үз өендә булмыйча?

– Айзирәк! Син миңа ни дип сүз биргән идең?

Айзирәкнең теле тибрәнде – авызыннан сүзе чыкмады. Мең төрле хис – сөйгәне каршында мондый хәлдә басып торганы өчен оялу, Василнең аңа ышанмавына гарьләнү, җизнәсе каршында егете белән аңлашырга кыенсыну – һәммәсе бергә буталып, аның җегәрен алган иде.

– Әйтер сүзең юктыр шул, болай да һәммәсе аңлашыла! – дип кычкырды үрсәләнеп Васил. – Хуш инде! Бәхетле булыгыз!

Һәм борылып күздән юк та булды. Айзирәк, баланы караватына салырга онытып, егет артыннан талпынган иде, җизнәсе бу юлы күкрәген аның юлына аркылы куйды.

– Кая барасың? Артыннан чапмакчымы әллә? Законлы ирең мәллә ул? Кыланмышы кырга сыймый!

Шулай дип, ишекне шартлатып япты да, йозак ачкычын ике кат борып, бикләп тә куйды...

...Васил бу төнен йокысыз үткәргән иде. Нишләптер борсаланды, башында төрле уйлар буталды. Төннәр шик-шөбһәләрне күпертә, сагышлы уйларны куерта шул. Айзирәккә ышана иде Васил, әлбәттә. Әмма монда сөйгәне үзе генә түгел, башка берәү дә бар бит! Һәм ул башка берәү кыз баладан көчлерәк. Әгәр Айзирәкнең ныклыгы җитмәсә, ни кылмас? Күпме кыз балаларның сафлыгын иң якын кешеләре таплый һәм, кагыйдә буларак, бу пычрак гамәл, олы җинаять җәзасыз гына түгел, билгесез кала!

Ахыр чиктә автобуслар йөри башлаганны да көтеп бетерә алмады, сикереп торды ул. Ә бәлки, анда Айзирәк кыен хәлдә калгандыр... Яклаучы, ярдәм итүче кирәктер...

Ул, шундый шикле уйлардан йөрәге ургып, урамга чыкты да машина туктатты...

Сулышына буылып, баскычтан йөгереп менеп җиткәч, Нәзиләнең кыңгырау төймәсенә басты. Айзирәк шунда булырга тиеш иде. Төймәгә берничә тапкыр сузып-сузып басарга туры килде – карчык авырлык белән кузгалды. Василнең кемлеген кат-кат сорагач, тимер ишекне кысып кына ачты да:

PRESSA.RU

– Айзирәкләрнең кыңгыравы менә бусы! – дип, бармагы белән ишекнең икенче ягына төртте. Аннары сукрана-сукрана кире кереп китте.

– Кара син аны, төн буе йокы бирмәделәр... Көн буе хәл җыя алмам инде...

Васил аны ишетмәде – күрше ишекне йодрыгы белән төяргә кереште.

Төрлесен уйлаган иде, әмма мондый күренешкә тап булырмын дигән уй аның башына да килмәде. Ишек ачылгач, күз алдында ярым шәрә ир белән аның артына ышыкланган, бала күтәргән хатын пәйда булдылар. Тигез, тату гаилә...

Антын бозган кеше кем була? Хыянәтче дип атала ул!

...Бу хәлләрдән соң Айзирәк тә ут эчендә калган иде. Ни уйлады икән Васил аны шушы рәвештә күргәч? Вәгъдәсез диптер. Хыянәтче дип уйлагандыр ул кәләше хакында, хәтта зиначы дип... Очрашырга кирәк аның белән, һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләп бирергә, гафу үтенергә. Аңлар, кичерми калмас! Айзирәк өзгәләнеп елаган баланы караватына салды да кесә телефонына тотынды. Ә аннан ят, битараф гамьсез ир тавышы: «Өзелгән... соңрак шалтыратыгыз»... – дип такылдый торды.

Иртән дә шулай, көндез дә... Бу шуны гына аңлата иде: димәк, Васил аның белән сөйләшергә-аңлашырга теләми...

Әллә тәне кычытып сызлангангамы, бала туктаусыз елады. Апасының бәгырен талаган утларның ялкыны аның да йөрәген өтә микән әллә? Алар икәүләп сызланалар иде... Айзирәк яшьле яңагын аның йомшак битенә терәп кенә юаныч алгандай булды...

Ишек ачылган тавышка бала елаудан туктады, Айзирәккә дә хәл кереп киткәндәй тоелды. Бусагада әнисе басып тора иде. Аллага шөкер, кайтты! Ул хәлне аңлар, киңәш бирер, ярдәм итәр.

Әле генә көн болытлы кебек иде, карасана, тәрәзәләрдән кояш төшкән икән ләбаса... Әнә, ул ике сумкасын куйды да, юыну бүлмәсенә кереп, кулларын юып чыкты, аннары килеп баланы алды.

– Чәй куеп җибәр әле, кызым, – диде.

Аның куенына кергәч, бала да тынычланып китте.

Өстәл уртасына авыл каймагы, яңа бал куелды, тезенә баланы салган хәлдә утырган Ләйсән:

– Син пешергән чәй тәмле шул, – диде. Кызының күңелен күтәрәсе, йөзен ачасы килә иде аның. Ана күңеле баласының бик тә борчулы икәнен күрде, билгеле. Һәм сәбәпчесе кем икәнен дә чамалый иде. Әмма сорашырга ашыкмады. Башта Багыш хәлләрен сөйләп алды. Бераз тын алгач кына:

– Егетең Казандамы әле, әллә киттеме инде? – дип сорады.

– Белмим...

– Ничек белмисең? Сөйләшеп тормыйсызмыни?

– Юк... – диде Айзирәк, карашын яртылаш кына эчелгән чынаягына төбәп.

– Үпкәләштегез дәмени инде?

Айзирәк, әйе дигәнне белдереп, ым какты.

– Авыр сүз әйтмәгәндер бит?

– Әйтте шул...

– Ничек алай? Шундый матур чагыгызда...

– Мин үзем гаепле.

– Ни гаебең булсын синең?

– Миңа, җизнәң белән бер өйдә кунма, дигән иде...

Беразга тынлык урнашты, Ләйсән кулындагы балкашыкның чынаяк читенә бәргәләнеп чыңлаганы гына ишетелеп торды.

– Ирләрнең шул булыр инде! Безнең башка килмәстәйне уйлыйлар, – дип куйды ул ниһаять. – Ходай язмаганны... Безнең кияү ул кадәр намуссыз бәндә түгел лә. Хатынын җирләгәнгә кайчан гына... Ай-яй көнче икән егетең! Син ни дидең инде?

– Нәзилә апага кереп йоклармын, дигән идем...

– Кермәдеңмени?

Айзирәк күзен күтәрми генә, өзек-төтек сүзләр белән соңгы төн эчендә булган хәлләрне сөйләп бирде.

– Алай ик-ә-ән... Ә син аның каршында акланып тормакчымы әллә?

– Ул телефонын өзеп куйган шул...

Ләйсән кояш нурлары коелган тәрәзәгә карады, гүяки шул нурлардан иң кирәкле сүзләрне эзләде.

– Харап икән! Бер-береңне аңлашмаган чаклар булып торыр ул! Кайсыберсен үткәреп җибәрә белергә кирәк. Сөюләре чынлап булса, телефоннан да җавап бирер, килер дә. Ә син ялынма!

– Нишләргә соң инде?

– Хәзердән үк аклана башласаң, кая китә ул! Ышанамы ул сиңа? Хәлеңне аңлыймы? Менә хәзер беленә инде. Шундый чакларда сынала да инде кеше. Көнче ир белән яшәүнең ни икәнен белмисең әле. Төрле ягын уйла! – Ана, өстәл аша үрелеп, кызының кулын учы белән каплады. – Ул да уйласын. Яратуы чынлап булса, ара ерагайган саен, ныграк сагыныр.

Аннары, урыныннан торып, кызы янына килде. Иелеп, аны кочагына алмакчы булды, әмма кулындагы бала арада калды, кыз белән анага бер-берсен кочакларга мөмкинлек бирмәде.

– Ахыры хәерле булсын, дип телик. Артык ашыгасыз бит, кызым. Әдәп өчен генә булса да, туегызны кичектерү тиеш иде. Баштук күңелем тартмады. Бала хәсрәте утында янган ана туйда биеп йөриме? Ул егет тә аңларга тиеш иде, башына тай типмәгән.

Айзирәкнең күзләренә яшь төелде. Бер сүз әйтә алмыйсың, дөрес сөйли әнисе. Тик менә әйткәннәре йөрәк ярасын тагын да ныграк сызлатканын тоймый бугай... Сиздермәскә тырыша тырышуын, тик бу яңалык аның йөрәгенә сары май булып ятты түгелме?

...Гөлүсәнең кырыгын уздырганнан соң, Ләйсән кире Австриягә китәргә җыена башлады.

– Син миңа үпкәләмә, кызым, – диде ул. – Азга булса да түз инде. Бер җае чыкмый калмас. Үзең күреп торасың, Курт, кайт дип, чакырып тора. Ә Касыймның авызыннан, миндә тор, әни, дигән сүзнең чыкканы юк. Әллә соң бала карарга кеше яллыйкмы?



Рәсем: Наталья Васильева

Монысына Айзирәк каршы төште.

– Чит кеше кулына калса, бөтенләй чиргә сабышачагын күр дә тор. Әнә теге чакта, аллергологка баргач, нишләттеләр. Медсестра иде бит әле үзе...

Ул көнне табибә сабыйның тимгел баскан битен, кычулаган колак артларын, култык асларын җентекләп карады, авыр көрсенгәч, балалар кухнясыннан алган сөт-кефирдан башка ризык ашатмаска кушты. Җиллеяңгырлы көн иде. Айзирәк, алгы бүлмәгә чыгып, баланы төрә башлаган иде, узып барган таза гәүдәле шәфкать туташы туктап калды да, солдатка әмер биргән ефрейтор тавышы белән:

– Шулай итеп төрәләрмени! – диде. – Ишектән чыгуга таралып төшәчәк бит бу! Кая, кит әле!

Һәм Айзирәкне читкә этәреп, тәвәккәл хәрәкәтләр белән сабыйның юрганын тыгызлап урап, киң зәңгәр тасмасын шундый кысып бәйләде, ташкурчак ясагандай итеп куйды.

Урамга чыгуга, Солтан иңрәп еларга тотынды. Арбасына салып, юрганын бушаткач кына хәл керде мескенгә.

Белер-белмәс кешегә ышанып тапшырсаң, нишләтмәсләр сабыйны! Теле ачылмаган, каршы әйтә алмый!

– Алай да... Дус бар, дошман бар... – диде Ләйсән уйланып. – Мирнең авызы иләк, томалый торган гына түгел. Кече бүлмә ишегенә йозак салыйммы әллә?

...Кичен моны ишеткәч, Касыймның кашлары җыерылды, билгеле.

– Андыйга кулың ята бит синең, кияү, – дип, аның салпы ягына салам кыстырып куйды кайнана. – Кыз баланың нинди чагы булмас. Син дә үз өеңдә гел генә алдыңны-артыңны карап йөри алмассың... Ә болай коммунал фатирдагы кебек, һәркайсыгызның үз куышы булыр.

Икенче көнне эштән Касыйм сап-сары, йомры тоткалы алагаем зур йозак күтәреп кайтты. Бер генә түгел, ике борылып бикләнә торганын. Кашларын җыерып, үҗәтләнеп, каты шакылдап, өтерге белән ишекне тиште, кадак какты. Эшен төгәлләгәч, Ләйсәнгә:

– Бикләп кара, әби, – диде. – Җаның тындымы инде?

– Нинди әби, ди, мин сиңа... Миннән алынды инде ул звание... Озакка сузмассың, башка берәүгә бирерсең аны, Алла кушса...

...Китте Ләйсән. Калды кызы бала кочаклап... Көн дә күршегә кереп кунып булмый. Нәзилә карчык караңгы чырай күрсәтмәс тә иде, тик менә бала төн буе елый, ә эти кешенең иртән эшкә барасы бар.

Айзирәк төннәрен сабый белән кече бүлмәгә бикләнеп үткәрә торган булды.

PRESSA.RU



Пар алма

Алларыма килеп тезләндең син,
Кулларыңда иде пар алма.
Төшләремә кереп һәр көн шулай,
Таң атуга китеп югалма.

Кушымта:
Өзелепләр төште пар алмакай,
Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Пар алмадай идек, пар алмадай,
Үз күзләрем тиде, күрәсең.
Багалмадай, бигрәк матур булып,
Төшләремә генә керәсең.

Кушымта.

Җанга ява бары салкын көзләр,
Бар төсләрне җирдә тигезләп.
Төшләремдә күргән пар алманы
Бакчаларда йөрим мин эзләп.

Кушымта.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

ПАР АЛМАДАЙ ИДЕК, БАГАЛМАДАЙ...

Җырлар көндәлегемә: «Пар алма» җыры 1995 елда «УНИКС» концертлар залында Зөфәр Хәйретдинов белән Алсу Хисамиева башкаруында беренче тапкыр тамашачыга тәкъдим ителде», – дип язып куйганмын. Менә инде 22 ел бу затлы җыр минем визит карточкам булып тора. Затлы сүзен уңайсызланып кулланмыйм. Шигыремә көйне чорыбызның талантлы композиторы иҗат итте, аңа гомер бирде, «Җыр бәйгесе» лауреаты дәрәҗәсенә күтәрде. Яшермим, иҗади әсәрне гомерле итү аны иҗат итүчеләрдән еллар дәвамында игътибар, тугрылык сорый. Зөфәр дустым, бүген дә безнең уртак иҗат җимешебезне үз репертуарыннан төшермичә, заманча аранжировкада ретро җырлар арасында олы сәхнәдә балкытып ала.

«Пар алма»га кадәр без Зөфәр белән «Ялгыз әнкәй», «Кура җиләк» җырларын иҗат иткән идек инде. Безнең шигъри әсәрне, музыканы тоемлау сәләте туры килә, алай гына да түгел, бер-берсен тулыландыра булып чыкты. Иҗатчыларның сүзсез аңлашуы шулдыр, мөгаен. Аннан соң да ул минем сүзләргә язылган дистәләгән җырның көй авторы һәм башкаручысы булды. Әмма халык безне нәкъ менә шушы җырыбыз аша иҗатташ дуслар, җыр өлкәсендә «тандем» итеп таныды.

«Өзелә бит инде үзәккәем, ялгызлыктан дәва булмагач» дигән – бәгырьдән өзелеп төшкән җыр юлларыннан күңеле тулып, минем «ялгызлыгыма» шифа булырга, хәлемә керергә теләүчеләр аз булмады ул чакта. «Ул апама багышлап язылган», – дигәч, «Кеше хәсрәтен болай ук җан кылларында тибрәтеп, мондый моңлы җыр итеп тудырып буламыни?» – дигән гаҗәпләнү белдереп, танышу теләкләрен сүндерергә мәҗбүр булалар иде.

Җизнәм арабыздан бик яшьли китте. Апам аңа бик яратып, 18 яшендә үк кияүгә чыккан иде. Җизни юл фаҗигасендә һәлак булганнан соң, апам шалтырата:

– Сеңлем! Җизнәң тагын төшкә керде. Кулында пар алма. Алларыма килеп тезләнде дә алмаларны миңа сузды. Алам гына дигәндә, алар җизнәңнең кулыннан тәгәрәп төшеп китте. Бигрәк пар алма кебек идек шул! Үз күзләрем тигәндер...

Апамны тыңлап та бетермичә, мин трубканы куйдым да шигырь язарга утырдым. Сөйләгәннәрен сүзен-сүзгә кәгазьгә төшердем. Көйли-көйли, елый-елый яздым. Язып бетердем дә Зөфәрләргә чыгып йөгердем. Без ул вакытта бер-беребезгә якын гына йортларда яши идек. Балаларыбыз бер бакчага йөрде. Якыннан танышуыбыз да шунда булды.

Мин килгәндә, Зөфәр ишегалдында келәм кага иде. Бер тынга язылган шигыремне тизрәк аңа бирергә ашыктым.

– Зөфәр! Мин өр-яңа шигырь яздым! «Пар алма!» – дим.

Ул, кулымдагы кәгазьне алып, шигырьне көйли-көйли укый башлады. Бөтен күңелем белән тоеп торам: Зөфәр дә минем дулкынга күчте. Янәшәсендә басып торганымны да онытып, келәмен култык астына кыстырды да подъезд ишегенә чумды.

Икенче көнне иртән гадәттәгечә балалар бакчасында очраштык.

– Синең шигырьгә көй яздым. Бер атнадан Алсу Хисамиева белән уртак коцертыбызга, җырның премьерасына көтеп калабыз, – ди композиторым.

Сөенечтән күзләремә яшьләр килде. Очып кайттым өйгә. Күпләрнең җанын кузгатырлык яңа җыр шулай туды!

Концертка аеруча дулкынланып әзерләндем. Минем җыр да яңгыраячак бит! Ничек кабул итәрләр? Ошатырлармы? Бүләккә... чәчәк сатып алмаска, алмалар алып барырга булдым. Иң эреләрен, алсуларын, матурларын сайладым. Халык җырны көчле алкышларга күмде. Сәхнәгә күтәрелеп, Алсу белән Зөфәргә алмалар суздым. Меңнән артык тамашачылык зал икенче тапкыр алкышлар күкрәвеннән тетрәп алды.

Урыным Зөфәрнең хатыны Зөһрә белән янәшә иде. Мин янына килеп утыргач, йөзләре алсу алмадай булып тулышкан гүзәл ханым колагыма нидер пышылдады. Дулкынлану, шатлык хисләреннән күрү, ишетү сәләтен югалтсам да, аның әйткәннәренең: «Ярый әле икесенә дә алмаларны пар-пар итеп бирергә башың җиткән, юкса...» – дигән кадәресен хәтер сандыгыма шудырдым. Чираттагы җыр яңгырый иде инде...

«Пар алма» тиз арада танылып китте: аны концертларда үзешчәннәр дә, мәҗлесләрдә кунак өстәле янында да җырлый башладылар. Бу җыр чыкканан соң берничә ел узгач, телевидение хезмәткәрләре халык арасында ниндидер сораштыру уздырды. Ул танылган җырларга багышланган һәм «Сез кайсы җырны яратасыз, аның авторлары кем?» дигән сорауга җавап алудан гыйбарәт иде. Шунда бер яшь кенә егет: «Авторларын белмим, ләкин җырлап күрсәтә алам яраткан җырымны», – дип, «Пар алма» җырының бер куплетын бик матур итеп башкарган иде. Еллар узгач, татар җыр сәнгатенә керткән өлешем өчен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә дә ия булдым, әмма минем иҗатыма бирелгән иң зур бәя менә шул – халык арасында үз тамашачым һәм җырларымны яратып башкаручылар булу дип саныйм. Җырга гомерне шагыйрь, композитор һәм җырчыдан торган өчлек бирсә, аның язмышын халык мәхәббәте билгели: йә яшәп китә җыр, йә туугa эзсез югала...

«Пар алма»ны озак еллар Айдар Галимов та зур сәхнәләрдә яңгыратты, күңел биреп башкарды, концертларына чакырды. Кайда гына, кем генә башкарса да, җырны тыныч кына тыңлый алмыйм. Күзләремне йомам да әле генә солдат хезмәтеннән кайткан мәһабәт гәүдәле егет белән җитәкләшеп барган апамны, аларның тигез, әмма кыска гомерле мәхәббәтенең, пар алма булып, көзге бакча учларына өзелеп төшкәнен күргәндәй булам.

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

ЭКСПЕДИЦИЯНЕҢ СОҢГЫ КӨНЕ. САУБУЛЛАШЫР МИНУТЛАР ДА ЕРАК ТҮГЕЛ. НИЧЕК БУЛЫР УЛ ХУШЛАШУ КИЧӘСЕ?

Гөлчәчәк бу җәйне әле озак сагыныр. Очып кына үтеп киткән бу көн, күңелне актарган җырлар, әллә нәрсә вәгъдә итмәсә дә, йөрәкне алгысытып куйган бу кичә, берәүнең җанга якын карашы...

Эльмира ЗАКИРОВА

САГЫНЫП КАЙТЫП КЕРСӘҢ...

(Ахыры. Башы 2-3 нче саннарда.)

3 июль, Көндәшле. Көннәр тәгәри генә! Иртән өй борынча әбиләрдә йөрибез, кич – концерт, концерттан соң авыл яшьләре белән «Әкълимә» җырына шейк сикерәбез.

Концертларда Айсылу белән Алик Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр»еннән бер өзек уйный. Айсылу – Сәрби, Алик – Хәйретдин ролендә. Хәйретдиннең Сәрбине кочып үбеп алу күренеше бар. Гадәттә, үбешкән кыяфәт кенә ясыйлар иде. Бүген Алик Айсылуны чынлап торып үбеп алды сәхнәдә. Кып-кызыл булып чыкты Сәрби-Айсылу. Хәер, бу бик табигый да күренде. Яраттылар, кул чаптылар. Ә сәхнә артында Сәрби... «Син нәрсә? Мине кем дип белдең!» – дип, «чалт» Хәйретдиннең яңагына! Егетнең: «Их, син! Мин бит тамашачыны ышандырыр өчен генә... Син бөтен барлыгың белән рольгә керергә тиеш», – дигән сүзләрен Айсылу колагына да элмәде.

...Кич Алик Айсылуга бер дәфтәр бите сузды: «Укы! Сиңа...» – ди.

Үпкәләмә, Сылу, үпкәләмә!

Бурнаш үптерде бит, мин түгел...
Юньсез диеп мине күп сөйлиләр,
Яхшы якларым да юк түгел...

4 июль, Карыш. Бездә бүген аулак өй – җитәкчебез экспедициягә бәйле кайбер эшләрне хәл итәргә дип, иртүк район үзәгенә киткән иде. Егетләр, гадәттәгечә, изрәп, тәмле төшләр күреп йоклый. Иң башта шул йокы чүлмәкләрен кызык итәргә булдык: пионер лагерендагыча, битләренә, мыекларына теш пастасы сылап чыктык. «Аһ, сезне!..» – дип тузынып, иң алдан Алик сикереп торды, Тимур, Зөфәр... Китте чыр-чу, мендәрләр атышу! Җыен бала-чага! Алик, күзләрен уып, миңа озак кына карап торды: «Кызый, мин сине төштә күрдем... Кулыңда ак чәчәкләр иде. Син елыйсың, мин яшьләреңне сөртәм. Нәрсәгә икән? Сәер, бик сәер...» «Сөенчегә!» – дип юрадылар.

Егетләрне суга җибәрдек. Үзебез сер сөйләштек.

– Радик белән без бертуганнар кебек охшаш, әйеме, кызлар? Чәчләр, иреннәр... Минем абый сыман ул, – дип, Нурия мактана башлады. Гашыйк булган!

Лира яшереп тә тормады, туп-турысын әйтте:

– Миңа ул бар яктан ошый! Идеал егет шундый буладыр!

– Үзенә син ошыйсың микән соң? – дип тешләп алды Зөләйха.

– Юктыр... Аның күңеленә бала-чага кебек беркатлы Гөлчәчәк, Айсылулар якын бугай. Игътибар иттегезме, Чәчкә ди бит... – Лира миңа күз кысып куйды. Ул соңгы арада Алик белән дуслашып киткән иде.

Ә бу сөйләшүләр Айсылуга бар ни дә, юк ни! Күзләрендә сөенечле моң. Чәч толымнарын әледән-әле рәтләштереп, ашыга-ашыга кәгазенә сүзләр тезә.

Кыз озаткан йортның баласыдай,
Июль җиле уйный – нарасый!
Җәй картая: ул-кызлары җиткән –
Яшь юкәләр бүген туй ясый!
Бакчаларда тәмле хуш ис аңкый,
Кәләш-юкә анда бизәнә.
Усак кына әнә үчле егет кебек
Койма аша ботаклары белән кизәнә.
Юкәләрнең шау чәчәктә чагы,
Яшь юкәләр бүген туй ясый...
Сагыну гына ярларыннан ташый,
Күңел генә никтер гел ярсый...

5 июль, Сәйтәк. Алик белән Тимурның, гитара кылларына чиертә-чиертә, концерт саен җырлаган, залны сихерләгән җыры бүген бөтенләй әллә нишләтте:

Сау булыгыз, кызлар! / Сагынырсыз, кызлар! / Сагынырсыз әле без киткәч...

Әйтерсең махсус безнең белән хушлашу өчен язылган! Күзләрдә – аерылышу сагышы. Алик кулларына баян алды. Зөфәр белән Фирүзә, Наил белән Зөләйха вальска бөтерелә башлады. Айсылу белән икәүләп чыккан идек, каршыбызда кай арада Тимур белән Радик пәйда булды? Безне аерып алдылар. Мин Радик белән калдым. Вальс көенә озак әйләндекме, хәтерләмим. Ул да дәшми, мин дә... Сүзсез генә, бер-беребезгә карарга да кыймыйча, Алик уйнап туктаганчы моң дулкынында тирбәлдек. Тагын синең белән вальска әйләнә алырбызмы, Радик? Бу соңгысы булмасмы? Хуш, Радик... Күңелдән шул «хуш»ны мең кат кабатлап, керфекләремне курка-курка гына күтәреп, аңа карадым. Карадым да, башым әйләнеп, чак кына аның кулыннан ычкынып китмәдем. Аһ, туры күз карашларын мин күтәрә алмыйм икән. Битләремә алсулык йөгерде, керфекләремне түбән төшердем...

Елыйсылар килә: бүген соңгы кичебез.

Ә халык гөр килә теге башта! Бездән башка гына «Ачык авыз»лы уйнап яталар. Ачык авызларга җәза бирәләр әнә. Айсылу лампочкага карап, «һау-һау» дип, эт булып өрә! Тимур грузиннарның «лезгинка»сын бии! Фирүзә белән Зөфәрне «йолдыз санарга» чыгарып җибәргәннәр. Лира «третий лишний» дигән уенны өйрәтеп маташа. Бу уен да шул ук «танцы» инде, тик бер кешегә ялгыз гына әйләнергә туры килә. Оһо! Радик берүзе урындык күтәреп йөри. Кемне биюгә чакырыр икән? Кайсы парларны аерып алыр? Шулай уйлап, Айсылу белән «Сарман вальсы»на әйләндем. Уф, беттем, безгә таба әкәмәт кыяфәттә Радик атлый. Ярый, Айсылуны баш-аягы белән аңа биреп җибәрербез. Юраганым юш килде: Радик безнең янда иде инде. Хәзер кайсыбызның исемен әйтер? Минекенме? Әгәр әйтмәсә? Айсылу дисә?.. Шуннан куркып, паровоздан алда чаптым: «Бар инде, Айсылу!» – дип, җәһәт кенә урындыкка тотындым. «Юк, миңа – Чәчкә!» – димәсенме! Радикның шул сүзеннән башым әйләнеп китте, аяк астындагы идән шуыша башлагандай тоелды. Кыяр-кыймас кына Радикның җилкәсенә кулларымны салдым. Әле бер парны, әле икенчесен аерып, берәрсен урындык белән әйләндертәләр. Безне бөтенләй оныттылар! Әйтерсең бу дөньяда без икәү генә!

– Чәчкә!

– Әү!

– Сиңа зәңгәр күлмәк килешә икән! Чәчләрең Мирей Матьеныкы кебек...

– ...

– Син мине театрга чакырам, диден.

– О-о! Көзгә кадәр ерак әле!

– Казанга кайткач, очрашырбыз бит, Чәчкә?

– Мин пионер лагерена практикага китәм, Радик!

– Юлларың уңсын, күңелле булсын... Сөйгән ярың уйлар синең хакта...

Нинди сөйгән яр? Кара, кара, Радик безнең җыр сүзләре белән сөйләшә икән бит! Көлеп җибәрдем. Ул да елмайды.

– Ак чәчәкләр белән каршы алырмын, сагынып кайтып керсәң, – дип җыр сүзләрен кабатлады... – Сагынырсың бит, Чәчкә?

Сагынырмын, Радик! Бу җәй, бу көн яшьлегемнең иң матур мизгеле булып йөрәгемә кереп калыр...

PRESSA.RU



Асия
ЮНЫСОВА

ӘЛЛӘ НИЧӘ ЯЗГАНЫМ БАР ИНДЕ – МУНЧАГА БАРГАН САЕН, ЯЗАРЫМА АЗЫК ТАБАМ.

Бу юлы да «кармагымдагы җим» әҗерле булыр кебек. Мунча ул шундый урын, анда тәннәр генә түгел, җаннар да язылып китә. Янәшә сәкедә мунчаның бөтен тәмен, ләззәтен белеп бер ханым юына. Кустодиев картиналарындагы хатын-кызларга охшатам аны. Тулы, тыгыз тәнле, хәтта бераз тазарак та дияр идем әле. Су белән юылып төшми торган матурлык иясе дә әле ул. Сөйләшә-сөйләшә юынабыз. Мунчада кеше аз. Иркенәергә берәү дә комачауламый. Сөйләшергә дә җайлы икән үзе белән. Безнең сүзләр акрын-акрын гына юнәлешен таба. Һаман да шул хатын-кыз язмышы...

ЧАЛЫ КОШЫ

Ул ханым Әнисә исемле икән. Сөйләшеп бетмәгән сүзләрне дәвам итәр өчен тагын бер очрашасы иде дә бит. Адресын әйтергә ашыкмый. «Монда сөйләшкән монда калсын инде, – дип, түгәрәкләп куясы килә яңа танышымның. – Аннары өсти тагын: – Минем тормышны китап итеп язарлык ул. Яза да башлаган идем инде. Улым үлгәч ташладым. Кемгә кирәк минем язмаларым. Югыйсә өч дәфтәр иде».

Мин Әнисәне киенү бүлмәсенә озата чыгам. Киткәндә колагыма пышылдап кына адресын әйтә. Мин ул адресны юл буе яттан кабатлыйм. Онытa күрмим тагын. Эзләп йөрерсең аннан шәһәр урамнарыннан! Бәлки, чын адресын әйтмәгәндер дә әле.

Ике атналап узгач, киттем хәтердәге адрес буенча Әнисәне юллап. Алдамаган икән. Фәлән йөзләгән фатирлы, дистәдән артык катлы йортта яши икән. Ишек шунда ук ачылды. Әнисәне «сюрприз» каушатмады.

– Сорамый да ачасың! Мине танийсыңмы, ичмасам?

– Таныдым.

Кухняга узабыз. Бер мәл фатирдагы чисталыкка, тәртипкә шаккатып торам. Февраль бураннары басылып та җитмәгән, инде Әнисәнең тәрәзәләре, без язга әзер дигәндәй, көлеп тора. Сөйләшә башлаганчы беренче җөмләм дә шуңа күрә сәеррәк яңгырый: «Кем юа бу тәрәзәләрне?» Әнисә елмаеп кына куя: «Үзем. Тумбочка белән плитә өстенә куна тактасын куям да менеп басам. Әни мине чисталыкка, эшкә өйрәтте. Ишекне бикләп куеп идән юдыра торган иде».

Хуш. Әнисә газ плитәсенә терәлгән пенал шкафтан үрелеп кенә фотолар тартып чыгара. Ул шулар ярдәмендә сөйләшүгә документаль төсмер бирмәкче. Югыйсә минем кебек хисле журналист өчен иң дәлилле документ кешенең күзләре инде ул. Әнисәнең яшькелтзәңгәр күзләре шундый да көләч, шундый да ышаныч белән карыйлар.

«...Менә монда миңа 7 яшь...» Чаялыгы чәчрәп торган курчак кебек матур кыз баладан күземне ала алмыйм. «Җиткән кыз булып өлгергәч, миңа да, шул Фәридәгә кебек, дәшеп кала торганнар иде: Гөлбәшикәр! Ә мин ул чагында Фәридәне белмим әле. Тик шулай да, күңелем булып, чытлыкланып көлә торган идем. Төрек язучысының ул әсәрен ун тапкыр гына укыганмындыр. Киносын да күп карадым. Чытлыклану юньлегә китерми лә ул. – Әйе шул, дип кисәткәндәй, Әнисәнең култык таяклары дөбердәп идәнгә төшеп китә. – Хәер, минем бер гаебем дә юк. Булса да, әни кушканны тиз генә үтәп кайтырга тырышу гына булгандыр... Миңниса белән Шәмсивәлинең матур кызына күз генә тиде, дигәннәр ул чагында».

Кибеттән йөгереп кайтып килгән 7 яшьлек кыз бала колонка янында су сибешеп уйнаган дус кызлары янында туктап су эчмәкче... Иренен салкын суга тидерәм дип иелгән Әнисә өстенә самосвал менгәнен абайламый да кала. Шифаханәдә аңына килгәндә инде кызның сул аягы бот төбеннән киселгән. Аяк очында ике абыйсы елашып утыралар. «Әни, ник елыйлар алар?» Әни кеше еламый. Әле кызын да кисәтә: «Еласаң, өйгә алып кайтмыйм!» Юк-юк, елый була ди мени! Әнисә үзләренең подвалдагы 16 квадрат метрлы «өйләрен» шундый сагынды. Еламый ул! Кайтсыннар гына өйгә! Быел укырга керә бит әле ул. Өч атнадан мәктәпкә барасы.

Әнисәнең мәктәпкә ничек йөрисе инде хәл ителгән. Беренче елны әнисе кызын көн дә үзе күтәреп илтә. Аннары ике абый сеңелләрен кулдан да төшермиләр. Аннарыдан ары аннарыда – ике култык таягы! Сак кына сорап куям: «Култык таяклары да туза торгандыр ул?» «Елга өчәрдән санасаң, 150 пар таяк тузгандыр». Таяк! Аяк! Ә аяк киемнәренең сыңары кая китеп бара торган иде?

Чалы кошы! Үзеннән-үзе әсәр каһарманы Фәридә белән чагыштырам икән.

– Ия табылды аларга. Первомайская урамында бер апа бар иде. Аяк киеме үлчәме туры килә. Аның уң аягы юк иде. Шул килеш тә, җирдә үрмәләп, яшелчә кәлшәләре үстереп сата торган иде. Ике улына квартира сатып алды, бахыр. Үзе җир идәнле фатирда яшәде. Әллә нинди сукыр мәхәббәт белән яратты ул балаларын. Мәрхүмә булды инде. Соңгы ун елда туфлиләремнең сыңарлары заяга аунап ята. Мин бит яшь чагында 12 шәр сантиметрлы үкчәле туфлиләр дә кидем. Сез, ни, уйламагыз мине боегып кына утыргандыр дип, Горький паркына иптәш кызлар белән танцыларга да бара идем әле мин. 12 кыз гел бергә йөрдек. Биемәсәм ни, бүтәннәр биегәнен карап торам. Ресторанга баргында да үзләреннән калдырмадылар. «Бусы ни дип килгән инде монда? – дигәннәрен дә ишетеп калырга туры килгәләде. – Әле генә көләч күзләрне томан сара. – Кеше төсле буласы, чын кеше буласы бик килә бит ул.

– Тик кешеләргә бүтәннәрдән ким түгеллегемне аңлата алмый йөдәгән чаклар булгалады шул...

– Мәктәп еллары, аяу белмәс сыйныфташлар хакында әйтүеңме?

– Юк ла инде. Сыйныфташлар мине лидер итеп таныды. Мәктәпкә килүгә билгә бәйләп куела торган протезны (башта протез кигереп караганнар иде) почмакка сөяп куям да, авыр чөнки, сыңар аякта титаклый торган идем. Аннары гел култык таяклары белән генә йөрдем. Такта янына да чыгам, кеше рәтеннән линейкада да басып торам. Сынатырга ярамый, мин бит отряд советы председателе! Тик бер үкенеч – мине бер мәртәбә дә пионер лагерена алмадылар. Бик тә, бик тә Артекка барасым килгән иде. Диңгезне күрәсем... Рәхмәт әтигә, ул мине йөзәргә өйрәтте. Йөри алмасаң, йөзәрсең, диде. Минем хакка Идел буенда, качып-посып, бакча өе салдылар. Ә бердән бер көнне поездга утырдым да Одессага китеп бардым – диңгезгә! Миңа 14 яшь иде ул чагында. Әти-әни тыймады. Югалмасыма

PRESSA.RU

ышаналар иде. Аннары диңгезгә ел саен йөрдем. Чиратымны ике тәүлек көтеп утырсам утырам, фәкать кунакханәдә генә яшим. Мин – подвалдан якты дөньяга чыккан кыз – шул рәвешле шаһзадә сыман яшәп ала торган идем. Акча бар – әни белән шәл бәйли торган идек кыш буе.

– Туй фотосы түгелме? Кәләш син бит! Ә кияү кем?

– Шыгырдан егете. Вагыйзь исемле. «Аромат» фабрикасында баш икътисадчы иде ул. Ә мин – студент. 20 яшемдә бардым аңа. Яратып өйләнде. Ни гаҗәп, әти-әнисе дә каршы килмәделәр. 16 квадрат метрлы фатирыбызның бер почмагында чаршау корып яши башладык. Улыбыз Руслан туды. Мин университетны ташлап, автовокзалда билет сата башладым. Тик менә фатир мәсьәләсе... Тәвәккәлләп, Терешкова янына бардым. Шулай итеп, безнең яшь гаилә фатирлы булды. Әйбәт кенә яшәп ятканда ирем кунарга кайтмады. Хыянәт! Фатирны аңа калдырып, улым белән подвалга кайттым. Иң авыры бу түгел!

Горур идем, кичерә алмадым.

Иң авырын да татыган икән шул Әнисәкәй. Эштән арып-талып кайтып килгән Әнисәне күршесе ХӘБӘР! белән каршылый: «Тизрәк кыймылда! Анда улыңны «КАМАЗ» таптады! Аякларын кисәргә алып киттеләр!» Русланга да 7 яшь иде. Аһ балакаем! Минем язмышымны кабатлыйсың! Шушы уй башыннан сызылып үтүгә Әнисә һушын югалта. Дүрт айлык көмәнен дә... Икенче ире кайгы кергән йорттан китү ягын карый. Югыйсә Әнисәнең ризалыгын озак яулап өйләнгән була да бит. Ир-атлар кайгыларга чыдамый шул ул. «Шөкер, улымның аякларын сакладылар, бераз кыскарак кына булып калдылар. Гаҗәп акыллы, гаҗәп тәүфыйклы улым гомерсез булып чыкты. Авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган иде. 33 яшендә авырып үлде. Улым артыннан берәм-берәм әти белән әни дә китеп бардылар. Шул көннән бирле мин намазда. Ходай Тәгаләдән сабырлык сорыйм. Әти белән әнине тәрбияли, кадерли алганыма бик сөенәм. Абыйларның да берсе иртә вафат булды, икенчесе бүтән кавем белән кушылып, безнеке булудан туктады. «Ярый әле, кызым, син бар, ярый әле теге вакытта үлмәгәнсең», – ди торган иде әти».

Олы яшьтәге авыруны карау сәламәт кешегә дә җиңел түгел. Җитмәсә, кабаланып йөргәндә абынып китеп, Әнисә сыңар аягын да сындыра. Ул чагында ничек тернәкләнгәндер? Әмма аякны сындырудан курку калган. «Кибетләрдә йөргәндә куркам. Анда гел идән юып торалар. Таягым таеп китәр дә, егылып, аягымны сындырырмын кебек».

Мин бер мизгелгә дөньяга Әнисә күзләре белән карап алам. Әнә урамга яңа кар яуган. Әнисә карны түгел, янәшә барган аяк эзләрен күрә. Әнә, берәү баласын иңенә утырткан. Әнисә, бер мәртәбә дә урамнан баламны күтәреп уза алмадым дип уйлый.

Мәхрүмлекләр! Тоташ мәхрүмлекләр! Барысына да исерек шофер гаепле...

«Мин мәхәббәткә коенып яшәдем! – Әнисәнең йөзе янәдән көләч. – Миңа 8 яшь иде, аңа – безнең урамның башкисәренә – 18! Мин капка төбендә утырганда шул башкисәр гел башымнан сыйпап уза. Әнигә гел әйтә: «Бу кызыңны урлап китәм, Миңниса апа!» Соңрак машина алды бу. Мине мәктәпкә илтә, алып кайта. Тик урлап китәргә өлгермәде. Төрмәгә утыртып куйдылар Илдар абыйны. Ә мин ул төрмәдә утырган чагында тормышымны бозып куярга өлгердем. Югыйсә адвокат булам да Илдар абыйны төрмәдән кайтарам дип кенә юрист булырга җыенган идем. Еллар узгач, аны миңа улым Руслан табып кайтты. Кинога киткән улым: «Әни, менә мин үземә әти алып кайттым», – дип кайтып керде. Ул чагында миңа – 29, аңа 39 яшь иде. Бер дә өйләнмәгән, ә мин инде ике ирдән аерылган балалы хатын. Илдар белән аның вафатына кадәр бик матур пар булып 20 ел яшәп калдык. Яратуның ни икәнен беләм. Ә ярату минем өчен беренче урында. Ярату дигәннән, бер тарих сөйлим әле. Казан университетында Латвиядән килгән бер егет аспирантурада укыды. Шул кеше, миңа гашыйк булып, тәмам чиргә сабышкан иде. Килә дә баса безнең йорт янына. Койма аша карап тора. Кинога чакыра. Югыйсә күрә бит инде нинди икәнемне. Үзе Ригасына кайтып киткәч, мине кунакка чакырды. Ә мин сәяхәтләр яратам. Бардым. Бу кеше ул вакытта «Даугава» журналында редактор булып эшли иде. Яратам, ди. Өйләнәм, ди. Укытам, ди. Синнән пара-олимпияче ясыйм, ди. Соборга орган тыңларга баргач, кулына күзем төште моның: шау сипкел! Шунда бу кешене мәңге ярата алмаячагымны аңладым. Кайттым да киттем, Вагыйзьгә кияүгә чыктым. Трофимов артымнан килгән. Кунакханәдә тукталган. Мине очрашуга чакырып хат язган. Вагыйзь көнләшүдән котырып чыкты инде. Миннән җавап хаты яздырды. «Килмә, көтмә, яратмыйм», – дип яздым.

Илдары белән парлап биегән чакларын сагына Әнисә. Ничекме? Илдар Гөлбәшикәрен аркасыннан кочып ала да матур музыкага әй «бииләр» икәү! «Мин таякларымны ташлап, тураеп басам, аның кочагында төп-төз торам. Тирбәләм. Буем да кыска түгел икән минем. Бик рәхәт була торган иде шул чагында. Илдар белән дөбердәтеп дөнья көттек. Менә соңгы машинамны бергә төзегән йортыбызны саткан акчага алдым. Машинасыз ярамый миңа. Хөкүмәттән даулап йөри торган гадәтем юк. Бөтен ирешкәнем үз көчем белән. Ялгыз да яшәп була анысы.

Тик яратусыз яшәү кыен. Ә хыянәтче Вагыйзь һаман шалтырата. Ялгыз яши».

Әнисә мине: «Гел сөйләшеп булмады. Әле күпме сүзләр калды. Минем гомер язылмаган роман ул», – дип озатып калды. Романыңның дәвамы матур, яратуга, кадергә мул булсын иде синең, Әнисәкәй! Иң мөһиме – өметең киселмәсен!



ГЫЙБАДУЛЛИНА Лилия
(әдәби тәхәллүсе – Лилия ГЫЙБАШ)

Казан дәүләт университеты

Кияүдә, ике ул үстерә

Карьера: шагыйрә.

Тормыш шигаре: «Барысы да вакытлыча. Мәңгелеккә бердәнбер юл – балаларым».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Ә бездә – өй туе!


Күптән түгел иркенрәк яңа фатирга күчендек. Шәһәр читендә: тыныч, иркен, рәхәт. Балалар бакчасы да өебезгә терәлеп кенә тора диярлек. Бу арада өй туе үткәрү, яңа җиһаз, пәрдә-чаршау ише нәрсәләр алу кебек күңелле мәшәкатьләр белән мәшгуль булдым. Яңа өйдә яңача яшисе килә, шуңа да бөтен нәрсәне үзебезгә ошаганны сайлап алдык. Матур да, күңелгә дә ятышлы булсын дип. Оя кору – адәм баласы өчен җир йөзендәге иң зур бәхетнең берсе икән ул.

Шәхесләребезгә – кадер-хөрмәт!

Күптән түгел Кадыйр Сибгатуллинның юбилее уңаеннан яңа китабы дөнья күрде. Соңгы вакытта иҗади мирасы матбугат чараларында шактый яктыртылды, Чаллыда шагыйрьгә багышланган кичә дә үткәрелде. Бу эшләрдә Кадыйр абыйның әдәби дәвамчысы, аның иҗатын өйрәнү һәм пропагандалауга зур өлеш керткән Факил Сафинның тырышлыгы зур булды. Сүз уңаеннан, Факил абый – быел Тукай премиясенә тәкъдим ителгән кандидатларның берсе. Аңа ихластан уңышлар телим. Кадыйр Сибгатуллин, Факил Сафин – үзем өчен өр-яңадан ачкан каләм әһелләре. Иҗатларына сокланам!

Озак яшим, дисәң – бала тап!




Швеция галимнәре раславынча, балалары күбрәк булган кешеләр озаграк яши икән. Безнең әбекәй, мәсәлән, 8 бала табып үстергән. Гаилә йөген дә, колхоз йөген дә тарткан. Эштән арып кайтып кергән уңайга мультиваркасында ашы пешеп тормаган, керләрен автомат машина юмаган... Узган ел 91 яше тулыр алдыннан дөнья куйды ул. Икенче әбекәем 87 дә бакыйлыкка күчте. Үлгәнче үзе чабына-чабына мунча кереп, күлмәкләрен шунда юып та кайта иде. Килендгә эш арттырмый, янәсе. Ул әбекәем – 5 бала анасы. Дөрес әйтә ул Швеция галимнәре!








сөендерде

көендерде

сөендерде

көендерде

сөендерде

көендерде

Дарулар нигәдер булышмый

Грипп эпидемиясе быел безне дә читләтеп узмады. Ике улыма да шушы зәхмәт кагылды. Температураларын төшерә алмый азапландык. Бернинди дару да алмый. Узган елгы даруларны биреп карыйм: файдасы аз.
Әллә вируслары да елдан-ел аза бара, әллә без дәвалый белмибез, әллә инде иммунитетның каршы торучанлыгы түбән? Югыйсә, витамин дип, яшелчә, җиләк-җимештән өзелгән юк, сәламәт яшәү рәвеше дип тырышкан булабыз. Әле менә терелделәр дә, авылда әбиләрендә тернәкләнү терапиясе үтеп яталар: саф һава, авыл сөте, йомыркасы дигәндәй...

Бирәүгә – тау кадәр, икенчеләргә – тамчылап...

«Гагарин кубогы»на ярышлар бара. Дөресен әйтәм, коточкыч зур акчалар түгеп, әллә каян китертелгән спортчыларның шайба куып кына миллионнар «эшләүләрен», безнең ил халкының исә кичен телевизорга текәлеп, шуларга җан атып утыруын кабул итә алмыйм. Шул акчаларга күбрәк балалар өчен спорт мәктәпләре, спорт мәйданчыклары ясасалар, хәерлерәк булмас идеме икән? Илнең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге хәерчелеген сөйлисе дә килми...
Югыйсә бер спортчыга түгелгән акча, әйтик, Чаллы драма театрына иркен, яңа бина төзеп куярга җитәр иде бит...

Дуслаштырыр урынга...

Быел «Евровидение» җыр бәйгесе Украинада уза. Россиядән анда инвалид арбасында утыручы кыз Юлия Самойлова катнашырга тиеш иде. Әмма Киев җырчы кызга Украина чикләрен узуны өч елга тыйган булып чыкты: Юлия 2015 елда Кырымда чыгыш ясаган һәм «кара исемлек»кә кертелгән. Соңгы елларда «Евровидение»гә болай да геосәяси вакыйгаларның йогынтысы сизелә иде. Европаның эфирга чыгу берлеге генераль директоры Ингрид Делтерненең бу хәлне: «Бәйгенең сәяси уеннар максатында кулланылуы кызганыч», – дип шәрехләве, Юлиянең катнашу хокукын югары даирәләрдә якларга омтылулары гына гаделлеккә өмет уята.

PRESSA.RU



ӘДРӘН ДИҢГЕЗ, ЗӘҢГӘР ДИҢГЕЗ...

ЧИТ ИЛЛӘРГӘ СӘЯХӘТКӘ ҖЫЕНГАЧ, ОЗАК САЙЛАНЫП ТОРМАДЫК: КАРА ТАУЛАР ИЛЕНӘ – ЧЕРНОГОРИЯГӘ КИТТЕК! ӘДРӘН ДИҢГЕЗНЕ КҮРЕРГӘ!

Йолдыз ШӘРАПОВА



Халкыбызның мәшһүр композиторы Салих Сәйдәшев, Әдрән диңгезне барып күрмәгән булса да (һәрхәлдә, биографиясендә андый мәгълүмат юк), аның гүзәллеген, бар ямен күңелләргә үтеп керерлек итеп, моң телендә җиткерә алган. Җырны тыңлаганда, бу шаулы-даулы диңгез дулкыннарының ярга шап-шоп бәрелгәнен ишеткәндәй буласың, аны барып күрәсең, тау батыры Искәндәр эзләренә басып йөрисең кебек тоела башлый. Шушы җырны ишеткәннән бирле, сихерләп, үзенә тартып тора башлады Әдрән диңгез.

...Мәскәүнең Домодедово аэропортыннан күтәрелеп, өч сәгать буе болытлар арасында йөзгән самолетыбыз, төшәргә әзерләнеп, әйләнә башлагач, иллюминатордан җиргә карадым. Ай Ходаем, кая төшәр икән инде бу?! Уңга карасаң – очсыз-кырыйсыз таулар, сулга карасаң, диңгез җәйрәп ята. Оста очучылар ике тау арасындагы үзәнлеккә урнашкан Тиват аэропортына җай гына төшереп утыртты тагын.

Самолетта очканда ук инде «Монтенегро» дигән сүз ничектер колагымны сискәндерде. Без сәяхәткә җыенган Черногориянең инглизчә исеме икән.





■ ... Менә бу капканы ачасы гына – син инде Әдрән диңгез хозурында!



Бер көндә – өч фасыл

Монда яңгыр сирәк ява, ләкин бер яуса, атна буе туктамый дип, килүгә үк куркытып куйганнар иде. Яңгыр тамчылап кына калмады, коеп яварга тотынды: әллә диңгез болытка тоташкан, әллә болыт диңгезгә төшеп чумган – һич аңларлык түгел. Ярый әле свитерлар алганбыз. Булмаса да гаҗәп түгел, җылы якка кызынырга-коенырга килдек бит. Черногориядә иң беренче алган товарыбыз кулчатыр булды. Бәхеткә, аны озак тотып йөрергә туры килмәде: әллә безнең үзеннән курыкмавыбызны ошатты, әллә инде вакыты җитеп, яңгыр туктады. Ялтырап кояш чыкты, кыздыра да башлады. Иртән – көз, төшен – җәй, кичкә – яз. Ярый әле кыш булмый да, кар яумый – шунысына сөенерлек.

Кара Таулар Иле дип аталса да, таулар һич кара түгел биредә, алар ямь-яшел урман белән капланган. Бөтен дөньядан монда дәвалану өчен киләләр. Бакча-ил, Европа оазисы дип тә атыйлар аны. Илнең халкы моны үзе дә белә һәм бик горурлана. Юк, алай гына да түгел, үзләренең табигатен пычратмас өчен җан-фәрманга тырышалар. Безгә бик кызык тоелса да, бу илдә торбаларыннан төтен чыгарып торучы заводлар күрмәдек. Әйтүләренә караганда, алар анда юк дәрәҗәсендә аз икән. Бу да шул илләренең җәннәт кебек чиста матур табигатен бозасы килмәүдән, әлбәттә. Кирәк әйбернең барысын да диярлек чит илдән алу ягын карыйлар. Ә ризыклары менә – күңелгә ятты. Экологик чиста саф һавада үскән үләнне ашаган сыер, кәҗә сөте ризыклары чын мәгънәсендә табигый, тәмле һәм файдалы. Шулай булса да, балаларга дигәнен тагын да сыйфатлырак ясарга тырышалар.

Хөрәсәннәр иле

Безнең халыкта эш яратмаган, иренгән кешене Хөрәсән ялкавы диләр. Әллә ул Хөрәсән дигәннәре шул Черногория микән? Бу илнең халкы бик ялкау. Алар моны үзләре дә белә, яшермиләр; иң сәере – хәтта моның белән горурланалар да әле. Ялкауларның ун кагыйдәсен дә уйлап тапканнар. Аларны бозып, эшкә тотынмас өчен кайларга гына язмаганнар – туристлар алып китә ала торган бар нәрсәгә! Каләм, кружка, футболка, тастымал – кайда да агач астында ял итеп яткан ир-ат сурәте һәм шул кагыйдәләр:

■ Кеше бу дөньяга бик арып, ял итәр өчен килә.
■ Караватыңны үзеңне яраткан кебек ярат.
■ Төнлә әйбәтләп йоклый алыр өчен эшләреңне читкә куй.
■ Хезмәт итмә, эш үтерә.
■ Әгәр ял итүче кеше күрсәң, аңа ярдәм ит.
■ Үзең булдыра алганны гына эшлә, эшли алмаганны бүтәннәргә куш.
■ Агач күләгәсе – коткаручы. Ял итүдән берәүнең дә үлгәне юк әле.
■ Эш сырхау-чирләрне китереп чыгара: яшьли үлмә.
■ Әгәр эшлисең килсә, бераз көтеп, сабыр итеп тор. Менә күрерсең, бу теләк юкка чыгар.
■ Ашап-эчеп утыручыны күрсәң – кушыл, эшләүчене күрсәң – комачаулама.

Әлеге кагыйдәләрнең безнең халык өчен түгеллеген төшенгәнсездер, шәт... Шаккатарсың, халык белән халык ничек аерыла. Ә үзенең уңганлыгы белән дан тоткан безнең татар халкы, киресенчә, «Эшләмәгән ашамый», дип кабатларга ярата.

Соңрак белдем, монда бер көн эчендә елның өч фасылы да була икән.

Туй түрендә... ил әләме

Кайчандыр Югославиянең бер өлкәсе булган төбәк хәзер Черногория дигән аерым дәүләт булып яшәп ята. Бу Балкан иленең йолалары да үзенчәлекле. Биредә безгә, чын мәгънәсендә, бәхет елмайды: шактый зур суммадагы евроларыбызны түләсәк түләдек (анда акча берәмлеге евро), әмма тау башындагы бер черногор авылына милли туйга баруга ирештек. Дөрес, бу илдә туйга чакырырлык туганнарыбыз да, танышларыбыз да юк иде. Туристлык агентлыкларына рәхмәт, алар

PRESSA.RU





Черногориядә җир асты юлларында шактый мәгълүмат та аласың! Алфавитның һәр хәрефе ил, шәһәрләр тарихы турында сөйли. Дөньяның атаклы рәссамнары, аларның картиналары белән дә танышырга мөмкин бирелә.



килгән кунаклар өчен шундый рәхәт чара уйлап тапканнар. Биек тау башындагы черногор авылына безне автобусларда алып менделәр. Тиешле урынга барып җиткәнче, берничә тапкыр белгән догаларны укырга туры килде килүен, тау бик текә, биек, җитмәсә, серпантин юлы Әдрән диңгез кырыйлатып уза.

Черногория иң саф һавалы ил дип санала.

Тау башына юкка менмәгәнбез икән, анда безне, иң кадерле кунакларны каршылагандай, милли сыйлардан сыгылып торган зур табын әзерләп көтеп торалар иде. Бәйрәмнең ияләре – кияү белән кәләш тә килеп җитте. Алар милли киемнәрдән иде. Мине иң гаҗәпләндергәне – кияү белән кәләш янәшәсеннән ил байрагын күтәргән байракчы атлады. Килгән кунаклар аларны бодай һәм башка ярмалар сибеп каршылады. Яшьләр әләм каршында тез чүгеп, аны үбеп, мәхәббәтләрен соңгы сулышкача сакларга, бер-берсен ташламаска ант иттеләр. Ике башлы сәмруг кош төшерелгән кызыл төстәге дәүләт байрагын тотып баручыга игътибар, кадер-хөрмәт яшьләргә караганда да күбрәк булды кебек. Аннары байракчы ил әләмен гашыйклар урыны артындагы диварга элеп куйды. Черногорларда туй өч көн бара, байрак та өч көн буе шунда эленеп тора...

Туйның үзен мин милли Сабан туебызга охшаттым. Кайбер уеннары нәкъ безнеке. Кунаклар да, яшьләр дә капчык киеп йөгерүдә ярышты. Яшь киленнәр, җиткән кызлар тавык куып йөгерде. Туйга махсус чакырылган атаклы ансамбль егет-кызлары белән бергәләп аякларга ут капканчы биедек. Тик кенә утырсаң, төнлә тау башында салкын. Аннары туйда тукмак та бии! Черногор егетләре бик горур кыяфәтле, бөркет карашлы – икесе дә тау балалары! Кызлары – тауда үскән чәчәк кебек нәфис.

Кадерле кунаклар икәнебезгә табын артында тагын бер кат инандык. Без килә дип, яшь бәрән итен төрле соусларга салып, тәмле итеп пешереп куйганнар. Кәҗә сөтеннән ясалган атаклы черногор сырыннан да, пршут дигән ысланган иттән дә авыз иттек. Эчемлекләрдән ракия (бездәге аракы, кара әле, исеме дә охшап тора), төрле шәраблар бар.

Татарстаныбызга кайткач, бу туй турында дус-танышларга сөйләргә булыр әле. Алар арасында ресторан, кафе хуҗалары да бар бит. Әгәр дә алар үзләрендә бәлеш-гөбәдияле татар туен күрсәтсәләр, килгән кунаклар разый булыр дип уйлыйм – тамак та тук, тамаша да бар. Безнең Казанга хәзер дөньяның кай кыйтгасыннан гына килмиләр бит! Татар илендә булып, чәкчәклеказлы милли туй да күреп китсәләр, әйбәт бит инде: кунакчыллыгыбыз бар җиһанга тарала. Җыр-бию коллективларын, популяр артистларны да чакырырга була.

«Күп яуларны күргән диңгез»

Язмамның башында сәяхәтебезнең максаты – җырларда җырланган Әдрән диңгезне күрү дип әйткән идем бит. Чынлап та, аңа сокланыр өчен генә дә килергә була бу илгә. Бәхетебезгә, кунакханәбезнең диңгезгә караган тәрәзәләреннән фирүзә кашлы зур йөзек булып күренә иде ул. Кырыена тезелеп киткән таулар да аны көмеш йөзек төсле итә. Ә инде ул тауларга урнашкан эреле-ваклы йортларның кызыл чирәп түбәләре мәрҗән муенса төсле күренеп торганга, кара таулар иле кыйммәтле бизәнү әйберләре салынган сандык-хәзинә булып тоелды. Яр буйларындагы су яшел зөбәрҗәт төсле, эчкәрәк кергән саен, зәңгәрләнә бара. Хәер, аның Адриатик (татарча Әдрән) дигән исеме дә зәңгәр дигәнне аңлата лабаса. Үзем күрергә хыялланган шул диңгезнең дулкыннарында да тирбәлеп коендык, аркылыга-буйга пароход көймәләрдә дә йөздек. Диңгез өстендә көймәләрнең ниндие генә юк. Суда батмый торган һәр савытка утырып чыкканнар. Кайсы чүмечкә охшаган, кайсы – ләгәнгә, ә җилкәнле көймәләрне санап кына бетерермен димә. Безнең илнең яңа байларының яхталары да шунда – Будвада тора икән. Ә без үзебез борынгы агач көймәгә утырып,



Әдрән диңгез ярларына хозурланып, күне буе йөздек. Мондагы гүзәллеккә башта күз сөенә, аннары – күңел. Кояш нурларында дулкыннар алтын балык сырты төсле җем-җем килә. Әлеге көймә туристларны безнең эраның IV гасырында ук төзелгән борынгы Котор шәһәренә сәяхәт иттерде. 1500 баскыч буенча тау башына иренмичә менсәң, күз алдында гаҗәп манзара ачыла: Әдрән диңгез уч төбендәгедәй күренә. Ярларында нығытма буларак төзелгән әлеге шәһәр тар урамлы, янәшә ике кеше дә атлап йөрерлек түгел.

Һәр илнең борынгы үткәне, чал тарихы аның архитектура корылмаларында чагыла. Монда да шулай. Антик чорларда ук биредә римлеләр яшәгән. Аннары аларны славяннар басып алган. Соңрак бу ил халкы төрекләр изүе астында калган. Диңгез ярына урнашкан уңдырышлы җирләр күпләрнең күзен кыздырган, күрәсең. Ләкин кыюлыкны бөркетләрдән алган бу батыр халык төрекләрдән генә түгел, французлар изүеннән дә җиңеп котылган. Яуларның төрлесен күп күргәнгә, диннәр дә төрле биредә: христианнар, католиклар һәм мөселманнар. Һәр килгән бере үзенең динен дә китергән. Яр буендагы биек тау башларында ялгыз католик чиркәүләре еш очрый. Аларны булдыра алган кадәр биегрәк салырга тырышканнар. Аллаһка якынрак булырга теләүдән.

Диңгез өстендә – азан аһәңе

Будвадан Барга без таксига утырып бардык. Йөртүчесе бик аралашучан кеше булып чыкты. Юл буе илнең үткәне һәм бүгенгесе турында сөйләп барды. Социалистик Югославияне дә сагынып искә алды. Татарстаннан, Универсиада шәһәре Казаннан булуыбызны, мөселман икәнлегебезне белгәч, шәһәрнең 2014 елның маенда гына ачылган Сәламия мәчетенә алып китте. Манаралары күккә ашкан зур яңа мәчетне күргәч, соклануыбыз соң чиккә җитте. Бераз гына безнең Колшәриф мәчетен дә хәтерләтә, ләкин манарасы да икәү генә, гөмбәзләре дә күрән төстә. Берьюлы ике мең кеше гыйбадәт кылырлык зур намаз бүлмәсе, үзенең мәдрәсәсе, китапханәсе, хәтта балалар бакчасы, хәләл рестораны, спорт һәм киңәшмәләр залы да булган бу ислам комплексыннан чыкмыйча да шәригать кануннарын бозмый гына да көн итәргә була. Өйлә намазы вакыты җитүен белдереп, Әдрән диңгез өстенә моңлы азан тавышы таралды. Кереп, без дә намаз укып чыктык. Ходай үзе кабул итсен! Унике ел дәвамында бөтен дөнья халыклары ярдәме белән төзелгән әлеге мәчет таулар арасында энҗе сыман ялтырап тора.

Озак еллар Төрек Госманлыгы изүе астында торган Черногориядә мәчетләр элек тә булган. Шуларның иң атаклысы, туристларны магнит шикелле үзенә тартып торганы Бар шәһәрендәге Үмәрбаш мәчете 1662 елда ук төзелгән инде. Риваятьләр буенча, Үмәрбаш бер сәяхәтеннән соңарып кайткан һәм кичке намазга кадәр кирмәннең эченә кереп җитә алмаган, намазын шунда үзе басып торган җирдә укыган. Аннары нәкъ шул урында мәчет төзетергә боерган. XVII гасырда төзелгән бу мәчет туристларның иң яратып килә торган урыны.

Суы тылсымлы икән ул Әдрән диңгезнең!

Илләр гизгән – телләр белгән

Гадәттә, телләр белгән – илләр гизгән, диләр. Ләкин монда бу гыйбарәне бераз үзгәртәсем килде. Бу илдә безнең ише инглиз телен белмәүчеләргә дә бик рәхәт: ачтан үлмисең. Бик күп сүзләр русныкына охшаган. Авызыңны азрак ачып, буталчыграк итеп сөйләшсәң, аларча килә дә чыга. Сәяхәтебез азагына бу телдә аңлаша гына түгел, аралаша да башлаган идек инде. Ә менә бер кибеттә үзебезнең татар (!) сүзен ишетеп, тәмам гаҗәпкә калдым. Күлмәк киеп караучы кызга сатучы ханым, товарның тагын да матуррак буласын искәртергә теләптер инде, «каешы-каешы» ди. Белгән таныш сүз колакны ярып керә бит ул. Мин дә, сөенеп, сискәнеп куйдым. Шул безнең дә билләрне буа торган каеш пута турында сүз бара бит инде. Аннары кибеттә – күмер кабына, ресторанда каймакка гаҗәпләнергә туры килде. Эзләсәң, тагын булгандыр әле алар. Болар шул Госманлы заманнан калган төрки сүзләр икән. Кайдан, ничек кенә кергән булмасын, аларны ишеткәч, рәхәт булып китте. Үзеңнеке үзәктә шул инде. Ләкин бу татар сүзләре үз илебезне, үз телебезне юксынырга өлгергән күңелебезгә бәлзәм булып ятсалар да, сагыну сагышын баса алмадылар. Киресенчә, көчәйттеләр генә. Ярый әле озакка килмәдек, шөкер, кайтырга үз илебез, сөйләшергә үз телебез бар. «Ямьле булса да торган җир, сагындыра туган ил» дип юкка гына әйтмәгәннәр шул аны. Менә шушы хакыйкатьне аңлар өчен генә булса да чыгып керергә кирәктер ул илебез чигенең теге ягына.

Редакциядән: танылган балалар шагыйрәсе, каләмдәшебез Йолдыз ШӘРАПОВАга – 55 яшь! Котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ БЕЗДӘН КӨЧЛЕРӘК



Илсур МОРТАЗА (МОРТАЗИН) – юмор остасы, җырчы, артист, сценарист, режиссер; өйләнгән; гаилә стажы – 25 ел; бер бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Яшь чакта, әлбәттә, чибәрлегенә, буй-сынына күз төшә. Зәвык белән киенә белгән хатын-кызлар ошый миңа. Ә хәзер, ир уртасы булгач, 80 процентка, дип әйтә алам, күзләре җәлеп итә. Беренче караштан кемнең кем икәнен аңлыйм. Нинди генә хәйләкәр булса да, хатын-кызның күңелендәге барлык хисләре күзләрендә чагыла.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хәзерге тулы эмансипация заманында да хатын-кызлар матур гаилә кору, бала табып үстерү турында хыяллана. Нинди генә сүзләргә төрсәк тә, хакыйкать бер: кешелекнең иң көчле коды – үрчү коды. Үзенең яраткан ире аңа бала сөю бәхетен бирә алмаганда, хатын-кызның әни булу хакына кылган хыянәтен гафу итә алам.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Җенси азгынлыгын канәгатьләндерү өчен хыянәт итүен. Тагын эчкече хатын-кызларны гафу итә алмыйм. Исереклек ирләргә дә килешми, ә исерек хатын-кыздан да ямьсезрәк күренеш, гомумән, юк дип саныйм. Барлык бозыклыкларга беренче адым шуннан башлана. Шөкер, Ходай мине бу афәтләрдән саклады дип ышанам.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Икесе дә. Минем өчен хатыным шундый була алды. Ул тәмле пешерә, пөхтә, тәртип ярата, зәвыклы комфорт та тудыра белә.

Моннан тыш, иҗатка илһамландыручым да – ул: мин җыр текстлары язам, Мәүлидә аларга көй иҗат итә. Уртак җырларыбыз дистәдән артып китәдер: «Куркам синең сөюеңнән», «Аермасын язмышлар», «Бүләк», «Улым – минем киләчәк», «Әнкәемнең күңелкәе» һәм башкалар.

Хәзерге вакытта мин вакытлыча Буа театрында эшлим, Мәүлидә – Казанда. Ара ерак та түгел, әмма көн дә кайтып та йөреп булмый. Гастрольләргә чыгып китсәк, атналар буе күрешмибез. Мондый аерылышып торулар нык гаиләләр өчен бер дә зыянга түгел дип саныйм: бөтен үпкәләр онытыла, хатынның яхшы яклары гына искә төшә, тәмле ашлары сагындыра... Хисләрне яңарту өчен дә бик кирәк этап бу тормышымда.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Мин тәкъдим ясап тормадым. 1992 елның гыйнварында Чуашстанның Батыр районы Татар Согыты авылына концерт белән баргач күрдем аны беренче тапкыр. Туганы безнең төркемнең администраторы булып эшли иде. Кыз кунакханәгә аның белән күрешергә килгән иде. Мәүлидәгә ул вакытта 22 яшь, Батырда музыка мәктәбендә укыта. Бик ошады: үзе шаян, үзе сөйкемле, бераз гына усал да шикелле. Бер күрүдән күңелемне биләде. Шаяру катыш: «Мин сине урлап китәм», – дидем. Февральнең 8 ендә, «КАМАЗ» машинасына утыртып «урлап» та кайттым. Үзенең ризалыгы белән инде. Кайткач, никах укыттык, мартта туй ясадык.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый...

– Шулайдыр. Әмма минем очракта сайлау түгел, сиземләү, тою булгандыр ул. Өйләнешкәнче берничә генә очрашып өлгердек бит без. Тышкы охшашлыклары булмаса да, хатынымда әнкәйнең байтак асыл сыйфатларын күрдем мин: тәмле кулы, уңганлыгы өстенә, киң күңеллелеге, тугрылыгы, кичерә белүе, зур җаваплылык хисе.

Кече киленен бик яратты әнкәй. Мәүлидә дә килен булып төшүенең беренче көннәреннән әни белән бергә торып, бөтен эштә булышырга омтылды. Җыештыра башласа, ялтыратмыйча туктамый. Әнкәй аның тырышлыгына сокланып: «Казыма инде шулхәтле», – дия иде. Пөхтәлек аның канына сеңгән. Инде мине дә шул дәрәҗәдә чисталыкка ияләштерде ки, хәзер теләсә кемгә кереп азык та ашый алмыйм, бик талымчанга әйләндем.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бар андый гаиләләр, тик аларда иргә хөрмәт юк. Ата-бабадан шулай килә бит инде, мал табу, гаиләсен туендыру – ир кеше эше. Гарип, инвалид булмаса, ир хатын тапканга риза булып ятарга тиеш түгел. Бу эшеңдә акча юк икән, икенчесен тап! Эшләргә теләгән кешегә эш бетмәгән. Инде хәлеңнән килми икән, хатыныңның битәрләвенә, кимсетүенә түзеп яшәргә кала. Гомер буе үзем эшләдем, бүрәнәнең авыр башын үзем күтәрдем.

8 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Тормыш тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: күпчелек очракта хатын-кызны тыныч холыклы, аек, җайлы ирләр җәлеп итә. Ә тормыш көтә башлагач, ирләрдә ныклык кирәклеге ачыклана. Хатын-кыз ирдә терәк эзли. Рухи көче булмаган ирләрдән тиз туя ул.

9 **Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүләрен көтәсез?**

– Шәфкатьле күңелемә, ярдәмчеллегемә. Кешегә булышырга яратам, шуннан ләззәт алам.

10 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Бар андый нәрсә. Гомер буе артык гүзәлләрне читләтеп үтәргә тырыштым. Чибәрләргә принц кирәк, тирә-юнендәге гади егетләргә алар түбәнсетеп, көлеп карый. Ә мин үземне беркайчан да асыл сөяккә санамадым, буй җитмәскә үрелмәдем. Артык матурларга барлык кешенең күзе төшә. Мондый игътибарны аларның бик сирәге генә күтәрә ала. Кызганычка каршы, күбесенең язмышы аянычлы була: принц көтә-көтә арып, ялгыз калалар, эчүчелеккә, азгынлыкка биреләләр, адәм мәсхәрәсенә калалар. Чибәрлекне Ходай биргән зур сынау дип саныйм.

Ир-ат үзе көчле, малтабар, дөнья йөген җигелеп тартучы булырга омтыла. Шуның өчен мактау, үсендерү көтә. Хатыны аңа сокلануын белдереп, рәхмәтле булып яшәсә, без, ирләр, таулар күчерәбез. Ә көчле хатын белән яшәү авыр. Ир андый хатын-кызда көндәш күрә башлый. Гүзәл зат үзен зәгыйфь, назлы итеп күрсәтү осталыгына ия булса гына, ирен, гаиләсен саклап кала ала. Калган очракта ике вариант бар: көчле хатын, пешмәгән дип санаган ирен куып чыгара яки ире, үзен көчле ир итеп, санлап торачак хатын эзләп чыгып китә.

Тормышта болай да хатын-кыз ирләрдән көчлерәк тә, зирәгрәк тә, чыдамлырак та, һәм моны һәрдаим исбатлап яшәргә кирәкми.

11 **Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.**

– Хатын-кыз башта эшли, аннары уйлый. Минем хатын көлә: «Гомер буе мыеклы кешеләрне яратмадым, ә үзем сакаллы кеше белән яшим», – ди. Үзе орчык кадәр генә булса да: «Кечкенә буйлы иргә кияүгә чыкмаган булыр идем», – ди. Гомумән: «Башта кияүгә чыктым, аннан гашыйк булдым», – ди.

Ә җитдирәк әйткәндә, чыннан да, хатын-кызның логикасы бик үзенчәлекле: аның барлык гамәлләре үз мәнфәгатен кайгыртып эшләнә. «Минеке», «минемчә», «миңа» – менә шул аның яшәү принцибы. Бу дөрестер дә, чөнки гаиләсенең киләчәген, иминлеген, муллыгын кайгыртып шулай эшлим, дип уйлый бит ул.

Ә ирләр исә киңрәк уйлый. Ул да киләчәкне күз алдында тотып эш итә. Тик бүген ирнең ахмаклык булып тоелган адымнары яшәеш чылбырының бер буыны икәнлеген хатын-кызга аңлатуы бик читен.

12 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Хатын-кызда кирелек бик зур. Мәүлидә дә искәрмә түгел. Гомумән, безнең икебездә ике менталитет. Башка милләт арасында үскән татарларга исән калу өчен көчле, горур, тәвәккәл булырга кирәк. Аларга хисчәнлек, сентиментальлек ят. Минем хатынның да холкы шундый. Ничек тә үз дигәнен итәргә омтыла. Шулай да, яши-яши бер-береңә ярашасың, очлы почмаклар яссылана.

Башта хаклы булуымны расларга талпынып карыйм инде. Холкым, Сукоярларга хас булганча, тиз кабынучан. Кычкырып җиңә алмагач, «тайм-аут» алам. Ә теге проблема үзеннән-үзе бетми, һаман баш калкыта тора. Соңгы чиктә хатынга минем белән килешергә туры килә.

13 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып кердегез, ә өйдә ашарга пешмәгән...**

– Минем гаиләдә мондый хәл, гомумән, булырга мөмкин түгел. Хатын иртән кайнар азык хәстәрләп озатып кала, кичен, кайчан кайтсам да, тәмле ризык пешереп каршы ала. Чирек гасырлык гаилә тормышымда «үзең кара, үзең җайла инде», дигән сүз ишеткәнем юк. «Хәзер, 5 минут көт, була», – ди. Кулларны юып өстәл артына утырганчы табын сый-нигъмәт белән тулган була.

Бик илһам килгәндә, үзем дә пешереп куям: итле бәрәңге, французча ит әзерләргә яратам. Тәмле дип ашыйлар.

14 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

– Озак вакытлар бик авыр мәсьәлә булды бу бездә. Мин бик тиз җыенам. Хатынның озак мыштырдавы җен ачуларын чыгара иде элек. Тавыш башлыча шуның аркасында чыга иде. Аннан, акрынлап, бер-беребезгә яраклаша башладык: кая булса да барасы булса: «Күпме вакыт бирәсең?» – ди һәм шул вакытка әзерләнеп бетәргә тырыша. Мин дә инде алай күтәрелеп бәрелмим. Ирләрнең, яшь барган саен, күңеле нечкәрә бара. Ә хатын-кызның – киресенчә. Гомумән, әгәр ирен барыбер үзгәртәсен белмәсә, хатын-кыз аның белән яшәмәс тә иде.

15 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...**

– Мин бүләккә битараф. Андый вак-төяккә исем китми. Хатыным бүләк иткән һәр нәрсәгә канәгатьмен. Минем өчен иң зур бүләк – этюдник. Рәсем ясап, дусларга бүләк итәргә яратам. Тик вакыт кына җитми. Кылкаләм алсам, дөньямны онытып иҗатка чумам. Пейзаж да, натюрмортлар да ясыйм – һәрберсе китеп бара.

Ә үзем хатыныма бизәнү әйберләре бүләк итәргә яратам. Форсат та чыгып тора – март аенда гаиләбезнең 25 еллыгын К. Тинчурин театрында «Көмеш туй» дигән тамаша белән билгеләп үттек.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Мастер-классны югары категорияле аш-су остасы Лилия БАЙКЕЕВА үткәрә. Казанның Яңа бистәсендә туып-үскән Лилия ханымның эш стажы 40 елдан артык. Кызы Динара, улы һәм ике оныгы да шушы һөнәрне сайлаган. Бүген үзе эшли торган «Татар утары» рестораны белән Лилия ханым кайларда гына булмаган да, ул пешергән татар ашларыннан кемнәр генә авыз итмәгән. Быел Франциядә узасы Сабантуйга барырга әзерләнәләр. Болардан тыш, ул әле яшьләрне дә татар ашлары серенә өйрәтә.
Ә менә бүген безгә пешереп күрсәтәсе талкыш кәләвәне Казанда ике-өч кенә кеше пешерә белә икән. Белгәннәре дә ул серне башкалар белән бүлешергә бик атлыгып тормый. Лилия ханым үзе дә аны тиешле кимәлгә җиткереп әзерләргә өйрәнгәнче, бер генә литр бал тотып бетермәгән. Катлаулы булса да, тәвәккәлләп, тотынып карыйк соң, эшләп карамыйча гына бернәрсәгә дә өйрәнеп булмый бит.



ТАЛКЫШ КӘЛӘВӘ



Кирәк:

(ширбәт өчен)
- 150 г бал;
- 450 г шикәр комы;
- 150 мл су.

Әлбә өчен:
- 100 г сары май (акмай белән дә пешерергә була);
- 1 стакан он.
- Киңәшебез: беренче тапкыр пешергәндә талкыш кәләвәне бирелгән ризыкларның яртысын гына кулланып, аз гына күләмдә ясап карагыз. Дөресен генә әйткәндә, беренче тапкырдан ук килеп чыгуы бик икеле. Күп очракта ул җепселләнми, ширбәт катып китә.



Эш барышы:

■ Кәстрүлгә су, бал, шикәр комы салып, ширбәт кайнатырга куябыз. Пропорцияләрне төгәл сакларга кирәк. Ширбәт дөрес кайнатылмаган булса, талкыш кәләвә килеп чыкмый. Аны тешкә ябышып, сына башлаганчы кайнатабыз (ике теш арасыннан тел белән эткәндә, сузылырга түгел, сынарга тиеш). Лилия ханым аны «әтәчләнгәнче» (ягъни әтәч конфет ясарлык булганчы) кайнатарга кирәк ди.

■ Әзер ширбәтне суытыр өчен төбе майланган табага бушатабыз. Кырыйларын күтәргәләп, суынганын көтәбез. Ул бик кайнар, әмма кулга җыеп тотарлык куелыкта булырга тиеш.

■ Ширбәт белән рәттән әлбәне дә пешерергә кирәк. Моның өчен калын төпле табада майны эретеп, онны салабыз һәм болгата-болгата кыздырабыз. Әзер әлбәдән кызган чикләвек яки көнбагыш тәме килеп торырга тиеш. Онны майга салуга кабып карагыз, ул тәмсез була. Аннары кызгач авыз итегез, он хуш исле, тәмле булырга тиеш.

Талкыш кәләвәне сузу:

■ Кулга бер кат – чүпрәк, аның өстеннән резин перчатка киеп, ширбәтне җыеп тотабыз. Ул агып төшәргә генә тора, шуңа күрә тиз-тиз эшлисе. Сул кулга җыеп тотасың, уң кул белән сузасың, урталай бөкләп, кабат сул кулга кайтарып саласың. Тарта торгач, ширбәт агара, кайтарып салганда «чап-чап» дигән тавыш чыгара башлый, нечкә җепселләргә аерылырга керешә.

Әлбәне сеңдерү:

■ куна тактасына әлбәне бушатып, кашык белән тигезлибез. Әлбә дә, ширбәт тә бертөсле җылылыкта булырга тиеш. Кулдагы ширбәтнең ике очын боҗралап тоташтырабыз да әлбә өстенә салабыз. Боҗраны әлбә өстендә килеш кенә сузып, урталай бөклибез дә кайтарып салабыз, шулай ширбәткә әлбә тәмам сеңеп бетеп, ак төстәге вак-вак җепселләргә аерыла башлаганчы кабатлыйбыз. Өзеп чыгарырык итеп тартмаска кирәк.

■ Җепселләнгән кәләвәне тотам-тотам итеп аерабыз. Кукуруза чәчен хәтерләтә торган була ул.

■ Хәзер аны формага тутырасы калды. Моның өчен кечкенә савыт кулай (махсус формасы да бар, ләкин аны заказга ясатсаң гына). Формага тутыруның да сере бар: савыт төбенә кәләвәне тыгызрак итеп саласы, уртасы бушрак булсын, аннары савытны тутырып бетерәбез дә, авызы белән кунага каплап, бер-ике тапкыр ышкып алабыз – тигезлибез. Савытны селкеп, эчендәге кәләвәне тактага төшерәбез. Форма кулланмыйча, кәләвәдән кечкенә шарлар гына әвәләсәң дә була. Талкыш кәләвә – кунак чәенә дигән үтә дә татлы ризык.

PRESSA.RU

Зилә – модельер-дизайнер. Киемнәрдә миллилекне һәм нәфислекне күрсәтергә тырыша. Тыныч төсләр, татарча бала итәкләр, түшләре бөрмәле күлмәкләр, милли бизәкләр – Зиләнең күлмәкләре әллә каян игътибарны җәлеп итә. Ә тегәргә аны... балачагында әтисе өйрәткән. Көннәрдән бер көнне өйдәге тегү машинасын көйләп, алар икәүләшеп эшкә кия торган бияләй теккәннәр. Тегү эшенә мәхәббәт Зиләдә әнә шул көннән уянып калган. Мәктәпне тәмамлагач, кая барырга дип уйланып тормаган ул – туп-туры КФУның сынлы сәнгать һәм дизайн факультетына юл тоткан. Зиләнең эскизлары белән тегелгән киемнәрне Казан кызлары гына түгел, Мәскәүнекеләр дә бик яратып кия. Бүген ул безгә тәкъдим итә торган жилет заманча мода белән тегелсә дә, милли бизәкләре булганга, үзенчәлекле күренә. Аны тегүе катлаулы түгел.





Мастер-классны Зилә ӘХМӘТОВА үткәрә.

МИЛЛИ ҺӘМ ЗАМАНЧА




Кирәк:

- Иңе 140 см булган тукыма; буе – жилет озынлыгына бәрабәр;
- көмеш төсендәге термоаппликация (көмеш төс – универсаль, ул теләсә нинди төс белән яхшы яраша);
- 11 данә ак сәйлән. Бишесенең диаметры – 0,5 см, калганнары – чак кына ваграк;
- Тукыма төсенә яршлы тегү җебе.

■ Жилет гадәти күлмәк өлгесенә (выкройка-основа, базовая выкройка да диләр) нигезләнеп киселә. Тегәргә яраткан кешеләргә иң элек шушы өлгене кайгыртырга кирәк. Ничек ясарга икәнен китаплардан да, интернеттан да карап була. Иң яхшысы – аны калын катыргыга ясау һәм кирәк булганда кәгазьгә күчермәсен алу.





Түбәндәге үлчәмнәр кирәк:

■ Алдан да, арттан да жилетның озынлыгы. Ул муен төбеннән башлап үлчәнә. Тасма алдан – күкрәкнең иң биек ноктасы, арттан калак сөяге аша узарга тиеш. Озынлыкны үзегез теләгәнчә итә аласыз. Без, мәсәлән, янбашына чак кына төшеп тора торган иттек.

■ Күкрәк әйләнәсе. Сантиметр тасмасы арттан калак сөякләре өстеннән, алгы якта күкрәкнең биек ноктасыннан уза. Тасманы артык тартып үлчәмәгез.

■ Бил әйләнәсе.

■ Янбаш әйләнәсе. Янбашының иң калку җиреннән үлчәнә.

■ Арка киңлеге. Бер култык чокырыннан икенчесенә кадәрге ара.

■ Иңбаш озынлыгы.

■ Муен төбеннән күкрәк очына кадәрге ара.

■ Җиң төбе уелышы озынлыгы.

■ Төп өлгенең күчермәсенә бераз үзгәрешләр кертәбез. Мәсәлән, арт якта билдәге уйдырманы (вытачка) ябабыз, муен уемын 1-2 см тирәнәйтәбез. Кырыйдан аскы якка таба 6-7 см клеш ясап киңәйтәбез.

■ Алгы якта исә иңбашындагы уйдырманы (вытачка) кырый җөйгә күчерәбез. Аны 1,5 см кыскартабыз.

■ Билдәге уйдырманы ябып, кырыйдан аска таба шулай ук клешландырып, 6-7 см киңәйтәбез. Алгы якның итәк очын дугаландырып кисәбез. Муен уемын да түгәрәкләндереп җибәрәбез.

Жилетны кисү:

■ Тукыманы пар белән үтүкләп, керештерәбез һәм урталай бөкләп, өстәлгә җәеп салабыз. Өлгеләрне чукмарбашлы энәләр белән тукымага беркетеп торып, акбур белән эзен төшерәбез. Кырыйлардан 1,5 см, астан 3 см тегү өлешләре калдырып, тукыманы кисәбез. Алгы як – 2 кисәк, арткы як – 1 кисәк.

■ Болардан тыш, безгә әле 3 астар да кисәргә кирәк. Аларның иңе – 6 см, озынлыклары: икесе – ал кыса озынлыгы кадәр (болары подборт өчен), берсе – арткы якка, муен уемы озынлыгы кадәр (обтачка була). Алар тукымага буй җеп юнәлешендә салып киселә.

Эш барышы:

■ Иң беренче эш итеп, алгы яктагы уйдырмалар тегелә. Уйдырма очлары күкрәк очына юнәлергә, икесе дә симметрияле булырга тиеш. Уйдырманы аска таба каратып үтүклибез.

■ Аннары кулдан гына иңбашындагы һәм кырый җөйләр тегелә. (Әлегә аны машина белән бастырмыйбыз!)

■ Киемне сул ягына әйләндереп, киеп карыйбыз. Уйдырмалар дөрес ятамы, муен уемы муенга терәлеп тормыймы, жилетның итәк очы бер-берсенә менеп тормыймы, симметриялеме, иңбаш җөе артык озын булмаганмы – боларның барысын да карарга кирәк. Сул яктан киемгә төзәтмәләрне кертү уңайрак.

■ Барысы да канәгатьләндерә икән, ул җөйләрне машина белән тегәбез.

■ Гадәттә, иңбаш җөен теккәндә, алгы як бераз озынрак булып чыгып кала. Аны кисеп алмаска, ә арткысы белән тигезләп, сыйдырып бетерергә кирәк. Моны эшләү кыен түгел: машина җөе салганда,

PRESSA.RU



алгы як аста булсын, теккән вакытта энә очы белән җыерып, аны сыйдырып бетереп була.

■ Астарларны баш-башларыннан бер-берсенә тегеп тоташтырабыз. Тәртибе болай: ал кысага тәгаенләнгән астар белән муен уемына дигәнен уң яклары белән бер-берсенә яткырып, өске очыннан машина җөе белән тегәбез. Муен астарының икенче очына кысага тегеләсе икенче астар тоташтырыла.

■ Һәрбер җөйне яхшылап үтүкләп, сыпылмасын өчен оверлок яки зигзаг җөй белән эшкәртәбез.

■ Эчкә таба 1,5 см кереп, астарны жилетка тегеп тоташтырабыз. Теккәннән соң, тегү өлешен кайчы белән кисеп, тарайтабыз. Астар читен шулай ук оверлок белән эшкәртәбез.

■ Җиң уемын тегү. Башта җиң уемының читен оверлок яки зигзаг белән эшкәртеп чыгабыз. Аннары аны эчкә таба 0,5 см бөкләп, кырыйдан 3 мм кереп, машина белән җөй салабыз.

■ Жилетның аскы итәген оверлок белән эшкәртеп, эчкә таба 1,5 см бөклибез, ачылып китмәсен өчен юеш тукыма аша үтүклибез.

■ Жилетның читеннән 3 мм эчкә кереп, машина белән җөй салып чыгабыз. Алгы як, муен уемы, аскы итәк тоташ бер җөй белән тегелә. Аскы итәкне теккәндә, астарның очын эчкә таба бөкләп, җөй белән аны да бастырабыз.

Бизәү:

■ Аппликациядән күңелебезгә ошаган кисәкне кисеп алып, аны жилетның бизәк буласы җиренә чукмарбашлы энәләр белән беркетәбез. Тукыманың сул ягыннан үтүк белән бастырып, аппликацияне жилетка ябыштырабыз. Үтүк белән генә ышанычлы булмый, соңыннан энәгә аппликация төсендәге җеп саплап, белендерми торган итеп, тукымага беркетәбез.

■ Бизәк очына сәйләннәрне тегәбез. Беренче булып эре сәйлән тегелә, аннары – ваграклар. 3 сәйлән – жилетның бер ягына, 3 сәйлән – икенче ягына. Сәйлән аралары 1 см итеп калдырыла.

■ Жилетның арткы ягын да бизибез. Бизәк бил турысына кыл уртага тегелә. Аның ике ягыннан да икешәр сәйлән урнаштырыла. Аска исә, бизәктән 1 см төшеп, 1 эре сәйлән беркетелә. Алгы яктан – бил турысына күренми торган каптырма тегелә.

■ Киемебез әзер, аны итәк белән дә, чалбар белән дә кияргә мөмкин. Тар итәк белән күркәмрәк күренәчәк.


Кучкар. Тирә-юньдәгеләр белән аралашуда бернигадәр киеренкелек тоелса да, кәефегез күтәренке булыр. Күңелегез яңалыкка, кызыклы чараларга әйдәр. Майның өчесенә кадәр сезнең йолдызлык Меркурий планетасы тәэсирендә, шуңа күрә юлларда игътибарлы булыгыз.


Үгезбозау. Финанс ягыгызның яхшыруын тоярсыз. Шәхси өлкәдә дә куанычлар булыр. Шулай да Меркурийның тәэсире бераз сизелеп, мәгълүмат кабул итү, игътибарлылык мәсьәләсендә кыенлыклар кичерергә мөмкинсез.


Игезәкләр. Көч-куәтегезнең артуын тоярсыз. Кызыклы идея белән мавыгып китү ихтималы зур. Бу бик әйбәт, чөнки шуның белән табыш ала башларсыз. Эшегездә дә, шәхси тормышыгызда да яңа күтәренкелек булыр.


Кысла. Сез дуслар белән көчле. Шуңа да алар белән күбрәк аралашырга тырышыгыз. Уйнап-көлеп кенә сөйләшкәннән дә үзегезгә файдалы мәгълүмат ишетерсез. Киләчәкне планлаштыру өчен яхшы вакыт.



Арыслан. Эшләрегезне үзегез теләгәнчә башкарырга беркем дә комачауламас. Хыялларыгызны, яңа идеяләрегезне тормышка ашырыр өчен бик кулай чор. Яңа эшкә тотынсагыз, нәтиҗәсе әйбәт булыр.


Сөмбелә. Уйларыгыздан ваз кичмичә, юлыгызны алга карап дәвам итегез. Сезгә беркем дә аяк чала алмас. Сәламәтлегегез борчыган булса тынычланыгыз, сезнең белән бар да яхшы.


Бизмән. Моңа кадәр көчегез кимеп киткән кебек булса да, бу айдан сезне яңа энергия бөтереп алачак. Шулай да көчегезне юкка-барга сарыф итүдән сакланыгыз, югыйсә башлаган эшегезне төгәлли алмассыз.


Чаян. Мөһим казанышларга ирешергә барлык юллар да ачык. Форсаттан файдаланып калыгыз. Хыялларны чынга ашырырга мөмкинлек булыр. Әмма моның өчен бар көчегезне бирергә туры килер.


Укчы. Эшегез күбәер, әмма бу тормышыгызга кызыклы яңалыклар һәм рухи канәгатьләнү алып килер. Танышларыгыз артыр. Ашыга торган гадәтегез мөһим карарлар кабул иткәндә комачауларга мөмкин.


Кәҗәмөгез. Ыгы-зыгылардан котылып, күңелегез тарткан эш белән шөгыльләнү форсаты туар. Иң кыю идеяләрегезне дә тормышка ашыра алырсыз. Иҗади эшкә сәләтегез ачылып, дөньяның моңарчы күрмәгән якларын барларсыз.


Сукояр. Вакытыгызны гаиләгезгә, өегезгә багышласагыз яхшы булыр. Җирдә эшләү форсаты булса, кире какмагыз, кыш буена саеккан энергияне тулыландыру өчен шәп мөмкинлек бу. Һич югында гөлләр булса да утыртыгыз.


Балык. Тәнегездә генә түгел, җаныгызда да талчыгу тоярсыз. Монннан котылу юлы бер генә – күбрәк табигатьтә булу. Күп кенә «балыклар» матурлыкка, иҗатка тартылу сизәр. Уйлаган уйлар чынга аша торган ай бу.

апрель дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Наилә Фатехова (12.04.1962) – **Татарстанның һәм Россиянең атказанган артисты.**

Мәскәүдә туып-үсә. Әти-әнисе чыгышлары белән Нижгар өлкәсеннән. Мәктәп яшеннән үк Наилә көйләр яза. Кызларының музыкага һәвәслеген күреп, аны музыка мәктәбенә укырга бирәләр. Музыка училищесында «хор дирижеры» белгечлеген ала. 1980 елдан «Москонцерт»ның Сәйяр Хәбибуллин җитәкләгән «Хыял» ансамблендә чыгыш ясый башлый. Телевидениедә «Шире круг», «Споемте, друзья», «С добрым утром» тапшыруларында катнаша. 1986–1988 елларда – Мәскәү өлкә филармониясендә вокалчы-солист. 1989–91 елларда Хөсәен Кужалиев җитәкчелегендәге «Эмират» ансамблендә эшли, 1991–2005 елларда кабат Мәскәү өлкә филармониясендә. «Умырзая» дип аталган җырлар җыентыгы, «Дөнья кешесе», «Гөлләр», «Татар илем» дип аталган альбомнары бар.

Россия



Светлана Немоляева (18.04.1937) – **РСФСРның атказанган артисты.**

Маяковский исемендәге театрда әйдәп баручы артистларның берсе. 2013 елда «Алтын битлек» театраль премиясе лауреаты. Кинода бала вакытыннан ук уйный башлый. Әтисе – кинорежиссер Владимир Немоляев еш кына аны күмәк күренешләрдә катнаштыра. Белемне Щепкин исемендәге югары театр училищесында ала. 1959 елдан – В. Маяковский театрында. Шушында булачак ире Александр Лазарев белән таныша, тагын бер елдан аңа кияүгә чыга. Ил күләмендә аны Эльдар Рязанов фильмнары таныта: «Служебный роман», «Гараж», «Небеса обетованные»... Улы Александр Лазарев, оныгы Полина Лазарева – шулай ук артистлар.

Чит илләр



Анук Эме (27.04.1932) – **күренекле француз артисты.**

Актерлар гаиләсендә туган кыз балерина булырга хыяллана. Әмма 13 яшендә кисәк кенә үсеп киткәнлектән, укытучылары аның балерина карьерасын шик астына ала. Анукка (чын исеме Франсуаза) танылу «Монпарнас, 19» фильмында уйнаганнан соң килә. Яшь актрисаны режиссер Федерико Феллини күреп, үзенең фильмнарында уйнарга чакыра. Әмма дөньяның барлык тамашачылары өчен дә Анук Эме – иң беренче чиратта Клод Лелушның «Мужчина и женщина» фильмындагы Хатын-кыз булып гәүдәләнә. Искиткеч уңышлы уйнаган бу роле өчен аны «Оскар», «Алтын глобус» премияләренә тәкъдим итәләр. 1980 елда «Прыжок в пустоту» фильмында башкарган роле өчен Канн фестивалендә призга лаек була.

PRESSA.RU





ТОРМЫШ СЫЗЫКЛАРЫ

Россиядәге иң үзенчәлекле рәссамнарның берсе дип бәялиләр бүген Ирик Мусинны. Иҗат итү рәвеше дә, фикер сөреше дә, тормыш фәлсәфәсе үзгә аның.

– Рәссам ул, һөнәрдән бигрәк, яшәү рәвеше, – ди ул үзе. – Син һәрвакыт үз персонажларың белән яшисең. Чөнки теләсә кайсы эш ул эчке кичерешләр белән бәйле.

Өлкән буынның йөзендә җир белән бәйләнешне тоеп, сизеп була, ә ташкалада яшәүчеләрдә бу юк: аларның йөзе дә, тавышы да, егәре дә башка, дигән фикердә ул. Заманында Ирик юкка гына каланы ташлап, Саба районына кайтып китми инде. Өч еллап авылда яши. «Анда син җиргә, шундагы мохиткә бирегәсең, бербөтен буласың. Чистарынасың. Шундагы һаваны сулыйсың, саз, кар ерып йөрисең икән, синең эшләрең дә күзгә күренеп үзгәрә. Авылда сирәгрәк булган саен, пейзажның да төсе, җаны китә», – ди.

Еш кына XIX гасырга «китеп-китеп» алуы да, тормышны төптән җигелеп тарткан өлкән буынга мөрәҗәгать итүе дә юкка түгел. Үткәндә калган мизгелләрне, чорны «тотар» өчен үзенең персонажларына шул дәвергә хас киемнәрне «кигертә» рәссам. Шуңа күрә дә аның эшләрендәге хатын-кыз образлары да, ниндидер ханымның купшы портреты булудан бигрәк, сабыен кайгыртучы ана яки ерак тарихта калган бер сылуның уй-сагышлары, йә узган гомере йөзенә үз чалымнарын калдырган әбиләр рәвешендә чагылыш таба.

– Безнең тормышыбыз билгеләүдән башлап хатын-кыз тәрбиясен, мәхәббәтен, назын, аларның җан җылысын тоеп үтә, – ди рәссам, әлеге темага алынуының өстенлекләрен барлап. Шуңа да аларның, тышкы матурлыгыннан бигрәк, эчке дөньясын, күңел байлыгын бирергә омтыла ул. Күп кенә эшләре балачак хатирәләренә тоташа. Әйтик, әбиләрне яза икән, монысы әтисенең әнисе – Саба районы Җәнәй авылындагы әбисендә узган балачагы белән бәйле истәлекләренә нигезләнә. Петропавловскидан ел саен өчәр айга җәйге каникулга кайта торган була ул анда. Эшкә өйрәтүчесе дә, җиргә мәхәббәт тәрбияләүче дә, урман шавына колак салырга, табигать биргән нигъмәтләрне танырга өйрәтүче дә Мәгъдүмә әбисе була.

«Әбиләр чуагы» – хәтергә уелып кала торган эшләреннән. Гомер иткән нигезенә сөялеп, көзге кояшның тымызык, тансык җылысында изрәгән шундый әбекәйне табарга кирәк бит әле! Әлеге хозурлыктан оеп китеп, черем итәме ул, әллә еракта калган яшьлек елларын искә аламы, урманда йөреп кайтканнан соң аякларына бераз ял бирәме – анысын Ходай гына белә.

– Зәкия апа минем бик якын дустым иде. Авылга кайткан саен янына бара торган идем. Туксанның өстендәге әби миңа һәрвакыт үзенең тормышы турында сөйли. Аны тыңлагач, ис-акылың китә. Ничек алар шул авырлыклардан соң да йомшак күңелле булып калганнар дип уйланасың, – ди рәссам.

Гадәттә, рәссамнар үз хатыннарын ясый. Ирик Мусин да искәрмә түгел. Бүгенге көндә театр артисты булып эшләүче Ләйсән Каюмова ире остаханәсендә дә «төп рольләрдә». Икәүләшеп тудырган шундый эшләрнең берсе «Чүп» дип атала. Никадәр мәгънә салынган аңа! Җан ярасы булсынмы, тән җәрәхәтеме – әниләребезгә сыенабыз шул. Бармагыңа чүп керсә дә, авыр сүз екса да – әни кирәк.

Расиха ФАИЗОВА









ИРИК МУСИН

PRESSA.RU



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204

11–21 май көннәрендә «Почта России»ның почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз!

Якыннарыгызга бүләк эзләгәндә «Сөембикә»не сайлагыз!



Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин.



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+